Әнәс Хәсәнов

# Әнис алмалар

*Повестьлар*

# Анисовые яблоки

*Повести*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-31
ББК 84 (2Рос=Тат)-44
Х91

**Хәсәнов Ә.Х.**

Әнис алмалар: повестьлар / Анисовые яблоки: повести / Әнәс Хәсәнов; тәрҗ. Г.Хәсәнова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 239 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01760-2

Язучы Әнәс Хәсәновның бу китабындагы повестьлары яшь егетләрнең һәм кызларның күңелләрендә борынлап кына чыккан тәүге мәхәббәтен тасвирлый. Бу изге хискә тугры калып, яшьләрнең әхлакый югарылыкка ирешүен чагылдыра.

Китапны зур тормышка аяк басарга җыенучы яшьләр яратып укыр дип уйлыйбыз.

УДК 821.512.145-31
ББК 84 (2Рос=Тат)-44

ISBN 978-5-298-01760-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Хәсәнов Ә.Х., 2008

***Хөрмәтле укучыма берничә сүз***

*Укучым!*

*Әгәр син дөньяда олы мәхәббәт яшәвенә ышанмасаң, бу китапны укып тормасаң да була. Көнеңә-төнеңә кояш бүләк итеп, җаныңа канат-куәт биреп, күңелеңә сандугач оялатып, гомер юлларыңда очып кына йөрергә көч биргән, изге, ләззәтле, шатлыклы саф мәхәббәткә ышанмасаң, укыма син аны. Якты дөньяда татлы, газаплы, җаның-тәнеңне сулкылдатып, хыял белән чынбарлык чикләрен юып, эш-гамәлеңдә рәхимлеккә, шәфкатьлелеккә, яктылыкка, югарыга өндәгән мәхәббәт булуына ышанмасаң, укыма.*

*Яшьме, картмы син, кызмы, егетме, әгәр дә кайчан да бер синең бөтен барлыгыңны кайнар сөю хисе җырлаткан, елаткан, зарыгып сагындырган, җирдән йолдызга чөйгән булса, укы.*

## Әнис алмалар

### 1

Алмагач яфраклары җылы җилдә әкрен генә тирбәлеп кыштыр-кыштыр серләшәләр. Бакчада хуш ис — өлгергән алма исе аңкый. Акация кузаклары чытырдап ярылып китә дә коры орлыклар җиргә коелыша. Башка вакытта кош-корт аларны чүпләп кенә торыр иде, тик балаларын канатка күтәреп, инде

тынычланган кошлар тук, исләре китми, канат-йоннарын, томшыкларын чистартып яфраклар арасында үзләре генә белгән шөгыльләре белән кайнашалар.

Әнис белән Илгиз икенче курс дәреслекләре алырга училище китапханәсенә килгәннәр иде. Чиста, саф һава тәэсиреннәнме, таш бинага кергәнче бераз алма бакчасындагы урындыкта утырып торырга ниятләделәр. Җылы, рәхәт. Зәп-зәңгәр күктә ак болытлар йөзә.

— Авылда бәрәңге ала башладылармы икән? Һава шулай коры торганда диюем.

— Юктыр әле, Илгиз. Иген эшләре бетмәгәндер шул.

— Кайтып булышасы иде дә бит. Дәресләрне калдырырга ярамый шул, Әнис. Рөхсәтсез киттеңме, Сафа абый каршына барып басасыңны көт тә тор. Әнис, сагынасыңмы, малай, ә? Авылны, дим.

— Быел алай ук үзәк өзелерлек түгел. Ияләшенә, күрәсең... Үткән е-ел!

— Ә мин һаман сагынам. Әле менә авыздан авылның сөтле аш тәме китеп тә бетмәгән, ә йөрәк пәрәвезгә эләккән күбәләкмени...

— Авылда кемең калды соң синең, Илгиз?

— Әнием. Күзләре бик начарланды. Әтинең үлгән хәбәре килгәннән бирле күзеннән яше кипми. Ничәмә-ничә ел бит инде.

— Әйе. Бик яраткандыр, күрәсең.

— Үзе дә шулай ди.

— Бер карасаң, гаҗәпләнерлек, сокланырлык бит. Кешене кеше шулай яратсын әле, ә! Нинди була икән соң ул андый ярату?

* * *

Әнис белән Илгиз бу әңгәмәләрен хәзер еш кына искә алалар. Аннан соң бер ел вакыт узса да. Икесенең дә яшьлек елларын кинәт килеп чыккан давыл сыман айкаган ел. Яшь күңелләренә тәүге кайнар сөю хисе килеп тулган ул ел нәнә шул кояшлы, җылы, матур, алмалы сентябрь көнендә башланды. Һич көтмәгәндә-уйламаганда онытылмас вакыйгалары белән мәңгегә хәтергә уелып калды.

## 2

Әнис тоткага кулын куйган гына иде, ишек кинәт ачылып китте дә аннан көлешә-көлешә берничә кыз килеп чыкты. Моны кинога төшерүче булса, ул Әниснең артка чигенеп, кызларны уздырып җибәргәч, кинәт кенә зур итеп ачылган күзләрен, гаҗәпләнгән йөзен эре планда озак кына күрсәтеп торыр иде.

Кызлар училище капкасыннан кереп киттеләр. Әнис ишек төбендә басып торды-торды да баскычка утырды. Үзен китапханәдә Илгиз көтеп торуын да онытты. Янында яшь егетләр, кызлар тыз-быз килеп кереп-чыгып йөрде. Училищега яңа кергәннәр кыяр-кыймас кына, тирә-якка карана-карана сак кына уздылар. Өлкән курснык ылар шап-шоп басып, ике-өч баскычны сикереп кенә төшеп киттеләр. Ә Әнис һаман утыра бирде. Аның күз алдында әле дә теге кызлар төркеме уртасындагы калын толымлы кызның ап-ак йөзе тора иде. Ул кызның күзләре урман аланындагы күкчәчәк кебек зәп-зәңгәр булып, үзләреннән бу дөньяда яшәү бәхете, яшьлек, сәламәтлек бәхете очкыннары чәчрәп тора иде. Кызның карашы Әнис йөзеннән битараф шуып кына узды, ә менә яшь егетнең күкрәк читлегендә кайнар ут кабызырга җитә калды. Ул уттан бөтен күкрәккә әллә нинди ләззәтле шом, очасы, йөгерәсе килү хисе таралды. Бу хис Әнискә бераз таныш иде. Урманга, болынга җиләккә баргач кып-кызыл җиләк баскан аланга килеп чыкканда нәкъ шундый хис туа, тик бу юлы ул кайнаррак, куәтлерәк, ләззәтлерәк иде. Шул көннән бирле Әнис юньләп ашау-эчүен дә онытты, йокысы качты. Дәресләрдә әллә утырды, әллә юк. Карашы еракка юнәлгән, кая карамасын, анда теге кызның ак йөзе, зәңгәр күзләре балкып торды, юан чәч толымнары чайкалды. Ул укытучыларның:

— Әнис, сиңа ни булды? Игътибарсыз утырасың. Мин әле генә нәрсә турында сөйләдем, — дигән соравын да ишетми иде. Андый чакта күршесе Вәгыйз Әниснең терсәгенә төрткәч кенә ул айнып китә дә:

— Гафу итегез, ишетмәдем шул, — дип җавап кайтара.

— Моннан соң дәрестә игътибарсыз утырма, — дип кисәткәч, Әнис чынбарлыкка әйләнеп кайта да гаҗәпләнә иде. «Мин дәрестә икән ләбаса. Тагын уйга талганмын. Тыңлап утырырга кирәк ич».

Дөньяда һәрнәрсәнең чиге була. Ниһаять, Әниснең дә чәбәләнеп беткән уйлары шактый вакыттан соң гадәти эзләренә төшә башлады. Күкчәчәктәй күзле, көләч йөзле бу кыз минем күңелемне юкка гына биләмидер дип уйлады ул. Аның мондый хәл турында укыганы бар иде. Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романында Галим Урманов та нәкъ шундый ук хисләр кичергән ич.

Тәнәфесләрдә Әнис ул кызны читтән генә күрә иде. Ятимнәр йортыннан килгән кызлар арасында йөргәнгә, Әнис аның да ятимә икәнлеген белде. Андый кызлар, егетләр бер үк төрле киемнән йөриләр.

Күкчәчәк күз дә нәкъ шулай, эти-әнисе юктыр, күрәсең. Бу уй исенә төшкән саен, аның йөрәге кысылып-кысылып куйды. Әй, шул кызны башыннан бер генә сыйпыйсы иде!

Көннәрдән бер көнне Әниснең бәхете басты. Ул зәңгәр күзнең исемен белде. Училищеның бик матур яшелчә бакчасында әллә ничә сортлы алма үсә, уңыш җыйган көннәр үзенә бер күңелле бәйрәмгә охшап кала иде. Андагы алма исе! Баллы хуш истән башлары әйләнепмедер, умарта кортлары, шөпшәләр өерләре белән очып йөриләр. Бакча укучылар тавышыннан гөрләп тора. Ул көннәрдә яшьләр белән бергә укытучылар да эшли, кара куе бөдрә чәчле, мәһабәт гәүдәле училище директоры үзе дә алма тулы әрҗәләрне арбага төяргә булыша, шаяртып та ала, яшьләр сүзенә кушылып, бәхәсләшеп тә куя. Аның шундый гадилеген укучылар да, укытучылар да ярата. Хәер, аны шәһәрдә белмәгән, ихтирам итмәгән кеше бармы икән? Алай гына түгел, район үзәгенә эш белән килгән авыл кешеләре дә, аны урамда танып:

— Исәнмесез, Нәсихов абый, сау-сәламәт яшисезме? — дип, әллә каян каршына чыгалар.

Педагогия училищесының даны бөтен республикага таралган иде шул. Ә аның белән озак еллар буена мәгариф отличнигы Сафа Нәсихов җитәкчелек итте.

Һәр эшкә куллары ятып торган авыл егетләре-кызларына алма җыю эшмени ул. Ә мондый күмәк эшне әйткән дә юк. Директор, укытучылар алдында бигрәк тә. Быел алма бик мул булып уңган, укучылар аны әрәм-шәрәм итми, бәрми-сукмый, сак кына өзеп, әрҗәләргә тутыралар, аннары складка киштәләргә илтеп куялар. Кышка хәтле ашарга да, кышын ашханәдә компот кайнатырга да җитәчәк бу кадәр алма. Әнә директор үзе шулай ди.

Ерак түгел иптәшләре белән теге кыз да баскычка менеп алма җыя. Әнис аны күзе белән генә түгел, йөрәге белән күрә. Әй ул кызның көлүләре! Көмеш кыңгыраумыни! Бу тавыш Әнис күңеленең әллә кайсы почмакларына үтеп керә. Егет борылып карый да әрҗәсен күтәрергә оныта.

Курсташы Илгиз:

— Әнискә бу әрҗә авыр булды, ахрысы. Әйдә, үзем җилкәңә күтәреп куйыйм әле, — дип, әрҗәгә тотына.

Әнискә шушы әрҗә авырмы? Тирә-юнендәге курсташлары алдында кешедән күтәртәме! Ул әрҗәне җирдән йолкып алгандай өскә чөя, тик тигезлеген югалта, чайкалып, әрҗәсен чүт кенә төшереп җибәрми. Өстә яткан алмалар җиргә коела. Кемдер көлә. Кызлар, «ах» дип, укытучылар, директор ягына карап алалар. Әнис, башын күтәрергә оялып, җирдән алма җыя башлый. Аның бит очлары кулындагы алмалардай кызарып чыга. Башында һаман бер уй бөтерелә: теге кыз да күрдеме икән? Ә укытучылар ни әйтер?..

Тәҗрибәле рус теле укытучысы Ләйлә апалары Әниснең хәлен аңлый:

— Зарар юк, укучылар, саграк кына булырга кирәк, — дип, киеренкелекне юк итә. — Алмалар бозылмас, йомшак җиргә коелды ич. — Әнис рәхмәтле елмая, аның күкрәген баскан авыр таш ереп юкка чыга.

Шул мәлне якында гына алма җыючы кызларның ачы итеп кычкырганы ишетелде. Теге Күкчәчәк күз үрелеп алма алганда баскычы авып киткән икән, ә үзе ботакка асылынып калган да:

— Булышыгыз инде! — дип кычкыра иде.

Моны күргәч, Әнис шул якка томырылды. Башка егетләр дә ярдәмгә йөгерделәр. Ә бакыр чәчле Идмасны гына күр әле! Барып та җитте, тиз генә баскычны торгызып та куйды. Менде, кызны күтәреп баскычка бастырды, кулыннан тотып төшәргә булышты.

Кызларның кайсыдыр:

— Әнисә, кулың сыдырылган ич, әйдә, йод сөртик, — дип, кызны училище медпунктына алып китте.

Әнис, дөрес ишеттемме икән дип, тирә-ягына каранды. Әнисә диделәр түгелме? Әйе шул. Исеме Әнисә икән, алайса. Ничек була соң инде бу? Ул үзе Әнис. Кызык. Әнис моңа бер шатланды, бер гаҗәпләнде. Гаҗәп шул. Ничек туры килгән. Әнис — Әнисә. Хәер, бу дөньяда эти-әниләре охшаш исем кушкан кешеләр әзмени? Тик исемнәре охшаш кешеләрнең менә шулай очрашуы анысы инде аның бер Ходай эше. Димәк, бу кыз Әниснең адашы була.

Шул ук вакытта Әниснең йөрәген әллә каян пәйда булган икенче уй тырнап өлгерде. Нишләп Әнисә янына иң алдан ул үзе түгел, ә бакыр баш Идмас барып җитте? Өлгеррәк булса, Әнисә Идмаска түгел, ә Әнискә рәхмәт әйткән булыр иде. Ә шулай да егетнең күңеле күтәренке иде. Күкчәчәк күзнең исемен белде бит ул. Әнисә диген, ә?!

## 3

Әнис Әнисәне ялгыз гына очратырга бик озак җай эзләп йөрде. Үзе бу бәхеткә ирешсә, ничек сүз кушасын, нәрсә әйтәсен дә белми иде. Шуңа күрә Әнисәне ялгыз түгел, ә дус кызлары арасында күргәч, шатланып та куя иде.

Октябрь бәйрәменә училище ныклап әзерләнә. Укучылар демонстрациягә чыгып, райком бинасы каршыннан узалар. Анда аларга Ленин һәйкәле төбендә басып торган район җитәкчеләре кул болгый, кемдер радиодан:

— Педагогия училищесы студентларына сәлам! — дип кычкыра. Үзләрен «студент» дип атагач, горурланып, яшьләр бөтен урамны яңгыраталар:

— Ур-р-а-а!

Бәйрәм алдыннан училищеда зур концерт була. Рус бүлеге чыгышын татар бүлеге карый, татар бүлегенекен — руслар. Музыка коралларында уйнарга өйрәнүчеләр, ялгыз җырлаучылар дер-дер килеп үз чиратын көтә. Аннары биюләр. Актлар залы ак кофта кигән, ак алъяпкыч япкан кызларның, галстук тагып җитдиләнеп киткән егетләрнең шау-шуыннан гөрләп тора. Ни итсәң дә, бәйрәм, ни итсәң дә, яшьлек бит.

Быелгысы Әнискә икеләтә бәйрәм булды. Оркестрда берничә әсәр уйнап сәхнәдән төшкәч, Әнис алдагы рәтләрнең берсендәге буш урынга барып утырды. Утырган гына иде, күршесендәге кыз:

— Бу урын буш түгел, — дип пышылдады.

Әнис кызга борылып караса, янәшәсендә Әнисә иде.

— Бу минем дустым урыны. Әнә үзе килә, — диде ул.

— Егеткәй, бушатыгыз әле минем урынны, — дигәч, Әнис янында басып торган рус кызына күтәрелеп карады. Торырга гына онытты.

— Нәрсә, егеткәй, күргәнең юкмы әллә? Шулкадәр текәлеп торасың? — Әнисә Әнискә карап көлеп җибәрде.

Әнис шунда урынлы-урынсыз:

— Син Әнисә бит. Ә мин Әнис, — дип пышылдады да торып китте.

Бу көннән соң ул шактый вакыт канатланып, ниндидер эчке рәхәтлек тоеп, әллә нинди үзгәрешләр көтеп йөрде. Әйтте бит ул үз исемен Күкчәчәккә, әйтте. Димәк, таныштылар. Тик үзгәреш кенә булмады. Әнисә, иптәш кызлары белән әле китапханәдә, әле коридорда сирәк кенә очраштыргаласа да, битараф кына уза бирде. Әниснең андый көннәрдә бигрәк тә җаны кыйналды. Ничек инде танышканнан соң да ул аңа борылып та карамый? Әллә бар аңа Әнис, әллә юк. Хәер, ул хаклыдыр да. Шундый матур кыз игътибар итәрлек кем соң ул? Кием-салымы ташка үлчим. Училищеда Сафа абый урнаштырган нык тәртип хөкем сөрә. Ямаулы киемеңне тулай торакта кисәң ки, ә училищеда гади генә булса да үтүкләнгән костюм-чалбардан йөр. Күлмәгең һәрчак чиста, юылган булсын. Муеныңа галстук — мәҗбүри. Аяк киеме турында әйткән дә юк. Ул һәрвакыт чиста булырга тиеш. Вакыт-вакыт директор, яз дими, көз дими, ишек төбендә үзе басып тора, өс-башыңны, аяк киемеңне тикшерә. Бар теләге — булачак укытучыны пөхтә киенеп, чиста йөрергә өйрәтү.

Балалар йортыннан килгән ятимнәрне училище ашата-эчертә, киендерә. Моны тәрбиячеләр игътибар үзәгендә тота. Аларның киемнәре әнә нинди матур. Җылы йон свитерлары гына да ни тора. Тереләк егетләр тәрбиячеләрдән өс-башларын яңартып торуны үзләре үк таләп итә. Тиешме — бирегез! Ә Әниснең нәрсә? Узган ел яз көне юл өзегендә ул училище коридоры буйлап кызыл эчле зур галош сөйрәп йөрде. Тула оегын салгач. Моны күргән кызлар бик мәгънәле итеп бер-берсенә карап калалар иде.

Ярый әле быел аңа эти-әнисе, сарыкларын сатып, зур авырлык белән ботинка, яңа чалбар, күлмәк алып бирә алдылар. Юк инде, юк, аның өс-башы ятимнәрнекеннән бик калыша. Җитмәсә, кара куе чәче түбәсендә тырпайган. Сулап тарасаң да һаман шул. Озынрак йөртсәң ята ятуын, тик рөхсәт юк. Директор күрдеме — алдыр. Син булачак укытучы!

Соңгы вакытта Әнис үзенең куе кара кашларын башкаларныкы белән чагыштыра да кәефе кырыла. Башкаларның әнә сызып куйганмыни! Ә аның тоташып үскән диярсең. Дөрес, тешләре тип-тигез, ялт иткән. Бу борын тагын. Нәкъ кызларныкы. Ир кеше борыны тотрыклы, күзгә бәрелеп торырга тиеш, диләр. Ә иягең чокырлы булырга. Бугаз төене нинди калку, җитмәсә. Ашаганда аска-өскә уйнаклап тора. Күзләргә килгәндә — гел мәсхәрә! Әле соры, әле яшькелт төскә керә. Ир буласы кешедә шундый күз булсын инде, әй! Әнисә аңа игътибар итәме соң. Аның күзләре — күкчәчәкләр. Эх!

Кая гына бармасын, ни генә эшләмәсен, аның күз алдында һаман Әнисә. Алтынсу толымлы күкчәчәк күзле Әнисә. Аңа игътибарсыз чибәр Әнисә. Йә, күпме йөрергә була инде болай? Юк, ничек тә күрергә, сүз катып карарга кирәк үзенә. Менә шул!

## 4

Күрде ул аны, күрде. Күрмәсә, яхшырак та буласы икән. Училищеның физкультура залы яныннан үтешли, Әнис анда шау-гөр килгән тавышка игътибар итте. Егетләр, кызлар көлешә-көлешә нидер сөйләшә

иде. Әнис ишекне ачып залга күз салды. Анда... анда... трусик-майка гына кигән бер төркем егетләр, кызлар Әнисәнең калын чәч толымнарын башына чорнап маташалар иде.

Берсе:

— Бэйләргә кирәк, бәйләргә. Чәчең сиңа сикерергә дә, мәтәлчек атарга да комачау итә, — ди.

Икенчесе:

— Бәлки, кистерергәдер. Ярышлар җитә. Ә безнең әле һаман ике-өч күнегү өйрәнеп бетергәнебез юк, — ди.

Әниснең курсташы Марс, аның ишектән карап торганын күргәч:

— Әнис, әллә син дә безнең акробатика түгәрәгенә керәсеңме? Уз әйдә, — диде.

Барысы да Әниskә борылып карадылар.

— Юк, юк! — Әнис, каушап, тиз-тиз ишекне япты да китапханәгә менеп китте. Кирәкле китаплар алып, уку залына кереп утырды. Укыса укыды, укымаса — юк. Аның күз алдында һаман баягы күренеш иде: егетләр, кызлар Әнисәне сарып алганнар да бөтерелепме-бөтереләләр. Тукта әле, нишләп ул, укуга бирелеп, шундый эшләрдән, түгәрәкләрдән читтә йөри соң? Дөрес, узган ел училище оркестрына язылып, альтта, контрабаста ару гына уйнарга өйрәнде. Бәйрәм кичәләрендә әнә ничек шәп уйныйлар. Юк, болай булмый бу! Аны бит чаңгы түгәрәгенә язылырга чакырганнар иде. Тик анда күнекмәләр еш кына ял көненә туры килгәнгә ул риза булмады. Языла да йөри ул моннан соң. Күнекмәләргә дәрестән соң, кичләрен дә чыгарга була ич. Авылга да чаңгыда кайтып-килеп була. Бу да күнекмә ләбаса. Нинди генә әле.

Әнис физкультура укытучысына теләген белдерде, күнекмәләргә йөри башлады. Аның тырышлыгын күреп, директор рөхсәте белән чаңгыларны, ботинкаларны тулай торакның бер караңгы бүлмәсендә тотарга рөхсәт иттеләр. Башкалар күптән шулай итә икән ич. Буш вакыт табуга, чаңгыларын киеп йөрергә чыгып китәләр. Әнис тә алардан калышмаска тырышты. Шунысы гаҗәп, ул бу түгәрәккә йөрү укырга комачау итәр дип борчылган иде. Ялгышкан икән. Әнис хәзер кайчан дәрес әзерлисен, кайчан күнекмәгә чыгасын бик төгәл белә, төгәл үти. Училищеның чаңгы ярышында ул икенче урынга чыкты. Шатлык өстенә шатлык, аны училищеның җыелма командасына алдылар. Күнегүләр тагын да куәтләнде.

Тормыш Әниснең борчулары бар дип туктамады, чапты да чапты. Беренче семестр азагы якынлашып, имтиханнар бирер вакыт җитте. Училищеда имтихан имтихан гына түгел иде шул. Берәр фәннән өчле алдыңмы, стипендия алмыйсың. Ә ансыз ничек укыйсың? Әти-әнисе таза тормышлы егет-кызлар гына монда стипендиясез укый. Авылдан килгән яшьләрнең күбесенә рус теленнән инша язу бик авыр. Ярый ла имтиханда таныш, инде бер кат язган тема туры килсә. Югыйсә эш харап! Шуңа күрә семестр дәвамында укучылар берничә инша язалар. Аларны укытучылар яхшылап тикшерәләр, төзәтәләр. Аннары инде ул текстны укучылар өтеренә кадәр яттан өйрәнәләр. Имтиханда шул темаларның берәрсе чыкса, яшьләрнең шатлыгы эчләренә сыймый. Бишле булмаса, дүртле алу мөмкинлеге туа. Ә бу инде стипендия алып укуыңны дәвам итә аласың дигән сүз. Әнис имтиханнарны яхшы билгеләренә генә тапшырып бетерде.

**5**

Гыйнвар ахырында район беренчелегенә чаңгы ярышлары оештырдылар. Анда урта мәктәп укучылары, комсомол оешмалары спортчылары, училищеның җыелма командасы катнашты. Бөтен шәһәр гөр килеп торды. Ун чакрымлы эстафетада училище чаңгычылары җиңеп чыкты. Шәхси күрсәткечләр буенча Әнис иң беренче иде. Егетләргә директор Сафа абыйлары рәхмәт белдерде. Район ДОСААФ комитеты аларны икенче дәрәҗәле спортчы исеменә лаеклы дип, республика комитетыннан күкрәк билгеләре соратып алды. Зәңгәр төстәге бу билгеләрне тапшыру бөтен училище җыелышында тантаналы төстә узды. Комитет карарын укуны Әнисәгә тапшырганнар икән. Директор иң беренче сәхнәгә Әнисне чакырды, рәхмәт әйтеп аның кулын кысты. Әнисә дә, Әниснең кулын кысып: «Котлыйм!» — дип, чәчәк тоттырды. Аның кулы никтер ут кебек кайнар иде. Әнис рәхмәт әйтергә дә онытып сәхнәдән төшкәндә чүт кенә егылмый калды, аның тез буыннары бушаган иде.

Семестр имтиханнары бетүгә, чаңгычылар командасын февральдә каникул көннәрендә узачак республика ярышларына әзерли башладылар. Тренировкалар тагын да ешайды. Егетләр чаңгыларын, ботинкаларын, беркеткечләрен кат-кат карадылар, чаңгы майлары сайладылар. Тик Әнис, ни кызганыч, Казанга бара алмый калды. Иртәгә иртән юлга чыгарга дип торган кичне ул тагын йөреп килим әле дип чаңгылар кигән генә иде, урам уртасында ук аның бер чаңгы беркеткече шартлап сынды. Аның сыныгын алып караган иде, үз күзенә үзе ышанмады. Кемдер аны, әллә кисеп, әллә йомшатып, эштән чыгарып куйган иде. Бер төн эчендә яңа беркеткеч, яңа ботинкаларны каян табасың инде? Бу хәлгә соңрак директор да, физкультура укытучысы Алексей Кузьмин да бик нык гаҗәпләнде. Команда Казанга Әниссез генә китеп барды. Әнис каникулга авылга кайтып китте. Кайтуын кайтты, тик икенче көнне үк аның йөрәге

сабантуйдан кайткан аттай тасырдый башлады. Хәзер Әнисә кайда йөри икән, нишли икән, кемнәр белән аралаша икән, дип уйлады ул. Уйларыннан арынып торыр өчен егет ярсып-ярсып утын ярды, кар көрәде, чанага фляга куеп су ташыды, әти-әнисенең вак-төяк эшләренә булышты. Ә шулай да йөрәген тыпырчынырга мәҗбүр иткән уйларын читкә куа алмады.

...Ниһаять, каникулның соңгы көне дә килеп җитте. Бербөтен түгәрәк ипи, атланмай тутырган кечкенә банканы биштәренә салып, Әнис тагын район үзәгенә юл тотты. Февраль көне шактый салкын, буранлы булса да, ул тирләп-пешеп шәһәргә атлыга, ә йөзендә елмаю уйный иде.

**6**

Ул елны май бик җылы килде. Егетләр, бушрак вакыт табып, Бизнә елгасына су коенырга баргаладылар. Елга училищедан ерак түгел матур бөдрә таллыкларны аралап ага иде. Егетләр аның тирән урынын беләләр, шактый биек басмадан сикереп чумалар, кайчакта су астыннан йөзү буенча үзара ярышып та алалар иде. Вакыт-вакыт монда килеп шәһәр балалары да су керә, аларның чыр да чу килеп коенуларын, уйнауларын карап тору үзе бер күңелле иде.

Көннәрнең берендә, Әнисләр комда кызынып, шәһәр малайларының басмадан сикереп уйнаганын карап ятканда, кием-салымы белән ун-унике яшьлек бер малай суга егылып төште. Ул сикерергә җыенган иптәшен сизмәгәндә артыннан килеп куллары белән этеп төшерәм дигәндә генә тегесе алданрак сикерде. Шаян малай туктала алмыйча аның артыннан ук үзе дә суга чумды да куркуыннан бата башлады. Аның, тончыга-тончыга: «Ярдәм итегез!» — дип кычкыруына Әнис суга ташланды. Коты алынган малайны, авырлык белән булса да тирәннән алып чыгып, сай җиргә бастырды.

Берничә көннән училищеда, иртәнге музыкаль зарядка беткәч, барлык укучылар алдында директор Әнискә рәхмәт әйтте, чын егетлек менә шундый була ул, дип мактап алды. Бу эш директорга ничек мәгълүм булгандыр, Әнис моны белмәде. Ул шунысына шатланды, теге көннән соң училище кызлары аңа елмаеп уза башладылар. Әнисәнең күкчәчәк күзләрен тутырып елмаюы Әнисне аеруча куандыра иде.

Май аеның соңгы матур көннәренең берсендә училище укучыларын Чулман култыгы яры буена баржадан утын бушатырга алып чыктылар. Училище утын белән җылытыла иде.

Баржаны бушатырга бер генә көн бирелгән икән. Чулманга кадәр алты-җиде чакрым барасы, аңа чаклы шәһәр кырыеннан ук аккан Бизнәне кичәргә кирәк иде. Менә шунда инде Әнискә бәхет кояшы елмайды. Ул көймәдә йөри белә иде. Әнә ул биш-алты кешене утырта да елганың аргы ягына чыгарып куя. Аннары кире килә. Әнискә шулхәтле рәхәт, чөнки чират көтүчеләр арасында Әнисә дә бар. Кызлар чыр-чу килеп сөйләшәләр, Әнис бар көченә ишә дә ишә. Бу бәхетле минутларның ул озаккарак сузылуын теле. Күкчәчәк аның бу якка чыгып җитәр алдыннан көймәне, зырылдатып борып, яр кырыена койрыгы белән оста итеп китереп туктатканын күрә. Яшьләр кереп утыргач, көймәне берәрсе этеп җибәргәнне дә көтми, Әнис янә ишә башлый.

Егет Әнисәнең яр кырыенда озаграк торуын теле: менә күреп торсын әле Әниснең осталыгын! Ниһаять, Әнисә дә иптәш кызлары белән көймәгә кереп утырды. Әнис янә ишкәкләргә ябышты.

— Әнис, сине егетләрнең берәрсе алыштырсын иде. Тирләп-пешеп чыккансың бит. Арыгансыңдыр. Ишә белүчеләр бардыр бит?!

Укытучы апаларының бу сүзенә Әнис:

— Юк-юк, Ләйлә апа, арымадым, — дип, ишүен тагын да кызулата төште. Аннары көймәдән чыгучыларга ярдәм итте.

Әнисә ярга чыгарга гына торганда, аннан алдан сикергән кыз көймәне чайкалдырып җибәрде. Әнисә «ой, мама» дип куркып калды. Әнис сикереп торып аңа кулын сузды, ярга чыгарга булышты. Әнисә елмаеп рәхмәт әйтте. Күкчәчәкнең ягымлылыгыннан рухланып, Әнис тагын иште дә иште. Соңгы укучыларны көймәдән төшергәндә, ул уч төпләренең кызып әрнегәнен тойды. Аның ике кулының да учы берничә урында чикләвек зурлыгында кабарып чыккан иде.

Укучылар, көне буе эшләп, баржаны кичкә бушатып бетерделәр. Ул арада кара төтен бөркеп килгән буксир баржаны алып та китте. Яр буенда әрдәнә-әрдәнә утын өелеп калды. Алгебрадан имтиханга ике көн кала Әниснең уң кулы бик каты сызлый башлады. Кулның кабарган урыннары кызгылт-сары сыекча белән тулган иде. Әнис аны каләм очы белән тишеп агызды, сызлау тынып торган сыман булды, ләкин бераздан уң кулы кызарып шешә башлады.

Авыртуга түзә алмыйча, Әнис ишекле-түрле йөрде. Ятты, торды, стаканга салкын су салып, бармакларын шунда тыгып җиңеллек эзләп карады. Төннәрен аңа аеруча авыр булды. Малайлар йоклый, ә аны йокы алмады. Шулай бимазаланган беркөнне кичен вакытлы-вакытсыз йокыга талды. Шул чакны

тулай торак бүлмәсенә профсоюз бюросы әгъзалары килеп керде. Йоклап яткан Әнисне күргәч, алар гаҗәпкә калды.

Арадан берсе:

— Нишләп әле ул бу вакытта йокы симертә? — дип, кашын җыерып, аның янына килеп басты. Әниснең бүлмәдәш малайлары хәлне аңлатып бирделәр. Бюро әгъзалары моны ишеткәч, табибка күрсәтергә кирәк дип, Әнисне уятырга тотындылар. Әнис аңгы-миңге килеп торып утырды да берни аңламый кызларга текәлде. Алар арасында читтәрәк басып торган Әнисәгә күзе төшкәч, сикереп тормакчы иде, кулы карават кырыена бәрелде. Аның күзләреннән утлар чәчрәде, күпереп шешкән учының авыртуына түзә алмыйча бөгелеп төште. Кызлар аһ-ваһ килеп аны сарып алдылар.

— Кая, күрсәт әле!

— Нишләп табибка бармадың?

— Малайлар, ә сез ни карадыгыз?

— Кулы кып-кызыл булып шешкән ләбаса!

— Җаныкаем гына, ничек түзәсең, ә?

Монысын Әнисә әйтте. Ул Әниснең кулын әйләндереп-әйләндереп карады да, хәзер үк шәһәр хастаханәсеннән табиб чакырырга кирәк, диде. Башкалар да, моның хәвефле бетүе мөмкин бит, дип, Әнисә сүзен куәтләделәр. Ул арада Илгиз хастаханәгә чыгып йөгерде.

Нечкә күңелле Әнисә һаман бер сүз кабатлады:

— Миленький, ничек болай булды соң бу? Ничек түзәсең?

Малайлар, теге көнне көймә белән укучылар ташыганда аның учлары кабарган булган, ә ул кабарчыкларын каләм белән тишкән икән, диделәр.

— Алайса, каны бозылуы ихтимал лабаса! Эх, сез!

Әнисне дәваланырга хастаханәгә салдылар. Егетләр, кызлар хәл белергә аның янына еш килеп йөрделәр. Уколлар, дарулар ярдәм итте, Әнис хастаханәдән савыгып чыкты. Егетнең бу көннәрдә күңеле тагын да күтәренке иде. Бердән, савыкты, икенчедән, килгән кызлар арасында Әнисә дә бар иде. Авырып алгебрадан бирә алмый калган имтиханы өчен ут йотып ятканда, укытучы Халидә Хәкимовна аңа ел барышында алган билгеләре буенча дүртле билгесе чыгаруын әйтеп китте. Димәк, Әнис стипендия алмаучылар исемлегеннән төшеп калмады. Ә иң куанычлысы — Әнисәнең «миленький», «җаныкаем» дигән сүзләре колак төбендә һаман яңгырап тора иде.

## 7

Булачак укытучылар училищедан йөз төрле эшкә өйрәнеп чыгарга тиеш. Аларга училищеның яшелчә, җиләк-җимеш участогында «Авыл хуҗалыгы нигезләре» буенча практика узу да мәҗбүри. Анда һәр укучы яшелчә үстерергә өйрәнә. Җаның кайсын тели. Эш кораллары, төрле-төрле ашламалар бирелә, биология укытучысы киңәшләр белән ярдәм итә.

Әнис үз участогында помидор үстерергә алынды. Җирне казыганда ук органик, минераль ашламалар кертте. Помидор үсентеләрен сирәкли-сирәкли кадерләп үстерде, аннары аларны җиргә күчерде. Дәресләр бетүгә, участокка помидорларына су сибәргә йөгерде. Күтәрелә төшкән саен, томат сабакларын таякларга бәйли торды. Укытучы ярдәме белән яфрак төбеннән борынлап чыккан ян үсентеләрне өзеп ташларга өйрәнде. Үсемлекләренә ашламаны вакытында, тиешенчә кертте. Кайбер укучылар суда җебетелгән сыер, кош тизәге мичкәсе янына да килергә җирәнсәләр, авыл малае Әнис тартынып тормады, үсентеләренә шул файдалы ашламаны да күпләп сипте. Нәтиҗәдә помидор сабаклары юан, яфраклары яшькелт-кучкыл булып ябалдашланып үстеләр. Җәйнең эссе көннәрендә беренче помидорлар кызарып пешә башлады. Аларны өзеп алгач, үлчәп, практика җитәкчесенә тапшырырга кушылган, теләгән кешегә шуннан соң үзенә дә алырга рөхсәт бирелгән иде.

Әнис, уңыш өлгерә барган саен, кып-кызыл сусыл эре помидорларын ашханәгә тапшыра барды. Җәйге каникулда да авылдан килеп ике атнадан артык үз участогында эшләде, килә алмаган укучылар участокларында да көчен кызганмады. Тырыш хезмәт нәтиҗәсе бик матур булды, Әнис нормадан өч мәртәбә артыграк уңыш алды. Моны ул һич көтмәгән иде.

Шатлык өстенә шатлык: аны Мәскәүдәге Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә юллама белән бүләкләделәр. Ә иң куандырганы — шундый ук юлламага кыярдан югары уңыш алган Әнисә дә лаек булды. Юлламада «Павел Бажов» пароходында Горький шәһәреннән Мәскәүгә хәтле барып, шул ук маршрут белән кире кайтырга диелгән иде. 20 августта алар Горькийга чыгып киттеләр. Көтмәгәндә килгән бу бәхеттән түбәсе күккә ашкан Әнис кызга бик игътибарлы булды, чемоданын күтәреп йөрде, иртә-кичен ашханәгә чакырды. Әнисә баштарак читләшебрәк йөрсә дә, тора-бара экскурсияләрдә

күбрәк аның белән булды. Бу Әниснең иң бәхетле көннәре иде. Ниһаять, ул Әнисә белән күрешә, сөйләшә ала. Идел буе шәһәрләре Ярославль, Кострома, Кинешма, Углич, Владимирда алар бергәләп фотога төштеләр. Әнис җае чыккан саен кызны туңдырма белән сыйлады, әле дә ярый җәйге айлар өчен стипендия биргәннәр иде.

Мәскәү ай-һай нинди зур шәһәр икән! Андагы машиналар тагын! Күргәзмәдәге экспонатлар, халыклар дуслыгына багышланган алтынсу скульптор композицияләрнең матурлыгы дисеңме! Яңа төзелә торган Мәскәү университетының мәһабәтлеге, зурлыгы дисеңме! Аның студентлар өчен уңайлыклары! Университет диварындагы сәгать эченә ике катлы йорт сыя икән ләбаса. Сталинга бирелгән бүләкләр музее турында сөйләп тә торасы юк. Андагы нәни генә дөге бөртегенә язылган хат, әллә ничә төрле агач кисәкләреннән ясалган шахмат тактасы, алтын йөгертелгән вазалар, юлбашчының шәхси әйберләре, аңа чит ил җитәкчеләре биргән бүләкләр Әнис белән Әнисәнең хәтеренә мәңгегә уелып калды.

Пароходта булган ике вакыйга аларны шактый якынайтты. Әнисәнең чибәрлегенә тасраеп караучылар монда да күп очрады. Шуларның берсе пароходта эшләүче матрос иде. Әнисләр утырганның икенче көнендә үк ул бик матур формасын киеп йөри башлады. Әнисәне күргән саен: «Сәлам, гүзәлем!» — дип кычкырып узды. Биюләр, концертлар оештырылган көннәрдә гел Әнисә янында бөтерелергә, кино залында якынрак утырырга тырышты. Ә беркөнне вахтасыннан буш чагында аны үз каютасына кунакка килергә кыстады. Моны күреп, Әнис ачуыннан нишләргә белми йөрде. Хәер, Әнисәнең тапкырлыгы мәсьәләне тиз хәл итте. Беркөнне алар палубадан Идел ярларын карап барганда теге матрос тагын килеп бәйләнде, Әнисәне җилкәсеннән кочаклап:

— Моя красавица! Мин бит сезгә гашыйк булдым. Сез игътибар да итмисез. Мин фәкыйрегезне кызганыгыз, — дип үбәргә үрелде.

Әнисә, аның кочагыннан җитез генә ычкынып:

— Отстаньте! Менә минем боксер егетем! — диде, сикереп торган Әнискә күрсәтеп. — Югыйсә... Мин капитаныгызга барып әйтергә дә күп алмам.

Син күр дә мин күр, матростан җилләр исте. Моннан соң ул аларны очратса да күрмәмешкә салышты.

— Егетем дигәнгә ачуланмыйсыңмы, Әнис, — диде Күкчәчәк күз. — Тозсыз күзләрен акайта да килә, акайта да килә бит.

— Егетең булырга мин бик тә шат булыр идем, — диде Әнис, тик тукталып калды. Аның колагында теге матроска әйтелгән «отстаньте» сүзе яңгырый иде. Әнисә моңа елмаеп куйды.

Ә беркөнне Әнис парикмахерскийга кереп җәй буена «под польку» үстергән чәчен кыска гына «под бокс» алуларын сорады. Чәч алучы кыз каршы килде:

— Шаяртасызмы әллә? Шундый матур чәчнеме? Юк-юк, мин аны бозмыйм.

— Тагын үсә лә ул. Алыгыз, — диде аңа Әнис. Мондый озын чәч белән училищега кайтып керсәң, директор кирәгеңне бирер, дип уйлады. Аның әтисе дә бит: — Аны кыска гына йөртергә ярамыймыни, — дигән иде.

— Әллә чәчегезне картада оттырдыгызмы, ә? Ял итүчеләр бездә әллә ниләр китереп чыгаралар.

— Юк-юк, сез ни сөйлисез. Әйдә, алыгыз инде. — Әнис үз сүзендә торды.

— Юк, — дип киреләнде чәч алучы кыз. — Сезне мин монда калын толымлы матур күзле бер кыз белән күрәм. Кызыгыз ни әйтер бит?

Әнискә бу кызык тоелды. Дөрестән дә, Әнисә ни әйтер икән?

— Үзен алып килимме әллә?

— Алып килегез.

Әнис Әнисәне каютадан чакырып чыгарды да парикмахерскийга алып китте. Чәч алучы кыз аңа да зарланды:

— Менә егетегез чәчен боздырырга тели. Ничек уйлыйсыз? Нинди чәч бит, нинди чәч!

Әнисәнең көмеш кыңгыраулы тавышы бүлмәне яңгыратты. Училищедагы тәртипне белә ич ул.

— Егетемнең теләгенә мин каршы килә алмыйм. Бу аның үз эше, — диде ул. Ә үзе Әнискә сынаулы караш ташлады.

Кыз, ризасызлыгын чыраена чыгарып, чәчне ала башлады. Үзе һаман ах та ух килде. Шунысы кызык, Әнисә чыгып китмәде, карап утырды. Эш беткәч:

— Менә хәзер чын авыл малае булдың, — дип көлеп куйды.

— Авыл малае булгач, нишлисең бит...

Авыл малае искиткеч шат иде. Менә Әнисә тагын «егетегез» дигән сүзгә битараф калды. Әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә игътибар итмәде. Егетем түгел, димәде. Моңа тикле ул Әнисәгә авылдагыча, әйдә, дус булыйк, дип тәкъдим итәргә ниятләп йөргән иде. Хәзер аңлады, алай кирәкми икән ич. Әйтмичә дә дус булып була икән.

Бу күңелле сәяхәттән алар тәэсирләргә бик баеп кайттылар. Уку башлангач, укучылар төркемнәре аларны:

— Башкала нинди ул? Матурмы? Метрода йөрдегезме?

— Сталинны күрмәдегезме?

— Мәскәүлеләрнең өс-башлары нинди?

— Шлюзлар «Яшь сталинчы»да язылганча матурмы?

— Мәскәүдә татарлар яшиме? — дип аптыратып бетерделәр.

Сәяхәтчеләр алып кайткан открыткаларын күрсәтеп, белгән-күргәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр.

Аларның аралары якынайганнан-якынайды. Әнис киноларга чакыргач, Әнисә, күкчәчәктәй күзләреннән нур балкытып, риза була иде. Алар хәзер еш кына уку залына да, училищеда, шәһәрдә уздырылган концертларга, спектакльләргә бергә йөрделәр.

Беркөнне Әнисне Сафа абыйлары кабинетына чакырып алды. Үзе бик яхшы белеп торса да, аннан ничек укуын, эти-әнисе хәлләрен сораштырды. Аннары:

— Әнис, күрәм, сез Әнисә белән бик дуслашып киттегез бугай. Син аның ятимә кыз икәнен беләсеңме? — диде. — Беркеме дә юк бит.

— Беләм, Сафа абый, — диде аңа Әнис. — Сөйләде. Күңеле китек чакларын да чамалый башладым.

— Шул-шул. Сиңа артык ияләшеп, егет белән кыз арасындагы чикне уза күрмәгез. Бу бигрәк тә сиңа, егет кешегә кагыла. Аңлыйсыңмы?

Аңлады Әнис, аңлады. Кызарып, оялып китте.

— Мин аның кулыннан тотарга да оялам бит, Сафа Гыйлаҗетдинович, — диде ул. — Честное комсомольское. Ул үзе дә бик тыйнак. Борчылмагыз.

Бу сөйләшүдән соң күп тә үтмәде, Әнис Күкчәчәкнең үзенә мөнәсәбәтен белде. Авыл малайларын кем биергә өйрәтә соң инде. Училищеда биюләр оештырганда, Әнис танцыларда читтәрәк йөри, краковяк шикелле җиңелрәк биюләргә генә катнашкалый иде. Башта малайлардан күреп, ул да батырчылык итеп, училищеда укучы Людмила исемле кыздан биергә өйрәтүен үтенде. Кыз риза булды, дәресләрдән соң калып, Әнисне биергә өйрәтә башлады. Беркөнне, алар буш класста вальс әйләнергә өйрәнеп торганда, ишектә Әнисә күренде. Аның йөзе үзгәреп китте, ул ишекне япты да китеп барды. Шул көннән соң ул Әнискә күренмәскә тырышты, чакырса да чыкмады. Әнис, ниһаять, аның акробатика түгәрәгеннән бушаганын көтеп алды да:

— Әнисә, сиңа ни булды? Теге көнне кинога билет алып килгән идем. Шәһәрдә «Чал чәчле кыз» исемле кытай фильмы бара. Син чыкмадың да, — диде.

— Кинога йөрергә кеше тапкансың бит инде. Людмилаң ни дияр? — Әнисәнең тавышы калтыранып чыкты.

— Ул бит мине биергә генә өйрәтә. Үзем үтендем.

— Ә мин өйрәтә алмас идемме? — Әнисә шундый үпкәле караш ташлады, Әнис барын да аңлады.

— Гафу ит, бетте. Син өйрәт алайса. Минем бит сине борчыйсым килмәде. Людадан мин гафу үтенермен, — диде ул.

...Тормыш такыр юл түгел, вакыт-вакыт анда сикәлтәләр дә очрап куя. Көз көне күрше колхозга бәрәңге алырга булышырга баргач, Идмас белән Әнис арасында низаг килеп чыкты. Әнискә ат җигеп бәрәңге тутырган капчыкларны авылның ындыр табагына ташырга кушылды. Бер-ике көннән соң Идмас Әнискә:

— Син эштән качып йөрисең! — дип бәйләнде. — Безнең кебек син дә бәрәңге чүплә. Ат белән кем дә ташый аны. Бүгеннән мин! — дип, дилбегәгә килеп ябышты.

— Бригадир миңа кушты, сиңа түгел, — дип, Әнис каршы килде. Гадәтенчә Идмас мәсьәләне йодрык белән чишмәкче булды. Алар бәргәләшә башлаганнар иде, бригадир килеп аерды.

— Юкка чәпәли чуак булмагыз, — диде ул. — Килешми. Бу нинди тәмсезләнү. Капчыклар авыр, аларны төяү дә, ындыр табагына илтеп бушату да майлы ботка ашау түгел.

Бу хәл директорга ук ишетелде. Ул Әнисне ачуланып ташлады, чөнки Идмас низаг шаһиты булган малайларны куркытып куйганга күрә, алар гаеп Әнистә дигәннәр иде.

Шуннан бирле Идмас Әнискә гел кырын карап йөрде. Аның Әнисә белән дуслыгы да Идмасның эчен пошыра иде.

Бер мәртәбә ул, аксыл керфекләрен кысып:

— Син юкка гына Әнисә янында буталып йөрисең. Без бит бер балалар йортыннан килдек. Аның артыннан йөрүчеләр булгалады, — диде. — Ул кемгә дә шаккатмады. Укуын белде.

— Әллә үзеңә дә исе китмәдеме? Шуңа борчыласыңмы? Бәлкем, сине карт дип уйлагандыр, ә?

Идмасның күзләре урынында нечкә ярыклар гына калды:

— Телим икән, Әнисәне мин синнән бик тиз биздереп, үземнеке итә алам. Мин аны алмагачтан күтәреп алган көннән бирле күпме вакыт узган дип беләсең? Ә ул миңа күргән саен елмаеп китә.

— Син, Идмас, куык очырма әле. — Әнис масаючан кешеләрне яратмый иде. — Син Илгиз белән Сәлимә арасына да чөй кагарга маташтың түгелме? Бик исләре китте!

Идмас күзләрен як-якка атты:

— Бәхәсме? Менә күрерсең! Раймагта сөяк саплы бик матур пәке күргән идекме? Оттырган кеше шуны алып бирә. Килештекме?

— Юк, бәхәсләшмим дә, нитмим дә. Борыныңны белеп тарт, яме. Син безнең араны боза алмыйсың. Сәбәбен әйтеп тормыйм.

Шул көннән Идмас Әнисә артыннан калмаска тырышты. Билет алып киного чакырды. Бүләккә китаплар алды. Кирәксә-кирәкмәсә дә физика, биология кабинетларында, ярдәм итимме дип, янына барып утырды. Тик Әнисә аның ярдәмен кире какты, бүләкләрен алмады. Киного чакыргач бер барды да бүтән бармады.

Беркөнне ул Әнискә:

— Син күрәсеңме, юкмы? Идмас күзләрен тозландырып янымда бөтерелергә генә тора. Ник дәшмисең? — диде.

— Зина белән ачуланышса, ул шулай бүтәннәргә бәйләнергә ярата. Сине дә үзенә каратам дип үҗәч киерә, — диде аңа Әнис.

— Мин аны якын да җибәрмим... Еш кына Зина белән Бизнә янына төшеп утыралар иде. Тагын нәрсә булган? Минем монда ни катнашым бар?

— Йөрер-йөрер дә туктар... Бер дә борчылма. Үзен бик чибәр, теләсә кайсы кызны карата алам дип белә, күрәсең. Үзен-үзе алдый ул. Үз сүзен аста калдырмас өчен.

— Нинди сүз?

Бу күңелсез әңгәмәне Әнис икенчегә борырга теләде:

— Ярар ла, игътибар итмә. Физика кабинетына керәбезме? Оптика кагыйдәләрен кабатлыйсым бар, дигән идең.

— Вакытың булса... Мин төшке аштан соң шунда керәм.

Әнис кабинетка кереп, озак кына көтеп утырса да, Әнисә күренмәде. Әнис аны эзләп тулай торакка барып килде, кыз анда да юк иде. Бүлмәдәш кызлары, аны Идмас бик кирәк иде дип чакырып чыгарды да алар каядыр китеп бардылар бугай, диделәр. Бу Әнис өчен шаккатыргыч яңалык иде. Ул аптырап калды. Ничек инде? Үзе Идмасны якын да җибәрмим диде, ә үзе... Әнис кызны кичкә кадәр булса да көтәргә, хәлне ачыкларга ниятләде. Хәер, Әнисә озак та үтми училище капкасыннан кайтып керде.

— Әнисә, мин сине кабинетта да, инде менә монда да көтә-көтә арып беттем, — дип, аның каршына чыкты.

— Хәлдән таймадыңмы соң? — Әнисәнең сүзләре бик кырыс яңгырады.

— Син кайда булдың соң? Кызлар сине Идмас белән чыгып китте, диделәр.

Әнисә җавап бирергә ашыкмады.

— Әйе, аның белән булдым. Ә нәрсә? Арып беткәнсең икән, бар, кайтып ятып йокла инде, хәл керер. — Кыз китәргә борылды.

— Әнисә, мин берни аңламыйм. Нинди чебен тешләде сине, ә?

— Мин дә сине аңламыйм. Теләмим дә. Их син! — Әнисә күзләренә мөлдерәмә тулган яшьләрен яулыгы белән сөртеп, йөгереп диярлек тулай торакка китеп барды.

Әнис балтасы суга төшкән кеше кебек берничә көн кара көеп йөрде. Нәрсә булды соң инде бу? Күкчәчәк күз шул көннән бирле аның белән очрашырга да теләми. Әнис, су буенда алар икесе генә яраткан каен янына барып, Әнисә килеп чыкмасмы дип көтеп тә утыргалады. Юк, күренмәде. Әнис Әнисәнең дус кызы Лилиядән дә:

— Әнисәгә нәрсә булды икән? — дип сорап карады, Лилия, берни белмим, дип, җилкәсен генә җыерды. Димәк, Идмас сүзе өстен чыкты. Әнә ич ул ничек елмаеп йөри. Дөрес, теге көннән соң Әнисә аның янына да чыкмый икән. Әнис моны белә, Лилия әйтте. Алайса, сәбәп нәрсәдә?

Тагын берничә көн узды. Алар Әнискә айлар булып тоелды. Беркөнне егетләр тулай торакта дәрескә әзерләнеп утырганда, бүлмә ишеген каты итеп шакыган тавыш яңгырады.

— Керегез, кер, бикле түгел ич.

Ишектән бүлмәгә Әнисә белән Лилия килеп керде.

— Хәерле кич, егетләр. — Әнисә кыю гына атлап Әнис янына килеп басты.

— Идмас өйдә юкмыни? Мин икегезне дә туры китерермен дип өмет иткән идем. Менә ал, син оттың, — диде дә Әнис кулына сөяк саплы авыр пәке салды. Әниснең бу ун җәпле пәкене раймагта кызыгып карап торганын ул белә иде.

— Нәрсә оттым? Бу нинди пәке? Һични аңламыйм. — Әниснең аптыравы йөзенә чыкты.

— Сез Идмас белән пәкегә бәхәсләшкәнсез икән. Син җиңдең. Мә! Ал! — Кызның ирен кырыйлары тартышып-тартышып куйды.

— Тукта әле, Әнисә. Аңлатыбрак сөйлә. Бернинди бәхәс тә булмады. Сиңа моны кем әйтте? Идмас әйттеме? Улмы? — Әнис кызны кулыннан алды.

— Сүз иясе белән йөрми.

— Бернинди бәхәс тә булмады. Киресенчә, Әнисәңне үземнеке итәм, дип, бакыр баш масайды. Ә мин, ул сиңа борылып та карамаячак, дидем. Дөрес әйттемме?

— Ә ул башкача сөйләде. Бәхәсләштек, җиңелгән кеше пәке сатып ала дип килештек, ди. Мин оттырдым, ди.

— Теләгенә ирешә алмаганын аңлый икән әле үзе. Тик бернинди килешү дә булмады. Анысы ялган. Ышанма! Комсомолец, имеш! Малайлар, менә сез әйтегез әле. Шундый килешү булдымы, юкмы? Сез дә аның мактанганын ишеттегез ич.

Шунда Игълам сикереп торды:

— Ялганлый ул! Андый сүз булмады. Әнисә, Лилия, ышанмагыз.

Бүтән малайлар да, юк, булмады, дип, аның сүзен җөпләделәр.

— Ә мин сиңа рәнҗегән идем. Мин бит ташкурчак түгел. Бу бит мине мәсхәрәләү дип уйладым. — Әнисәнең йөзе ачылып китте.

— Син миңа шуңа гына үпкәләп йөрдең инде алайса, иеме? — Әнис күңелсезлекнең бетүенә сөенә иде.

— Шуңа гына. Пәке отар өчен дус булып кыланып йөрү кешедән көлү түгелмени?

— Ярар инде, Әнисә. Аңлаштык бит. Бүтән сәбәп юкмы диюем генә.

— Ә син ничек уйлыйсың? Аның шулай мактанып йөрүен белә торып, үзең читтән генә күзәтүең егетлекме?

Әнис моны көтмәгән иде. Дөрестән дә, нишләп ул моңа юл куйды соң әле?

— Менә монысы өчен мин гаепле. Гафу ит. Чыннан да. Сиңа ышанганга күрәдер, уйламаганмын да, — диде ул. — Йә, беттеме?

— Бетте.

— Алайса, мә, бу пәкене Идмасның үзенә кире бир. — Әнис кулын пешереп торган матур пәкене Әнисәгә сузды.

— Бирде ди, хәзер. Алмыйм. Минеке ул, анықы түгел. Сиңа бүләгем булыр. Кызыгып йөргәнеңне беләм ич.

Идмас теге чакта кәпрәйсә дә, Әнисәне үзенә карата алмавына бик гарьләнеп, эчтән тынды. Әнискә ник бер сүз әйтсен. Әнис егетлек эшләде, бу хакта аның исенә төшереп тормады. Сөзәм дигән сыерның мөгезе сынган чаклар да булгалый шул дип уйлады.

## 9

Өченче курс тәмамлангач, җәен укучыларны район буенча экскурсиягә алып чыктылар. Район чыннан да үзенең бай тарихы, тарихи һәйкәлләре белән горурлана иде. Антоновка авылында укучылар патша Александр II крепостное правоны бетерү хакында манифест чыгаргач ул чакта Рус Бизнәсе дигән авылда Антон Петров исемле крестьян җитәкчелегендә баш күтәрүләре, моның өчен нинди җәзага тартылулары хакында бик күп мәгълүмат алдылар. Патша залимнәре тарафыннан җаны кыелган Антон Петров каберенә чәчәкләр салдылар. Никольское авылында данлыклы ат заводында, Куйбышев исемендәге затонда, пароходлар ремонтлау заводында булдылар. Борынгы Болгар шәһәрендә тетрәндергеч тарихи хәрабәләр карап йөрделәр.

Укучыларны җирле экскурсоводлар Болгарда матур бер күл янына алып бардылар, аның ни өчен изге Рабига күле дип аталуы хакында халкыбызның буыннан буынга күчеп йөргән риваятен сөйләп таң калдырдылар.

Менә шунда инде Әнисә дә Әнискә күңеленең иң ерак түрендә йөрткән хисләрен тәүге кат ачып салды. Болгар хәрабәләрен карап йөргәндә, ул үзен бөтен барлыгы белән болгар кызы итеп тойды.

...Хан кызы Рабига, Иделдә дус кызлары белән ял итеп көймәдә йөргәндә, ялгыш суга егылып төшә, бата башлый. Моны күргәч, камышлар арасында балык тотып утырган Гомәр исемле яшь егет аңа ярдәмгә ташлана, коткарып кала. Ике яшь йөрәкнең танышуы әнә шундый фаҗигале вакыйгадан башлана. Әле мыегы тибеп кенә чыккан горур кыяфәтле, үткен күзле, җитез хәрәкәтле яшь егет берничә елдан чибәр, гайрәтле, уңган батырга әйләнә. Рабига да буйга тартыла, кызларның багалма кебек гүзәл чорына керә. Бер-берсенә гашыйк булган егет белән кыз Ага-базар урамнарында, Идел буенда, хан сарае янында очрашканда мәхәббәтләрен яшермиләр.

Аксак Тимер сувар халкына яу белән чыккач, Гомәр батыр аңа ярдәмгә ашыга һәм сугыш кырында һәлак була. Биләр, Сувар, Җүкәтау калаларын яндырып көлгә әйләндергәч, Аксак Тимер Болгарны камап ала. Болгар халкы үз-үзен аямыйча басып алучыларга каршы сугыша, ләкин көчләрнең тигез булмавы сәбәпле, шәһәр дөрләп яна, мәчетләр, китапханәләр көлгә әйләнә. Хан үзе дә яраланып фани дөнья белән хушлаша. Ләкин шәһәр халкы бирелми.

Аксак Тимернең гаскәр башлыгы Болгар халкына соңгы әмерен җиткерә:

— Хан кызы Рабиганы миңа тотып бирсәгез, мин моннан ары сезгә тимәскә сүз бирәм, — ди.

Туган халкын кырылып бетүдән саклап калу өчен гүзәл Рабига риза була, тик гаскәр башлыгына бер шарт куя.

— Бертуган абыем белән энемә ике юртак китерт. Шунда гына мин синеке булырмын, — ди.

Шарт үтәлә, юртаклар китерелә. Рабига туганнарына:

— Барыгыз, сөекле туганнарым, качып котылыгыз. Аннары халыкны җыеп, шушы Аксак Тимер этләрен дөмектерегез, — ди.

Егетләр, юртакларга атланып, күздән югалалар.

Рабига, ташпулат түбәсенә менеп, туган шәһәренә күз сала. Күрә, кая карама — ут, янгын, кайгы-хәсрәт, үлем. Инде аның беркеме дә калмаган, туганнары да, әти-әнисе дә, сөекле Гомәре дә.

— Юк инде, — ди ул. — Явыз дошман минем намусымны пычрата алмас. Аңа бирелгәнче, үлүең яхшырак.

Рабига ташпулат түбәсеннән ут эченә ташлана, ләкин исән кала. Болгарлылар, савыктырырга дип, аны изге күл янына күтәреп баралар, яраларын юып дәваларга телиләр. Чибәр Рабига, аңына килгәч, куе каенлык ышыгында җәелеп яткан күлгә ташлана да юк була. Дошман аны бик озак эзләсә дә таба алмый. Туган халкы аның явыз басып алучылардан качып, яшерен юл белән Иделгә агып чыккан да аннары сөйгәне Гомәр кабере янына барып вафат булган дигән фикергә ышана. Шуннан соң бу күлне намусын чиста-пакь саклап, мәхәббәтенә тугры калган Рабига күле дип йөртә башлыйлар...

Боларны ишеткән Әнисә ул көнне үзен исеме риваятьләргә, халык күңеленә сеңеп калган Рабига итеп сизде. Мәхәббәт кешене нинди биеклекләргә күтәрә, җир, күк белән бербөтен ясый ала икән. Күлдә йөзеп йөргән ике аккошны күргәч, аның күңеле тулды. Янәшәсендә аның үз аккошы бар лабаса. Ә ул аккош чыннан да янында гына, күз карашы белән иркәләп, сөюеннән очып кына йөргән Әнис иде. Аның Әнискә бик тә мөһим, менә шушында, Болгарда, Рабига күленең чирәмле матур ярында күңелен ташытып, аеруча дулкынландырып туган тәүге хисен әйтәсе килде.

— Әнис, — диде ул, — мин янәшәмдә гомерем буена син генә булуны телим. Бары син генә.

Кояш нурларында коенып яткан зәңгәр күл өстеннән җылы җил исте, ул йөрәкләренә бөек хис тулган яшьләрнең башларыннан сыйпап узды. Иреннәр иреннәргә кушылды.

## 10

...Пароход тавышы сискәндереп җибәрде. Ул Идел өстеннән еракка, каршы яктагы ярларга барып бәрелде, аннан кире кайтып бөтен урманлыкка, пристаньга кереп тулды. Әнис белән Әнисә кочаклашып, бер-берсеннән аерыла алмый басып тордылар. Инде аларга аерылышырга кирәк иде. Тик көчләреннән килмәде.

Басманы алырга җыенган киң җилкәле ачык йөзле матрос:

— Сез утырасызмы, юкмы? — дигәч кенә, егет кызны кочагыннан чыгарды.

— Хуш, җаным. Йә, елама инде... Сөйләштек бит инде. Бер ел күп түгел ул. Миңа да синнән аерылып китү бик авыр. Тик нишләмәк кирәк. Училище тәмам. Әрәм булма, укуыңны дәвам итә күр, диделәр. Беләсең ич. Син дә училищены тәмамла, аннан минем янга килерсең. Мин университет бетергәч, бергәләп эшкә китәрбез. Хыялыбызны тормышка ашырып, балалар укытырбыз. Йә-йә, пароход кузгала ич.

— Мин сине хәзер үк сагына башладым, — диде Әнисә. — Хәтерлисеңме, син миңа роза бүләк иткән идең. Ул исән. Кипсә дә, хуш исе аңкып тора. Мин аны синең төсең итеп саклармын.

— Алла боерса, безнең тормышта андый розалар күп булыр әле, матурым.

Алар пароход басмасына кадәр янә кочаклашып бардылар.

Әнис пароходка керүгә борылды да:

— Хуш инде, Әнисә, — диде. — Пароход төнлә генә килә. Озатып йөрмә, дип күпме әйттем. Инде караңгы төште. Җил көчәя. Болыт та килә, яңгыр булыр, ахрысы. Шәһәргә берьялгызың ничек кайтырсың. Бар инде, бар. Хатларыңны еш яз. Яме-е!

Пароходның көпчәк калаклары инде суга бәрә иде. Ул акрынлап борылды да, кап-кара суны икегә ярып, Идел уртасына таба юл алды. Пристань лампалары тоныкланып артка шуды, пароход елга култыгын узып инде күренмәс булды. Ул төн караңгысына кереп югалганчы пристаньда яулык болгап басып калган ак күлмәкле кыз Әниснең йөрәген әрнетеп, аның хәтеренә мәңгегә сеңеп калды...

Әнисәнең күз яшьләре кибә төште. Аның Әнисеннән соң бушап калган шәһәр ягына борылып китәсе килми, аягы тартмый иде. Сөйгәненең китүенә ул әллә ышанмый идеме соң? Ышанадыр ла, әнә ич егете пароходка керүгә, аяк астында шыгырдап торган басманы тартып алдылар. Әнә ич Әнисе аңа, хуш, диде, Казанга килерсең, диде. Җил, яңгыр, диде. Ә шулай да Әнис менә хәзер кинәт кенә әллә каян пәйда булыр да, гадәтенчә, арттан килеп аның күзен томалар, Әнисә танымаган булыр, ә егете шуңа шатланып көлеп җибәрер дә кысып кочаклап алыр сыман тоела иде.

Әнисә үз хыялына үзе ышанып, кинәт кенә борылып карады. Юк шул, Әнис инде еракта, ул күптәннән пароходның җылы төтен бөркегән торбасына сөялеп, күзләрен авырттыра-авырттыра караңгыга чумып калган пристань ягына карап китеп бара иде.

Кинәт көчәеп киткән җил пристаньның калай түбәсен шаулатып алды. Әнисә айнып китте. Төнне монда үткәреп булмый, кайтырга кирәк иде. Тулай торактагы дус кызлары әллә кайчан пошаманга төшкәннәрдер. Хәер, аның кая киткәнен беләләр белүен. Тәрбияче Ксения апасы да белә. Шулай уйлана-уйлана, Әнисә кайтыр юлга чыкты. Аңа әле кап-караңгы юлдан алты-җиде чакрымлап ара узасы бар иде.

Караңгыда юл кырыендагы һәр куак, һәр түмгәк әллә нинди албасты, җен, бүре булып күренә. Кыз куркуын җиңәргә тырышып атлый да атлый. Ә үзе, һич булмаса, берәр кеше очраса, болай ук куркыныч булмас иде, дип уйлый. Җил көчәйгәннән-көчәя, инде әнә Идел ягыннан беренче тамчылар да куып килә бугай. Әледән-әле күзне яшен камаштырып ала. Шөкер, инде шәһәр утлары да күренә башлады. Кыз адымнарын тагын да тизләтә төште.

— Йа Ходаем, яңгыр коя башлаганчы кайтып кына җитәсе иде.

Юл кырыена якын ук килеп үскән куаклар яныннан узганда, Әнисәгә анда кемдер посып торган кебек күренде. Кинәт ялтырап киткән яшеннән куркып, кыз чигенеп куйды. Шул мәлне кемдер, арттан муенын бик каты кысып, учы белән авызын-борынын томалады. Әнисә тыны бетеп, сыгылып төшкәч, аны куак арасына сөйрәп керделәр. Күлмәк сәдәпләренең чытырдап өзелеп төшкәнен ул ишетә алмады. Кемдер кызның өстенә авып, аның гәүдәсен тупас капшый иде. Бик нык авыртудан Әнисә кинәт айнып киткәндәй булды. Аның өстендә сасы хәмер, әче тир исе аңкытып битен яшергән берәү мыш-мыш килеп, ашык-пошык үзенең хайвани теләген үти иде...

## 11

Иптәш кызлары аны таң атканда гына тулай торак баскычында елап утырганын ишетеп бүлмәгә алып керделәр. Тулай торак ду килде. Кызлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сораша башладылар. Әнисәнең күлмәк изүе ертылган, әчке киемнәре дә пычранып беткән иде. Үзе бертуктаусыз сулкылдап-сулкылдап елый, бер генә сорауга да җавап бирми утыра бирде.

Фаҗига иртән директорга мәгълүм булды. Сафа Нәсихов та гаҗиз калды. Мондый вәхшилекне кем эшләвен ул Әнисәдән сорашуны хатын-кыз укытучыларга йөкләде, әмма мәсхәрәләнгән кыз, телсез калган кешедәй, һаман берни дә әйтмәде, елавын белде. Кызлар директорга Әнисәнең Әнисне озатырга барганын әйткәч, Нәсихов тетрәнеп китте. Мондый эшне Әнис ничек эшли алды икән? Мин аны бик яратам, кочакларга да оялып йөрим бит, дигән иде ләбаса. Нинди явыз, кара эчле кеше булып чыкты бит бу тәти егет. Өстәвенә юләр! Болай булгач, башы бетә бит инде аның. Хәзер менә аңа университетның башкасында укырга туры килер инде, дип уйлады ачынып директор. Егетнең юлдан язганын алар ничек күрми, сизми калдылар икән соң? Фаҗига турында Сафа Нәсихов прокуратурага, милициягә җиткерми булдыра алмады. Андагыларның да районда, шәһәрдә мондый чиктән тыш вакыйгага гаҗәпләнүенең чиге булмады.

Бер-ике көн узды. Әнисә тынычлана төшкән шикелле булды. Тамагына каба башлады. Сорауларга да кыска итеп йә «әйе», йә «юк» дип җавап бирсә дә, шуннан артык узмады. Тик Әнис турында сорашырга керешкәндә ул кабат үксеп-үксеп еларга тотына да үз эченә кереп бикләнә иде.

Укучы егетләр Әнисәне шушы хәлгә төшергән кешене изеп ташларга әзер иде.

— Мин ул Әнисне Казанда барыбер эзләп табам! — диде Идмас. — Моның үчен барыбер алам, болай гына калдырмыйм!

Берничә көн шулай шау-шу килеп кайнап торган училищеда Әнис исеме һаман ешрак кабатланды. Әнисәнең дус кызлары беркөнне җыелышып директор кабинетына килеп керделәр.

— Сафа абый! Без бик нык гаҗәпләнәбез! — диде Камәрия. — Әнисне эзләп табарга да җавапка тартырга кирәк. Ә сез бернинди чара күрмисез! Бу ничек була инде, ә?

— Укучылар, мин тиешле органнарга хәбәр иттем инде. Алар тикшерү эшләре башлап җибәрделәр. Тик менә Әнисә үзе берни дә әйтми бит. Мондый явызлыкны кем эшләде, дигәч, белмим, дип елап тик тора. Ә Әнисне табабыз аны, табабыз. Ул үзенә тиешлесен алыр. Дуслык, мәхәббәт, имеш. Мәхәббәт шундый буламыни.

Директор, чыннан да, аптыраган иде. Ул бит яшьләрнең мөнәсәбәте чындыр дип ышана иде.

Менә сиңа мә! Уйлый торгач, ул бер нәтиҗәгә килде. Тикшерүчеләргә кадәр Әнисне ул үзе барып тапсын әле. Нинди йөз белән каршылар икән?! Әнис инде училищены тәмамлаган кеше булса да, дипломын әле генә алды бит. Аның бер аягы әле һаман училищеда дияргә була. Аның өчен дә җаваплылык шул ук директорга төшә ләбаса. Министрлыкта, райкомда ни диярләр! Башың әйләнерлек тә шул. Әнә бит күрше Тәтеш училищесы директорын эшеннән азат иттеләр. Әллә ни гаебе булмаса да. Анда шундыйрак бер ЧП өчен директор җаваплы булып калды. Әйе, барырга кирәк Казанга, күрергә кирәк ул оятсызны!

Ул арада училище тагын ду килә башлады. Әниснең Әнисәгә ике хаты килеп төште. Килеп төште дә кабат училищеның астын өскә китерде. Әнисәдән хатны ялына-ялына алып укыгач, барысы да шаккатты.

*«Әнисәм, күз нурым! Сагынып үләм бит мин сине. Күз алдымда һаман кул болгап басып торасың, бәгърем. Ник хат язмыйсың? Бер атна чамасы узды бит инде. Вәгъдәне шулай үтиләрмени? Бер-ике көн эчендә хатың килмәсә, нишләргә дә белмим. Имтиханнарга да әзерләнә алмый башладым...»*

Аның икенче хаты тагын шөбһәләнергә мәҗбүр итте. *«...Мин үзем гаепле. Син миңа рәнҗегәнсеңдер дип уйлыйм. Сине елатып, кап-кара төндә ялгызыңны калдырып киттем бит... Ник хат язмыйсың, матурым?..»*

Эшләр болайга киткәч, Нәсихов Әнисәне үз янына чакыртты.

— Сеңлем, мин барын да төпченмим... Бер генә сүз әйт. Сез бит бик матур пар идегез. Әйт әле, Әнис гаеплеме? Син, бәлки, яшерәсеңдер?

Әнисә әле генә аңга килгән кешедәй яшь тулы күзләре белән директорга карап торгач:

— Сафа абый! Ул түгел... Ул мине ярата. Мин дә аны... Әнис гаепле түгел, — диде дә әкрен генә торып чыгып китте.

Директор:

— Алайса, кем соң? — дип сорарга өлгерсә дә коридорда бәхетсез кызның аяк тавышлары гына яңгырап калды.

Бу хәл директорны янә тирән уйга батырды. Кем соң, алайса? Кем? Тикшерүчеләр ник шулай озак кыймылдый икән? Училищеда эш тавык чүпләп бетерә алмаслык, ә кул эшкә бармый. Нәсихов прокуратурага барып, берәр нәрсә ачыклап булмасмы дигән уйга килде. Кызның Әнисне гаепләмәвен дә әйтергә кирәк иде.

Олы яшьтәге тикшерүче аңа күптәннән таныш булса да, шешенке күз кабакларын өстәлгә төбәп, бик ачылып китмәде, директорны сабыр гына тыңлап торды. Аннары:

— Сез миңа яңалык әйтмәдегез. Ул кыз белән сөйләшеп, без аның егетен гаепләмәгәнен белдек инде, — диде. — Бик ярата икән ул аны. Яраткан кешесенең җавапка тартылуын теләр микән соң ул дигән сорау туа.

— Сез чыннан да Әнис гаепле дип уйлыйсызмы? Әнә бит хатында ул Әнисәгә, өзелеп яратам, дигән. Хат язмый торсаң, кайтам, дигән. Сөйгән кызын мәсхәрә кылса, ул шундый хат язар иде микән?

— Шунысы сәер дә шул аның.

— Менә-менә. Ә икенче хатында: мин үзем гаепле. Рәнҗегәнсеңдер. Сине елатып, калдырып киттем, дигән. Бу үз гаебеңне тану түгелме?

— Ә кыз, аның гаебе юк, ди ләбаса. Һич аңламассың. Кыскасы, безнең хезмәткәр Казанга китте инде. Әнисне эзләп табарга тиеш. Калганы шуннан соң ачыкланыр.

— Ярар, рәхмәт сезгә. Һөнәри сер булмаса, миңа хәбәр биргәләп торыгыз инде, зинһар.

— Карарбыз, Сафа Гыйлаҗетдинович. Мин аңлыйм. Мондый хәлләр өчен беркемнең дә башыннан сыйпамыйлар. Үзегез беләсез.

Сафа Нәсиховның тикшерүче кабинетыннан чыкканда кәефе тагын да бозыла төште. Нәрсә булып чыга соң инде бу? Ятимнәр йортыннан килгән кыз бала өчен, әлбәттә, ул үзе җаваплы. Ул бит җитәкче. Тәрбия эше начар куелган, димәк. Нәрсә карадың, диячәкләр. Ул республикада ятим балаларны укыта торган

бердәнбер училище директоры. Шуңа күрә аңа игътибар да, җаваплылык та зур. Балаларның тамагы да тук булсын, өс-башлары да бөтен булсын. Дөрес, министрлык ярдәм итә, тик тормыш тормыш бит ул. Киемсалым да туза, ертыла, продуктлар белән тәэмин итүдә дә өзеклекләр килеп чыгарга гына тора.

Авылдан килеп укучылар өчен дә җаваплылыкны беркем киметми. Ул балаларның тормышы хәтта авыррак та. Туклану, кием-салым юнәтү гаиләләре өстенә төшә. Ә илдә тормыш яхшы якка үзгәрергә бер дә охшамаган әлегә.

Шундый уйлардан башы каткан директор үз кабинетына кайтып кергән генә иде, телефон шылтырады. Чыбыкның теге башында әле генә сөйләшеп торган тикшерүче иде.

— Кайтып җиттегезме, иптәш Нәсихов? Монда тагын бер проблема чыгып тора әле. Казаннан безнең хезмәткәр шылтыратты. Теге Әнис юкка чыккан бит. Университетта да, тулай торакта да таба алмаган ул аны. — Үз гаебеннән куркып, качып йөри микән әллә? Әти-әнисенә сиздермичә, борчымыйча гына белешәсе иде, авылына кайтмады микән?

Сафа Нәсихов лып итеп кәнәфиенә утырды. Иш янына куш. Димәк, тәти егет гаепле. Югыйсә качып йөрмәс иде. Чүп өстенә чүмәлә була түгелме соң әле бу? Йомгак тагын да чуала лабаса.

Көндәлек эшләр җыелып тора. Директор бер генә эшкә кулы бармаса да, үзен кулына ручка алырга мәҗбүр итте. Әллә ничә приказ язасы, читтән торып укучылардан имтиханнар алуны оештырып җибәрәсе, тагын бакчада җәйге эшләр планын карап чыгасы, тагын әллә ниләр эшлисе бар лабаса.

Директор авыл хуҗалыгы нигезләрен укытучы Вера Кузнецованы чакыртып алды, җәйге эшләр көндәлеген төгәлләргә кушты. Ана теле укытучысы Илсөяр белән каникулда Казанга экскурсиягә баручы укучылар исемлеген аныклады, кирәк-яракларны табарга булышты. Физика укытучысы Гыйльман Әхәтов белән лабораториягә яңа уку елына нинди әсбаплар сатып алу кирәклеген ачыклады. Ләкин ни генә эшләмәсен, миен һаман борчулы уйлары бораулады: кайда, кайчан, ничек, нәрсәне күрми калдылар соң алар? Тәрбиячеләр ничек кыз баланы кемгәдер ияртеп җибәрә алганнар? Әллә күрми калганнармы? Кемгәдер дисәң... Сөйгән егетенә ләбаса. Алайса, бу фаҗигагә кем гаепле? Тикшерүче дөрес әйтә: кайда, ник югалып йөри ул Әнис. Дөрестән дә, аның дусты Илгизәрне мотоциклга гына утыртып авылга җибәрергә кирәк. Әнис анда кайтмадымы икән? Тик моны әти-әнисенә берни әйтми, сиздерми генә эшлисе иде.

Кичен өенә кайткач та аны шушы уйлары борчыды. Хатыны Гәүһәриянең:

— Син алай ук бетеренмә әле. Ашаудан калып барасың ич, — диюенә кәефе кырылды.

— Синең шул булыр инде. Ашау-ашау... — дип, бер дә юкка хатынының хәтерен калдырды.

Ә иртәгәсен аны тагын да борчулырак хәлләр көтә иде.

## 12

Әнисә шушы берничә көн эчендә нык суырылып, ябыгып калды. Тамагына капса капты, капмаса онытты. Тәрбиячеләр, иптәш кызлары, бигрәк тә Лилия, Фирдәвес гел аның белән бергә булдылар. Әлбәттә, күбесенең башында үз-үзенә кул гына сала күрмәсен дигән уй бөтерелде. Кызлар үзләрен Әнисә урынына куеп карыйлар да йөрәкләре жу итеп китә иде. Фаҗигагә тап булган Әнисәнең күкчәчәктәй күзләренең тоныкланып, алсу битләренең саргылт-көрәнсу төскә керүен күрү аларга бик авыр иде.

Кайвакыт Әнисә иптәшләреннән, зинһар, үземне генә калдырыгыз әле, дип үтенсә дә, аңа күз-колак булырга тырыштылар. Әнисә исә төннәрен, бүлмәдәге кызлар йоклап беткәч, торып утыра, аннары киемсалымын барлый торган булып китте. Аннары тагын уйга талып утыра-утыра да кинәт аның борынына теге хәмер, ачы тир исе кабат бәрелеп киткәндәй була. Ул хәтта укшый ук башлый. Тешләнеп, кара янып беткән күкрәкләре янә сулык-сулык итә. Үзе һаман бер нәрсә уйлый: кем соң аны шулай рисвай итте? Кем соң аның исемен шулай пычратты, бөтен шәһәргә фаш итте. Инде хәзер аңа нишләргә? Бу хәлне белгәнишеткән һәр кеше аңа бармак белән төртеп күрсәтәчәк бит. Аңа күз салып йөргән шәһәр егетләре күзен дә ачырмаячак хәзер. Йа Хода, әнисе исән булса, кайтып аңа сиенып иде. Аның бит беркеме дә юк. Шушы явыз, миһербансыз дөньяда ул берүзе калды. Хәзер аңа бәхетсез башын кайларга илтеп ташларга соң?

Сафа Нәсихов училищега килгәнче тагын прокуратурага кагылды, тик аңа анда бернинди яңалык әйтмәделәр. Ә яңалык аны училищеның үзендә көтә иде. Ул кабинетына кергән генә иде, училищеның озын коридор башындагы ишек шапылдап ябылды да ир балалар тавышы яңгырый башлады:

— Әйдә-әйдә, батыррак атла, кияү егете! Башта директорга күрен. — Тавыш Идмас Фәсхетдиновныкы иде.

— Җибәр! Җибәр, диләр сиңа! Сугыш чукмары! Синнән башка да юлны беләм. Җибәр!

Йа Хода! Бусы Әнис тавышы түгелме соң? Нәсихов идәндәге паласка сөрлегә-сөрлегә ишеккә ташланды. Кинәт ишек ачылып китте, ә анда Әнис күренде. Җилкәсеннән төртеп җибәргәнгә, ул Сафа абыена килеп бәрелә язды. Әнис артыннан Идмас Фәсхетдинов пәйда булды.

— Исәнмесез, Сафа Гыйлаҗетдинович! Мине кызлар тулай торагына барган җирдән менә бу сугыш чукмары сезнең янга сөйрәп килде, гафу итегез! — дип, Әнис директор каршына килде. — Әйтерсең мин үзем юлны белмим! Кара инде, күлмәгемнең изүен умырып төшерде.

Нәсихов, бераз үз күзенә ышанмый торгач:

— Син Әнисме? — дип урынсыз сорап куйды. — Син каян килеп чыктың? Кайчан? Сине бит милиция, прокуратура эзли.

— Прокуратура? Милиция? Мин нәрсәгә кирәк булдым аларга? — Әнис агарынып китте. — Нәрсә булды? Һич аңламыйм. Менә училище ишегалдында күренүем булды, Идмас килеп ябышты.

— Син берни дә белмисеңмени?

— Нәрсәне? Әнисә миңа хат язармын дип калды. Ә үзе язмый. Күңелем нидәндер шикләнде дә менә кайтып хәлен белим дидем.

— Алай икән.

Идмас кулларын бутарга кереште:

— Кара син аны, ә! Берни белмәгән булып кылана! Юк инде, тәти егет, җаваплылыктан котыла алмассың хәзер.

Директор инде үзен кулга алып өлгерде, ул Идмасны тынычландыра башлады:

— Тукта әле, Фәсхетдинов. Сабыр ит.

— Сез, сабыр ит, дисез. — Идмас йөзен җыерды. — Ә кем аңа йөргән кызын мәсхәрәләргә ирек биргән. Әнисәне яраткан булып кына йөргән икән. Икейөзле! Сталин үлгәч тә еламаган иде ул. Мин яхшы хәтерлим!

Боларны ишеткәч, Әнис шаккатты.

— Сафа абый, нәрсә сөйли ул?! Кем мәсхәрәләгән? Әнисәнеме?

— Туктагыз әле, егетләр. Әйдәгез, тәртип белән генә... Әнис, сине Әнисә пароходка озатырга бардымы?

— Барды, барды. Озатып калды. Нәрсә булды, Сафа абый? Әйтегез инде.

— Пристаньда син киткәндә тагын кемнәр бар иде? Араларында танышларыгыз юк идеме?

— Кеше бик аз иде. Танышлар юк иде. Балыкчылар бар иде. Йә, әйтегез инде, нәрсә булган Әнисәгә?

— Һе, белмәгән булып кылана! Нәрсә булсын, син аны көчләгәнсең ич! — Идмас төкерекләрен чәчеп сүзгә кысылды. — Белмәгәнгә салына!

— Көчләгән? Минме? Син ни сөйлисең, бакыр баш?!

— Туктагыз әле, дим, егетләр. Һм-м... Сине, Әнис, эзлиләр бит. Шик сиңа төшә...

— Миңа? Ә Әнисә кайда? Ул исәнме? Әйтәм аны хаты юк!

Әнис, кинәт сикереп торып, ишеккә ташланды. Аңа каршы төшәргә теләгән Идмас өлгерә алмый калды, Әнис чыгып йөгерде. Аның артыннан Идмас та йөгереп китте. Нәсихов коридорга чыккач, аларның кызлар тулай торагына кереп киткәннәрен күреп калды. Үзе дә шунда ашыкты. Нәсихов Әнисә яшәгән бүлмә ишеген шакыганда анда инде давыл купкан, кызлар Әнисне сарып алганнар, аны теткәләп ташларга җыенган кебек, кызарып-бүртенеп аңа ябырылганнар иде. Директор килеп кергәч тә, алар тынычлана алмадылар, кычкыруларын дәвам иттеләр:

— Син нишләдең?

— Ничек шуңа намусың җитте, ә?!

— Ярата, имеш!

— Сине бит ул өзелеп ярата иде, ә син! Их!

Әнис кызларның әле берсенә, әле икенчесенә борылып карый, нәрсәдер әйтергә тели иде, тик кызлар һаман ду киләләр, аңа авыз ачарга да ирек бирмиләр.

Нәсихов кызларны тынычландыра башлады:

— Сабыр итегез, кызлар! Сабыр итегез. Әнискә дә сүз әйтергә ирек бирегез.

Әнис, тирә-ягына каранып, маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп алды.

— Нәрсә соң инде бу? Минем бер гаебем дә юк, кызлар, Сафа абый. Ышаныгыз. Честное комсомольское. Ул мине озатып калды. Әйттем мин аңарга, озатма, дидем. Инде караңгы төшкән иде. Болытлы төн иде.

— Болытлы булгандыр шул. Сиңа ярдәмгә. — Моны Идмас кыстырып куйды.

— Син телеңне тыясыңмы, юкмы? Нинди ярдәм! Әйтегез әле, Әнисә үзе кайда соң? Сырхауханәдәме? Кайсында? Мин барып күрим әле. Әйтәм хаты юк. Көтәм-көтәм, җавап язмый.

Кызлар тынычлана төштеләр булса кирәк, Әнисә караватына карап куйдылар.

— Әнисә үзе кайда соң?

Кайсыдыр:

— Чыннан да, ул кайда соң әле? Бәдрәфтә түгелме? — дип, якындагы бәдрәфкә йөгерде. Әнисә анда да юк иде.

Нәсихов тагын шөбһәләнә калды:

— Лилия, Фирдәвес, сез белмисезме? Сез ничек соң аны күздән югалттыгыз? Аңа игътибарлы булырга дип кат-кат әйткән идем ләбаса. Барыгыз, эзләп табыгыз, — диде ул. — Ә син, Әнис, әйдә минем белән. Училище классларын карап килик.

Кызлар дәррәү коридорга, тулай торак бүлмәләренә сибелделәр. Әнисәне бер җирдә дә таба алмагач, аның урын-җирен актара башладылар. Бәхетсез кызның әйберләре үз урынында, тик бер-ике күлмәге, җылы йон кофтасы, плащы юклыгы беленде. Тәрбияче Ксения Юрьева йөгереп кенә сестра-хозяйка янына барып килде. Әнисәнең чемоданы үз урынында иде. Яңа хәбәрне ишеткән егетләр, кызлар тиз генә училище бүлмәләрен, хәтта чарлакны тикшереп чыктылар. Әнисә беркайда да юк иде.

Хәбәр бик тиз милициягә барып җитте. Кызны инде милиция хезмәткәрләре эзли башлады. Егетләр белән көне буе анда-монда чапкан, әлсерәгән Әнисне кичен кулга алдылар.

## 13

Ә Әнисә бу вакытта Тәтеш ягына баручы очраклы машинага утырып Идел янына килеп җиткән иде. Кулындагы төенчеген алып машина әрҗәсеннән төшкәч, ул кабинадагы шофер янына килде дә аңа ике сум акча сузды.

— Рәхмәт сезгә, — диде ул. — Ике сум җитәдер бит?

Шофер кызга текәлеп карап торганнан соң:

— Шундый чибәр кыздан акча алсаң, җир йотар. Кирәкмәс, сал кесәңә. Кая юл тотуың, матурым? — диде. — Йөзеңнән күреп торам, бик борчылгансың. Бирешмә син, бирешмә. Дөньяда матурлык яшәмәсә, аның мәгънәсе калмый. Ярый, хуш иттек.

Машина тузаны таралгач, Әнисә Иделнең аръягына чыгучылар арасына кереп басты. Ул әле кая китәсен белми, бары тик үзен пычракка батырган район үзәгеннән, аның гүзәл мәхәббәтен изгән, яшьлегеннән мәхрүм иткән урыннан тизрәк китәргә, качарга гына тели иде. Үзен эзләргә ташланачакларын чамалаганга, Әнисә Переволоки пристанена түгел, Тәтеш пристанена китәргә карар кылды. Пристаньда эзләми, аны каян эзләсеннәр тагын. Ә Тәтешкә эзләп килсәләр, ул инде киткән булачак. Тик менә кая китсен икән ул? Казанга һич тә ярамый, анда аның Әнисе, аның бу дөньяда иң яраткан, иң якын кешесе укырга керергә йөри. Иң якын? Их, йөрәккә иң якын да бит, ә менә хәзер аларның аралары... Мәсхәрәләнеп, исеме бөтен дөньяга таралгач, Әнисенең күзләренә ул беркайчан да күренә алмаячак. Әнис белән алар бер-берсе өчен үләргә дә әзер иде. Бер-берсен мәңге ташламаска антлар эчтеләр, вәгъдәләр бирештеләр. Ә кем белгән аларның гүзәл мәхәббәте менә шулай көтмәгәндә чәлпәрәмә киләсен. «Их, Әнис, Әнисем, бәгърем, мәхәббәтем, күз нурым, хуш мәңгегә. Мәхәббәтебез хакына син мине гафу итәрсең, тора-бара онытырсың. Ә мин сиңа гомерем буе турылыклы булып калырмын. Йөрәгемдә синең урыныңны беркайчан да беркем дә били алмаячак, җаным».

Уйлана торгач, Красный Бор районының Кырыңгы авылында әнисенең сеңлесе — Сәрия апасы яшәгәне исенә төште. Башта шунда барып чыксын әле ул. Аннары күз күрер. Иң яхшысы — йә Себер, йә Урта Азия якларына юл алу. Аннан аны беркем дә эзләп таба алмас. Әнисә булган акчасын барлап, Красный Бор пристанена тикле билет алды. Дөрес, аңа Кама Тамагында икенче пароходка күчеп утырасы бар, диделәр. Бусы әйбәт тә иде. Димәк, аның эзе тагын да чуалачак.

Пароход Переволокида туктап торачагын Әнисә уйлап бетермәгән иде. Пароход кузгалып киткәч кенә аның башына уй килеп төште: әгәр аны пристаньда эзләп йөрсәләр? Ярый әле бу уй үз вакытында башына килде. Димәк, ничек тә качып калырга кирәк. Кыз «Джамбул» пароходының трюмында иң ерак, яктылык саран гына төшә торган почмак идәнендә кайсы ятып, кайсы утырып баручылар арасына кереп урнашты. Косынкасын маңгаена ук төшереп бәйләде. Ул Әнисе утырып киткән пристаньның тизрәк артта калуын теләде.

Әнисә дөрес уйлый, аны чыннан да пристаньда эзләп йөриләр иде. Эзләүчеләр арасында училище кызлары, егетләре, милиция хезмәткәрләре дә бар иде. Алар пароходка утырырга килгән кешеләргә Әнисәнең фотосурәтен күрсәтеп сораштылар, кассир хатынны аптыратып бетерделәр. Кассир хатын, юк, андый кыз миннән билет алмады дип әйттем ләбаса инде, дип, тегеләрнең өметен бөтенләй кисеп куйды. Бермәлне трюм халкы гөжли башлады, карана-карана, кесәләрен актарырга керештеләр. Әнисәнең йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Аны алып калачаклар микәнни? Юк икән лә, контролерлар билет тикшереп

йөриләр икән. Шулай итеп, Әнисә куркыныч пристаньны узып китте. Узуын узды, ләкин шушы пристаньнан ерак түгел үзенең тормыш юлы кискен борылыш алуын искә төшерүгә, аның йөрәге әрнеп-әрнеп сулкылдады. Кем соң аны шулай мәсхәрә кылды? Нинди явызы бәхетсез итте, мәхәббәтеннән аерды. Әнисә ул бәндәгә бөтен күңеле белән ләгънәт укыды.

Бәхеткә каршы, Кама Тамагы пристаненда аңа күп көтәргә туры килмәде. Ул Красный Борга кадәр йөрүче пароходка күчеп утыргач, бераз тынычлангандай булды. Тынчу трюм идәнендә аунап төн уздыргач, Әнисә саф һава суларга пароход койрыгына чыкты. Күбекләнеп артка йөгергән Чулман суына карап бара-бара аны тагын тирән уйлар басып алды. Бүгенге кебек үк бу су көннәр, айлар, еллар буена аккан да аккан. Кемнәрне генә күрмәгән, кемнәрне генә күкрәгендә йөртмәгән бу гүзәл елга... Аның әле сөзәк, әле текә ярлары буенда кемнәр генә ял итмәгән, хәл җыймаган, бөдрә таллар, биек-биек өянкеләр баскан култыкларына карап кемнәр генә хозурланмаган. Офыкларга тоташкан хуш исле куе үлән үскән болыннарында кемнәр генә тезелешеп тирләп-пешеп печән чапмаган да тәненең һәр күзәнәгенә иксез-чиксез ләззәт биргән шифалы суында коенмаган, колач җәеп йөзмәгән. Кемнәр генә шушы изге елга буенда матур айлы кичләрдә сандугачлар җырына кушылып, йөрәктә дулаган табигый хискә бирелеп, сөйгәненә иң изге, иң саф мәхәббәтен ачмаган.

Үзенең бүгенге аяныч хәле исенә төшкән саен, Әнисәнең йөрәге әрнеп, сыкрап тибә. Мәхәббәтне иң татлы, ләззәтле, канатландыргыч хис диләр дә, ник соң ул аңа газаплы, әрнүле сулышын өрде? Бөтен табигать шау чәчәктә гөрләп утырган, һәр җан иясе яшәргә ашкынып торган бу көннәрдә мондый рухи газап кешегә каян килә? Ник җаныңны тегермән ташыдай авырлыгы белән баса, тыныңны кыса...

Әнисә кергәндә, кешеләр уянып, аннан-моннан юынгалап, тамак ялгарга керешкәннәр иде. Кайсы йомырка белән ипи кисәге капкалый, кайсы кипкән балык суыра, сохари кимерә. Әнисәнең бернинди ризыгы юк иде, булган акчасын ул бит билетка тотып бетерде. Күршеләренә карамаска тырышып, һаман йокымсырап утырган булды. Ләкин күпме генә йоклап утыра аласың инде. Юлдаш абыйлар, апалар да әнә капчыкларын баш астына салып черем итәләр, уянып дөнья хәлләрен сөйләшеп алалар, тагын яталар, торып, йөреп керәләр. Ни генә итсәң дә, аларның азмы-күпме тамаклары тук, ә менә Әнисәнең...

Аның каршында утыручы бумази күлмәк өстеннән иске халат кигән хатын кесәсеннән «Свобода» дигән нәни генә түгәрәк тартма алды да яргаланып, каралып беткән куллары белән ачып азаплана башлады. Тартма бирешмәде.

— Бирегез, үзем ачыйм әле, — диде Әнисә. Ул тырнакларын авырттыра-авырттыра тартманы ачып хатынга кире бирде. Трюмга вазелин исе таралды. Хатын бармак очы белән вазелин алып кулларына сөртте. Әнисәнең сораулы карашын күргәч:

— Әйе, наным... Авыл хатынының куллары ярылмый нишләсен, — диде. — Чүп утарга да, сыер саварга да, бәрәңге әрчергә дә, кер уарга да, бүтән мең төрле эшкә дә шул бер кул бит инде ул. Хезмәтнең ни икәнен татыган кул.

Әнисә әнисенең куллары да нәкъ шундый иде ләбаса! Ул чиста ак яулыгын арттан бәйләгән бу ягымлы хатынның тиресе яргаланып беткән кулларын үз кулларына алып күкрәгенә кысарга теләүдән чак кына тыелып калды.

Пароход дигән нәрсә ник шулай әкрен сөйрәлә икән? Агымга каршы бару авыр инде, анысы билгеле. Ник пристаньнарда шулай озак тора? Ашыйсы килүне ничек басарга соң? Әллә үзе каршында Әнисәгә ягымлы күзләре белән карап барган ападан ипи катысы булса да сораргамы? Әнисә кичкә кадәр чыдады, ләкин ашказанының сулык-сулык итүенә чыдый алмый башлагач, теге апага сүз катты:

— Апа, ачуланмагыз әле. Сезгә үтенечем бар. Минем акчам бетте. Менә төенчектә күлмәкләрем бар. Берәрсен сатып алмассызмы? — диде.

— Кичәдән бирле сиңа карап барам, кызым. Бу балага нидер булган дип уйлыйм, ә сүз катарга уңайсызланам. Укымышлы кешегә охшыйсың, андыйлар тиктомалдан сүз катуны өнәмиләр. Кил якынрак. Менә кружкага чәй ясап бирим. Ипи кисәгем дә бар. Икебезгә дә җитәр, кил әле, кил, — дип, бу апа ачык чырай күрсәтте.

— Мин бит бушлай түгел, апа. Менә шушы күлмәкне сезгә бирәм.

— Әй, бала-бала. Минем дә синең шикелле кызым бар. Ул да шулай дөнья җаен белми. Кирәкми миңа синең күлмәгең. Үзең киярсең. Нинди таза, матур, кер күтәрә торган икән.

Ягымлы караштан, җылы сүздән Әнисәнең күңеле тулып китте.

— Рәхмәт инде, апа, — диде ул.

— Син соң кая барасың болай? Берьялгызың, кыз бала?

— Кырынгы дигән авылга баруым иде. Эшем төште. Бик тиз чыгып китәргә туры килде.

— Кырынгыгамыни? Мин үзем Чишмәледән. Якташлар икәнбез. Ә Кырынгыда кемең бар?

— Әнинең сеңлесе Сәрия апа. Ул почтада эшли иде.

— Ә-ә, алай икән. Мин аны әз-мәз беләм бугай. Теге күп балалы Сәрия инде ул, алайса. Аның ире фронттан, контузия алып, бик холыксызланып кайткан дигәннәр иде. Шул инде, шул, алайса.

Кайнар чәй белән ипи кисәге капкач, Әнисәгә хәл кереп китте. Юлдаш хатын сүзләрен ишеткәч, Әнисә сүзне артык сузарга теләмәде, рәхмәт әйтеп үз урынына барып утырды. Авыр уйлар аның җанын тагын тегермән ташыдай баса башлады. Әнис хат язмаганга үпкәлидер инде. «Ничек яза ала идем соң мин аңа?! Караңгы төндә юлда тотып көчләделәр, дипме? Сүзеңне тыңламыйча сине озата барып, шушы хәлгә төштем, дипме? Әй, Әнис, Әнисем, син хәзер кайларда нәрсәләр уйлап йөрисең икән?»

**14**

Әнисне прокуратурага алып килделәр. Ул үз хәлен әле дә аңламый иде бугай. Ничек инде аны, Әнисәне үлеп яраткан кешене, шундый пычрак эштә гаепли алалар. Вәхши кеше эше ич ул! Ә Әнисә кайда икән соң? Ул ачыклык кертә ала лабаса. Аны таптылармы икән, юкмы икән? Көчләделәр дип үзенә-үзе кул сала күрмәсен, Ходаем. Бик тә эмоциональ кеше бит.

— Тиктомалдан кешене кулга алырга сезнең ни хакыгыз бар? Минем бер гаебем дә юк. Чишегез кулларны! — дип, Әнис һаман ачуланды. Тикшерүче ләм-мим сүз әйтми бик озаклап аның кулларын чиште дә йөзенә текәлеп торды. Тып-тын бүлмәдә стена сәгате тавышы буш мичкәгә чүкеч белән суккан кебек яңгырый башлады.

Шактый вакыт торганнан соң тикшерүче:

— Син, егет, монда тавыш күтәрмә. Шуны бел. Син миңа әйт әле, Әнисә Әхмәдуллина дигән гражданканы беләсеңме? Йә? — диде.

— Белмәскә! Бергә укыдык. Минем яраткан кызым ул. Сез аны таптыгызмы, юкмы?

— Алайса, бик әйбәт. — Тикшерүче сорауны җавапсыз калдырды. — Сөйгән кызың икән. Син аны соңгы кат кайчан күрдең?

— Кайчан дип. Моннан бер атна элек. 20 июньдә ул мине пристаньда озатып калды. Мин Казанга киткәндә.

— Сәгать ничәдә?

— Сез пароход ничәдә килә дип беләсез? 11 сәгать 20 минутта килә ул.

— Әхмәдуллина нинди киемнән иде?

— Анысы нәрсәгә инде?

— Сорауны монда мин бирәм. Җавап бирегез.

Тикшерүче астындагы урындык ямьсез итеп шыгырдап куйды.

— Чәчәкле кыска җиңле җиңел күлмәктән иде.

— Күлмәге чиста идеме?

— Сез нәрсә инде? Кыз кеше пычрак күлмәк киеп йөрсен димени?

— Ул төнне яңгыр яуды. Сез яңгырга эләктегезме?

— Юк. Мин пароходка утырганда яшен яшьнәп, яңгыр килә иде. Мин әле Әнисәгә: юкка гына озата килдең. Яңгыр килә, ничек кенә кайтырсың, дидем.

— Ә аның күлмәк изүен син ерттыңмы? — Урындык күсе тавышлары чыгарып тагын шыгырдады.

— Нишләп мин ертыйм ди. Аның күлмәге ертылганмыни?

— Сез пристаньга барганда берәр җирдә туктап тормадыгызмы?

— Туктадык. Әнисә чәчәк ярата. Бер-ике урында туктап чәчәкләр өзгәләде.

— Утырып та тордыгызмы?

— Юк, утырмадык. Армадык без. Икебез дә спортчылар. Ул акробатика белән шөгыльләнә, ә мин икенче разрядлы чаңгычы. 7–8 чакрым юл безгә нәрсә инде ул.

— Ярар, мактанма. Син монда кайчан кайттың?

— Бүген, иртәнге пароход белән.

— Ник кайттың?

— Без көн саен хат язышырга сөйләшкән идек. Мин яздым. Ә җавап юк.

— Шуннан?

— Мин бик борчылдым. Күңелем нидер сизгән кебек булды. Белергә дип кайттым.

— Нәрсәне?

— Сезнең кайчан да булса ятратканыгыз бармы? Булса, мондый сорау бирмәс идегез.

— Син сорауга җавап бир. Йә, җаваптан баш тартам, диген.

— Бу сорауга җаваптан мин баш тартам. Яраткан кеше күңелен яраткан кеше генә аңлый, күрәсең.

— Яхшы. «Баш тартам». Шулай дип язып куйыйк.

— Языгыз. Минем Әнисәгә тимәгәнемне, аның өчен үләргә әзер торуымны да язып куегыз.
— Һе-е. Шушы хәлендәдәме?
— Әйе. Әгәр аны мәсхәрәләгән кешенең кем икәнен белсәм, үтерер идем.
— Әһә-ә. Димәк, үч алыр идең...
— Алыр идем. Ә сез?
— Син кайда икәнеңне онытма.
Стена сәгате тавышы тагын көчәйде.
— Сез миннән шикләнәсезме? Соң, аның үзеннән сорагыз.
— Сорадык, сорадык. Син аны бик каты куркыткансың, ахрысы. Көчләүче син түгел, диде.
— Алайса, ник мине монда алып килдегез. Җибәрегез.
— Менә бусы тиз булмас шикелле. Бик күп нәрсәләр ачыклыйсы бар әле, — диде тикшерүче, кәгазьләрен кыштырдатып.
— Ачыклагыз. Ә мине җибәрегез. Без Әнисә белән икәү килеп барын да аңлатырбыз. Күрештерегез безне.
— Әнисәң югалды шул, таба алмыйбыз әле... Ярый, син әлегә утырып тор. Уйла, бәлки, кайбер нәрсәләрне искә төшерерсең.
Тикшерүче рәшәткәле тәрәзәгә карап бераз уйланып торды да:
— Петров, алып кит! — дип кычкырды.
Ишектә кобурасын бил каешына таккан милиционер күренде, куе зәңгәр гимнастеркасын тарткалап, Әнис янына килде дә авыр кулын аның җилкәсенә куйды:
— Киттек.
Урамга чыгуга каршыларына тупыллардан юмарт коелган мамыкларны тирә-якка очырып, ашыга-ашыга килүче Сафа Нәсихов, курсташлары Илгиз Сәләхетдинов, Идмас Фәсхетдинов, Вәгыйз Миңнуллин, тагын берничә егет очрады.
Әнис:
— Сафа абый, бу нәрсә соң инде? Минем бер гаебем дә юк бит! Ярдәм итегез. Моны карт әти-әни ишетсә, авырып егылачаклар. Аларга ишеттерә күрмәсеннәр, зинһар, — дип туктап калды.
Директор:
— Гаебең булмаса, бары да ачыкланыр, Әнис. Син артык борчылма, — диде.
— Сөйләшергә ярамый. Киттек, киттек. — Милиционер Әнисне КПЗга алып китте.
Әнис:
— Әнисәне һаман тапмадыгызмыни? Ул кайда икән соң? — дип сорарга өлгерде.
— Юк шул әле. Беркайда юк.
Әнис директор белән килгән егетләргә берни әйтергә өлгерә алмады. Аның күз алдыннан Идмасның мыскыллы карашы гына чагылып китте. Ул арада Илгиз, килеп:
— Әнис, кайгырма. Без сезнең Әнисә белән нинди дус йөрүегезне аңлатырбыз. Сине озак тотмаслар! — дип кычкырып калды.

## 15

Икенче көнне дә Әнистән шул ук тикшерүче сорау алды. Әнис бүген аның йөзендә нindидер үзгәреш барын шәйләде.
— Йә, егет, инде барын да сөйләп бирергә булдыңмы, юкмы? — диде ул. — Әллә һаман үз сүзеңдә торасыңмы?
Төне буе йоклый алмыйча пычрак, караңгы камерада аунаган Әнис бик йончыган, хәлсезләнгән иде. Күз кабакларын көчкә күтәреп, ул тикшерүченең йөгерек күзләренә текәлде.
— Гражданин Лотфуллин, син сорауны ишеттеңме?
— Ишеттем. Мин кабат шуны гына әйтә алам. Мин Әнисә Әхмәдуллинага кагылмадым. Мин аны яратам. Ул да мине ярата. Әнисә пристаньда озатып калганнан бирле минем аны күргәнем юк. Безне аның белән очраштырыгыз, ул табылдымы? — диде дә Әнис сыгылып төште. Ул әле дә сасы камера исеннән айный алмый иде.
— Син гаебеңне танысаң, үзеңә хөкемне җиңеләйтә төшәрләр иде. Йә, ярар... Син менә бу әйберне таныйсыңмы? — Хәйләкәр елмаеп, тикшерүче Әнис йөзенә текәлде.
— Минем югалган пәкем ич бу. Сез аны каян алдыгыз?
— Димәк, пәке синеке. — Урындык тагын күсе тавышлары чыгарып куйды. — Яхшы. Шулай дип язып куйыйк. Югалган иде, дисең инде. Ә кайчан, кайда югалтуыңны беләсеңме?

— Каян белим? Белсәм, шуннан гына табып алган булыр идем, — диде Әнис, көлемсерәп.

— Димәк, белмисең. Ә мин беләм. Җинаять урынында югалткансың син аны. — Тикшерүче күз кырые белән генә үз сүзләренең Әнискә тәэсирен күзәтте.

— Тагын җинаять... Мин бернинди дә җинаять эшләмәдем.

— Син пәкене кайчан югалттым дисең әле?

— Әллә кайчан... Яз башында ук инде.

— Ә җинаять урынына ул ничек барып чыкты икән, ә? Үз аягы беләнме?

— Пәкем югалгач, тулай торакның бүлмәсен егетләр белән кат-кат актарып чыктык без. Таба гына алмадык.

Тикшерүченең йөзенә караңгылык йөгерде. Аның ышанасы килмәве күренеп тора иде:

— Бу кайчан булды дидең әле? Кышынмы?

— Яз көне дидем ич инде.

— Моны кем раслый ала?

— Классташ, бүлмәдәш егетләрнең күбесе. Илгиз Сәләхетдинов, Хәтмулла Кәримов, Идмас Фәсхетдинов. Бүтәннәр дә. Ул пәке миңа Әнисә бүләге.

— Ә пәкегә «Ә.Л.» дип үзең тамга салган идеңме? — дип дәвам итте тикшерүче.

— Ничек? Нинди «Ә.Л.»? Кая, карыйм әле.

— Кагылма. Урыныңда гына утыр.

— Мин бернинди тамга да төшермәдем. Шундый матур пәкенең сөяк сабын бозалар димени?

— Ә яратып йөргән кызыңның сафлыгын бозсаң да ярыймы? Йә, ярый. Бар, кайтып тор.

— Әллә мине чыгарасызмы? — Әнис шатланып китте.

— Һәй, нинди өлгер син. Ашыккан ашка пешкән.

— Уф... үләм...

— Үлмисең әле, үлмисең...

Әнисне тагын камерага алып киттеләр. Ул гаебем юк дип әйтеп тора бит инде. Нишләп соң аны һаман ябып тоталар? Бу мәхшәр кайчан бетәр? Хәзер аның бөтен тормышының асты өскә килде. Менә сиңа университет. Әле кайчан гына алар Әнисә белән киләчәккә нинди матур планнар корганнар иде. Бергә тормыш итәргә вәгъдәләшкәннәр иде. Шулай итеп, бу хыялларның барысы да күккә очты микәнни? Аның хәзер бар өмете дә киселдемени?..

## 16

Күптәннән аралашмаган Әнисә хәбәр бирми-нитми Кырынгыга кайтып төшкәч, Сәрия апасы гаҗәпләнә калды. Әнисәнең йончыган кыяфәтенә, соргылт йөзенә карап, пошаманга бирелеп сораша башлады: нәрсә булды, ник кайттың, каникулгамы, укуыңнан кумаганнардыр ич, әйберләрең кайда?..

— Мин берничә көнгә генә. Шаршудыга барып әнием кабере белән саубуллашам да китәм, — диде Әнисә.

— Тукта әле, тукта. Гомер эчендә бер күрешеп дигәндәй... Кая ашыгасың? Ишле гаилә булганга бездә әллә ни сый булмас инде ул. Хәлдә барынча кунак итәрбез. Әнә җизнәң дә шулай ди. — Сәрия апасы иренә сораулы караш ташлады.

Тегесе:

— Дим, дим, — диде, төксе генә.

— Мин кунак булырга кайтмадым, апа. Ачуланма, артыгын сорама да. Аңлатырмын әле бер. Йомышымны соңрак әйтермен.

Сәрия Әнисәнең йотлыгып катык ашаганын күреп, аның ачykканын аңлады. Туганының артык ачыласы килмәгәнен чамалагач, төпченеп тормады. Йомышымны соңрак әйтермен, диде ич. Төнлә Әнисәнең авыр ыңгырашканын ишеткәч, янына барып озаклап карап торды. Саташа да, ахрысы. Берәр бәхетсезлеккә юлыкканмы икән әллә?

Кайтканның икенче көнендә Әнисә апасына мунча ягарга булышты, сеңелләрен юып чыгарды. Үзе дә юынып чыкты.

Балалар белән мәш килгәч, тәне генә түгел, җаны да җиңеләйгәндәй булды. Күзләрендә аз-маз нурлар кабынып китте.

Шаршудыга барып кайтыйм, дигәч, Сәрия апасы аңа ике йомырка, бәрәңге кушып пешергән кабартмалар төйнәде. Нәни Рәхимҗан бу вакытта әнисе янында бөтерелде. Аның:

— Миңа да йомырка бир. Әни, дим, минем дә йомырка ашыйсым килә, — дигәнен ишеткәч, Әнисә тетрәнеп куйды. Йомыркаларның берсен Рәхимҗанга тоттырды. Бу йортта мин артык кашык лабаса. Тизрәк китәргә кирәк. Тик кая барырга соң, дип уйлады ул.

Шаршуды зиратына ул арт урамнан барып керде, чөнки аның беркем белән дә очрашасы килмәде. Хәер, аны танырлык кеше монда калдымы икән соң? Ул бит бик яшьли ятимнәр йортына эләкте. Шактый эзләгәч кенә ул әнисенең каберен тапты. Кабер янындагы куе үләнгә утырып уйга талды.

— Әнием, бәгърем, син минем хәлемне беләсеңме икән?! Менә хәзер миңа нишләргә инде? Син ничек киңәш итәр идең?

Тик аңа кем җавап бирсен соң?

Зиратта тын гына басып торган каеннарның җиңелчә җилдән лепелдәгән яфраклар тавышыннан башка бернинди тавыш та юк иде. Монда килгәч Әнисә тагын елармын дип уйлаган иде. Тик еламады. Елый алмады. Әллә инде күз яшьләре беткән, әллә аның иңнәренә ишелгән авыр хәлен сизенгән туган җире Әнисә җанына тынычлык иңдергән иде.

Әнисә кечкенәдән үк әбисеннән өйрәнгән бер-ике дога укыды да хушлашырга дип башын кабергә куйды. Шул мизгелдә аның күңелендә моңа кадәр таныш булмаган хис уянды. Кыз талпынып куйды. Аның әнисе ана булып дөньядан китте. Ә ул? Үзе? Беркайчан да ана булмаячакмыни? Дөньяның нинди зур гаделсезлеге бит бу! Миһербансыз бер адәм аны пычратты, мәхәббәтеннән аерды. Баланы бит аны сөйгән кешеңнән генә табалар. Югыйсә балаңны ничек сөясең? Димәк, ул да бәхетсез бала тапмаячак. Беркайчан да ана булмаячак. Кинәт аның башына коточкыч бер уй килеп, миен бораулый башлады. Әйтерсең лә Әнисәне баштанаяк кайнар су белән коендырдылар, ул хәтта бөтен тәне кызыша башлаганын тойды. Теге хәлдән соң балага узган булса! Үз хәленең тагын да хәтәррәк икәнен ул менә әле генә төшенде. Нишләрмен, кая барып егылырмын, кеше күзенә ничек күренермен? Мондый хурлыкка түзеп яшәгәнче яшәмәвең хәерлерәк түгелме дип борчылды ул.

Авыр уйларына бирелеп, Әнисә шулай шактый утырды. Инде көн сүрелеп бара, кайтырга кирәк иде. Алда бары авыр билгесезлек, бәхетсез көннәр дәвамы. Юлда аңа кемнәрдер очрады, нидер әйттеләр, сораштылар, тик ул боларны төштә күргән кебек шунда ук онытты. Аны бер генә уй биләде — каядыр барырга, нидер кылырга кирәк, тик нәрсә — Әнисә моны тәгаен белми иде. Бермәлне кылт итеп аның күз алдына Әнис килеп басты, әмма бу аның хәлен тагын да авырайта төште. Әнис инде еракта, бик еракта, бәхетле, мәхәббәтле тормышта, томан эчендә калды.

## 17

Әниснең үтенечен тыңлап, аны машинага утыртып пристаньга алып киттеләр. Куаклар юлга якын үскән бер урында туктап машинадан төшерделәр. Әниснең йөзен, үз-үзен тотышын җентекләп күзәтеп торган тикшерүче бу куаклар янында аның тынычсызлануын көткән иде. Ләкин Әнис башын игән килеш уйга талып тик басып торды. Йә тикшерүченең, йә машина йөртүченең куаклар арасына кереп хаҗәт үтисе килгәндер дип кенә уйлады. Куе кара кашлы тикшерүче бераздан:

— Бу куакларны танийсыңмы? — дип сорады.

Әнис гаҗәпләнде:

— Юл кырыендагы үскән барча агач, куакны ник танырга тиеш соң әле мин? Моның нәрсәгә кирәге бар?

— Ярар, танымасаң, киттек алайса. Әнисәң, менә шунда көчләделәр, дигән иде.

Пристаньга килеп җиткәч, Әнисне пассажирлар залына алып керделәр. Залда беркем дә юк иде. Яшь кенә милиционерны сакта калдырып, тикшерүче каядыр чыгып китте. Егетнең йөрәге тагын әрнеп-әрнеп тибә башлады. Әле кайчан гына алар Әнисә белән бирегә пароход көтеп, вак дулкыннарның чупылт-чупылт пристаньга бәрелеп күбекләнеп торуларын озак-озак карап тордылар. Кояшның кызарып, зураеп, аргы як яр артына төшеп китүен күзәттеләр. Шул чакта Әнис:

— Менә Җир шарының түгәрәклеген исбат иткән бер мисалны үз күзебез белән күзәттек, — дип, сөйгәнен көлдереп алган иде. Ә менә бүген! Кем уйлаган мондый хәлләрне? Ничек килеп чыкты соң бу?.. Әниснең җылы су, суүсемнәр исеннән тагын башы әйләнә башлады.

Зал ишеге сискәндереп кинәт ачылып китте, аннан тикшерүчегә ике ир-ат ияреп керде. Әнис аларны шунда ук танып алды. Болар теге көнне пристань тросына бәреләзябып килеп туктаган балыкчылар иде. Алар зал уртасына уздылар да Әнискә текәлделәр. Түземсезлек белән аларны көтсә дә, Әнис үз хәленнән уңайсызланып, оялып читкә борылды. Ә шулай да аның миеннән боларның ярдәме тими калмас дигән уй узды.

— Йә, — диде тикшерүче, ирләргә карап.

— Шул бит, — диде тегеләрнең берсе, иптәшенә карап.

— Әйе, шул егет, шул. — Икенчесе дә иптәшенең сүзен җөпләде. — Бу егет бик боевой бер кыз белән пароход килгәнне көтеп торды.

— Кайсы көнне инде ул?

— Исеңдәме, Коля, ул көнне без бик зур чуртан каптырган иек. Менә шуның хәтле. — Балыкчы, кулларын җәеп, тикшерүчегә борылды. — Мин спиннингны ыргытуым булды, кинәт леска бик нык тартылып читкә атылды. Мин әле Коляга әйтеп куйдым. Бу ике-өч килолы боевой чуртан булса, мин әйтәм, бер ярты алабыз инде, дим. Шулай булды да. Коля белән без ул чуртанны көчкә тартып чыгардык, әйе. Аны күрүгә минем хатын...

— Туктагыз әле. Анысы соңыннан...

— Соңыннан дип... Өч килолы боевой чуртан бит ул көн саен эләкми, парин. Хет елап утыр... көне буе...

— Аңлашылды, аңлашылды... Әйтегез әле, бу егет үзе генә идеме?

— Әллә шаяртасыз инде, иптәш тикшерүче! Нишләп үзе генә булсын. Аның янында бик чибәр боевой бер кыз да бар ие, дим ич.

— Әйе, әйе. Алар гел кочаклашып басып тордылар. Без кирәк-яракны, балыклы чиләкне көймәдән алып чыкканны карап калдылар. Үзләре гел елмаялар, безгә карап нидер сөйләшеп алалар.

Боларны ишеткәч, Әниснең эченә җылы йөгерде. Ул торып басты. Милиционер аны җилкәсеннән этеп кабат урынына утыртты.

— Әйе шул. Мин әле Степанга әйтеп куйдым. Их, мин әйтәм, нинди матур чаклары боларның... — Ирләрнең Коля дигәне кабат сүзгә кушылды.

— Ә ул кыз нинди күлмәктән иде?

— Кыска җиңле җәйге, көнбагыш чәчәге төшерелгән җиңел күлмәк кигән ие. Без әле аның күлмәге үзенә бик төс килгән икән дип сөйләшеп тә кайттык.

— Чибәр кыз, бик чибәр кыз иде, әйе.

— Күлмәге ертылмаган, чиста идеме?

— Ну инде...

— Сез аларны якыннан күрдегезме?

— Алар белән безнең ара 5–6 метрлап булгандыр инде.

— Әйе, шуннан артык түгел. Без көймәне пристань тросына бәйләп, йозакка бикләп калдырабыз.

— Алайса, сез инде бернинди дә шикле нәрсә күрмәдегез. — Тикшерүче һаман үз ягына каерды.

— Нинди шик инде ул. Без киткәндә дә алар кочаклашып басып карап калдылар, дим ич.

— Ярар, инде китсәгез дә ярый. Файдагыз тимәде. Кирәк була калсагыз, чакыртып алырбыз. — Тикшерүче канәгатьсезлеген яшерүне кирәк тапмады.

Балыкчылар Әнискә борылып карый-карый чыгып киттеләр. Берсе, ишек төбендә туктап, Әнискә күз кысты. Тикшерүче моны күреп калды. Аның башына берәр уй килде бугай, ул, тиз генә ишекне ачып:

— Сез сәгать ничәләрдә кайтып киттегез? — дип кычкырды.

— Сигез, тугызынчы яртылар булгандыр. Кояш әле баемаган ие, — дигән җавапны ишеткәч, тикшерүче Әнискә төбәлде.

Әниснең йөзенә алсулык йөгерде, ул еш-еш сулыш алып торып басты.

— Менә күрдегезме, — диде ул. — Минем гаепсез икәнемне хәзер аңладыгызмы инде, ә? Җибәрегез мине. Мин дә сезгә Әнисәне табарга булышыйм.

— Ашыккан ашка пешкән, дип әйткән идем инде мин сиңа. Боларның сүзе берни дә расламый әле.

— Ничек инде? Алар кочаклашып тордылар диделәрме? Көчләнгән кыз кочаклашып торыр идеме?

— Алар сезне сәгать сигезләрдә, тугызынчы яртыларда күргәннәр. Шулаймы?

— Шулай. Йә, шуннан?

— Әйтик, тугыздан соң пароход килгәнче күпме вакыт бар?

Әнис лып итеп урындыкка утырды. Эш тагын кире якка борылды, күңелендә туган өмет чаткысы кабат сүнде. Күз алдына ниндидер кара шәүлә килеп басты.

— Беләсезме нәрсә! — диде Әнис, кинәт кенә. — Без пароход килгәнне көтик алайса.

— Ни пычагыма? — Инде үзе дә йончый төшкән тикшерүче тагын усал карашы белән Әнискә текәлде.

— Бәлки, мине «Свирьстрой»ның капитаны йә берәр матросы таныр. Мин Казанга шул пароходка утырып бардым бит.

— Юк инде, егетем. Башка вакытта...

— Сез тәҗрибәле кеше ләбаса. Башка вакыт булмаска да мөмкин. Күргән кешеләрнең безне онытуы, эшләрен ташлап китүе ихтимал. Үтенеп сорыйм, зинһар, пароходны көтеп алыйк без.

Тикшерүче икеләнә калды:

— Һе... Безнең дә нәчәлство бар. Киңәшеп алыйм әле, булмаса.

Ул телефонлы бүлмә эзләп чыгып китте. Аның кире килүен көтә-көтә Әнис гаҗиз булды. Аның өчен хәзер бердәнбер өмет шул пароход кешеләрендә калды. Әгәр алар Әнисне танып, Әнисәнең яулык болгый-болгый озатып калганын әйтсәләр, котылачак бит ул, котылачак. Тикшерүче, сыра исе аңкытып, авызын сөртә-сөртә кире килгәнче Әниснең күңелендәге өмет йөз мәртәбә кабынып, йөз мәртәбә сүнеп өлгерде.

— Ярар, синеңчә булсын. Нәчәлство каршы түгел. Көтик алайса, — диде тикшерүче.

...Ниһаять, тирә-юньне яктыртып пристаньга пароход килеп туктады. Шыгырдатып басманы пристаньга сузганны көткәндә Әниснең йөрәге ярылырга җитеп кага иде.

Аның колагына тагын тикшерүче бүлмәсендәге теге сәгатьнең ярсып-ярсып типкән тавышы ишетелеп китте. Пароходтан чыгучылар да, керүчеләр дә аз иде. Тикшерүче Әнисне милиционер карамагында калдырып чыгып китте дә бераздан пароход капитанын ияртеп кире керде. Ул эшне аңлаткан булган, күрәсең, капитан бүлмәгә керүгә, Әнискә карап:

— Шушымы? — дип сорады.

Тикшерүче баш какты.

Капитан бер якынрак, бер ераграк китеп Әнискә карап торгач:

— Әллә тагын... Пароходка утырган кешеләрне каян танып бетерәсең. Пассажирлар пароходка кергәндә бер-берсен чүт кенә таптамыйлар. Юк, әйтә алмыйм, гафу итегез, мин эштә, — дип чыгып китте. Әнис өнсез калды. Инде бөтен өмет матроста иде.

20–25 яшьлек куе кара чәчле, шомырттай кара күзле, беләкләре бүлтәеп чыккан матрос егет, бүлмәгә килеп кергәч, башта аптырабрак торды.

— Минем милиция, прокуратура белән беркайчан да эш иткәнем юк. Аллам сакласын, — диде ул.

— Ярар алайса, бик әйбәт, — диде тикшерүче. — Сез менә бу егетне танымыйсызмы?

Әнис торып басты да аңа ялварулы караш ташлады.

— Һо! Бәхетле егет, бу синме? Ни булды?

Тикшерүче:

— Таныйсызмы, юкмы? — диде, коры гына.

— Кәнишне, таныйм.

— Кайда күрдегез? Сез аның белән танышмы?

— Таныш түгел түгелен. Берәр атна булыр, аны бик чибәр кыз елый-елый озатып калды. Ну чибәр иде, первый класс. Шуңа күрә без әле бер-ике пассажир белән бу егетне нинди бәхетле дип сөйләшеп алдык. Сиңа нәрсә булды соң, егет? Милиция...

— Әйе, бәхетем минем хәзер ташып тора менә.

— Ул кыз елый иде, дисез инде? — Тикшерүче үз ягын каера бирде.

— Егете дә нинди бит аның! Еларлык шул. Алар бер-берсенә шулкадәр пар килгәннәр, әй. Кара син аның дулкынланып торган чәчләрен! Кашларын!

— Бәлки, ул үпкәләп йә берәр башка сәбәптән елагандыр?

— Анысын белмим. Бәлкем, аерылып калу авыр булгандыр. Пароход киткәнче кочаклашып басып тордылар. Мин басманы алам бит, дигәч кенә, менә бу бәхетле егет кереп утырды. Мин әле соңыннан да күз салгаладым. Ул кыз бик озак яулык селкеп, кул изәп калды. Кереп утырыр алдыннан егетне үпте дә бугай. Вәт шул.

— Тагын берәр шикле нәрсәгә игътибар итмәдегезме? Киемендә, әйтик.

— Иттем. Матур күлмәген кабартып торган матур имиләренә. Ну, егет, син чыннан да бәхетле икәнсең. Йә, ярар, беттеме? Кул куясы түгелме? Йөгерим, безнең капитан ул — коры кеше. Кстати, ул төнне яшенле яңгыр булды.

— Ярар, рәхмәт, хушыгыз.

— Хушыгыз. Егет, хуш. Кызың бик чибәр синең, саклый күр син аны.

Матрос йөгереп диярлек чыгып китте. Ул арада «Свирьстрой», өченче сигналын биреп, яңа туып килгән айның су өстендәге алтын күперенә юл тотты.

...Ике көннән Әнисне ирекккә чыгардылар. Ә аның Әнисәсе суга төшкән кебек юк булды.

## 18

Чарджуй шәһәрендә ул көнне бик көчле җил чыкты. Күкне тузан болыты каплады, хәтта кояш та күренмәс булды. Әнисә яши торган йорт каршындагы тупыл төбе-тамыры белән гөрселдәп юлга ауды.

Тузан тәрәзәләрдән, ишекләрдән бүлмәләргә кереп тулды, шкафларга, өстәл-урындыкларга калын катлам булып ятты, кешеләрнең күзләренә керде, тешләрендә чытырдады.

Әнисәнең биредә мондый көчле туфанны беркайчан да күргәне юк иде. Җил котырынып исә башлагач, ул ишек-тәрәзәләрне япты, аннары йорт хуҗасы Саҗидә апасы янына икенче бүлмәгә чыкты да аңа сыенды.

— Курка калдыңмы әллә, Әнисәкәй? — диде апасы. — Була ул мондый хәлләр бездә, була. Көньяктан эссе җил исә дә чүлдән әллә нинди тузан өермәләре алып килә. Мәхшәр! Без чүл уртасында яшибез ләбаса. Чарджуй Ташкент та, Ашхабад та түгел шул. Асфальт аз, тузан оясы инде бер карасаң.

Әнисә моның шулай икәнен ел ярым элек килеп урнашуга ук белде. Ул тимер юл вокзалына килеп төшкәч, Сәрия биргән адрес белән Саҗидәләрне эзләп йөргәндә урамнан узып барган 15–16 яшьлек малайлар, кызларның яланаяк йөрүенә игътибар иткән иде.

Урамда калын булып яткан тузанны сөреп кенә баралар! Соңыннан моны Саҗидәгә сөйләгәч, апасы:

— Әй, сеңелкәй, без моңа гадәтләнгән инде, — диде. — Ничек кенә сакланып йөрмә, берәр җиргә барырга чыксаң, тездән тузанга батып кайтасың. Кая инде монда аяк киемнең чисталыгы!

Ләкин ничек кенә булмасын, Әнисә үзе укыткан класс укучыларын — төрекмән, рус балаларын чисталыкка өйрәтергә тырышты. Балалар мәктәпкә керер алдыннан җәй булса, аяк киемнәрен селкеп, кагып, башка вакыт булса, кырып юып, яхшылап сөртеп, чистартып керә торган булдылар. Училищеда өйрәнгән гадәт монда бик ярап куйды.

Давыл котырынды, ә яңгыр яумады. Җил басылгач, Әнисә бүлмәләргә кереп тулган тузанны сөртте, идәннәрне юып чыгарды.

Саҗидә:

— Рәхмәт сиңа, Әнисәкәй. Менә Низам абыең кайтканчы ялт иттердең, — диде. — Әнә гомере озын булыр, кайтты да бугай.

— Ул түгелдер. Ул булса, капка кагып тормас иде. Кемдер кечкенә капканы кага ич анда, — диде Әнисә. — Кая, чыгып ачыйм әле.

— Юк, үзем ачыйм. Ә син өстәл әзерли башла.

Саҗидә кечкенә капка келәсен ачкач, анда бер ят кеше пәйда булды.

— Сәмәрканд урамы, 13 нче йорт шушы буладыр бит инде, — диде бу ир-ат, тирә-ягына каранып. — Тәки таптым бит.

— Сез кем буласыз соң? Бер дә күзгә-башка күренгәнегез юк шикелле иде?

— Мин ерактан, Татарстаннан килдем, апа.

Апа дигәч, Саҗидә ир кешегә төбәлебрәк карап алды. Әйе, дөрестән дә, апа диярлеге бар икән. 24–25 яшьләрдә булырдыр шул, дип уйлады Саҗидә. Башта гына олырак булып күренгән икән. Бакыр сыман чәчле. Күзләре ничектер сәер карый. Әле изүгә, әле чәч-башка карашы төшә, гәүдәсен дә тиз генә күзе белән сыпырып алды.

— Татарстаннан укмыни?

— Әйе. Миңа менә шушы адресны биргәннәр ие. Әхмәдуллина Әнисә монда яшиме?

— Монда, монда. Әйдә, узыгыз, уз. Әнисәү, менә монда бер егет сине сорый, карале.

Ишек шыгырдап ачылып китте. Аның уемында изүен яба-яба Әнисә күренде.

— Әнисә! Таптым бит, таптым! — дип, егет шатлыгыннан нишләргә белмичә аның янына ашыкты.

— Абау! — Әнисә аптырап хәтта чигенеп куйды. — Идмас димме? Каян, ничек болай? Әллә сине давыл китереп ташладымы?

Әнисә кинәт, очынып барып, Идмасның муенына сарылды.

— Каян килеп чыктың син? Каян?!

— Әнисә, кунакны йортка алып керик. Болай ярамый инде. — Саҗидә Әнисәнең кунакка сарылуын ошатмады бугай. — Әйдәгез, узыгыз. Хәзер хуҗа абыегыз да кайтып җитәр.

Әнисә Идмас куеныннан чыкты да шатлыклы күз яшьләрен сөртә-сөртә ишеккә юнәлде. Идмас аңа иярде. Кызның алсуланып киткән яңаклары, төз, матур аяклары, сылу гәүдәсе, муенына килеп асылынганда тиеп киткән йомры күкрәкләре аңарда күптәнге хисләрен уятып җибәрде. Ләкин егет үзенең соклануын яшерергә тырышты.

— Димәк, син шушында качып ятасың икән, — диде ул. — Без сине эзли-эзли аптырап беттек.

Әнисә һаман ни әйтергә дә белмәде, ул каушаган иде.

— Качып дип. Юк, тик...

— Ә мин кичә төнлә килеп төштем. Чемоданымны саклык камерасына тапшырдым да вокзалда кундым. Урындыкта озак йокланылган. Адресың белән эзләргә чыгарга дип торганда давыл купты. Инде менә... килеп таптым.

— Ярар... йә, сөйлә, Идмас, анда ниләр бар? Утыр, утыр. Кайда яшисең, кайда эшлисең? Бергә укыган кызлар, егетләр кайларга таралып бетте? Аралашасызмы? Монда ник киләсе иттең?

Әнисә сорау артыннан сорау яудыра башлады. Бу аның каушап калуын яшерергә тырышуы булды, күрәсең. Һич көтмәгәндә бөтенләй чит-ят җирләрдә Хозыр Ильяс шикелле кинәт шулай килеп чыксыннар әле. Икенчедән, ул бит киткәннән бирле Сәрия апасыннан башка беркем белән аралашмады, хат та алышмады. Анда да сирәк кенә... Аның Төрекмәнстанда икәнлеген бары тик Сәрия апасы гына белә иде. Бары ул гына. Идмас аның адресын Сәрия апасыннан алган микәнни? Нәрсәгә? Ә апасы ник биргән инде? Әнисә бит аңа, адресымны беркемгә дә бирмә, дигән иде. Әнис исемле егет сорап килсә, бигрәк тә.

— Әнисә, Әнисә, дим, аннары, аннары... Кунак кеше шундый ерак юл килеп арыгандыр, әйдә башта чәй эчерик. Әйдә, табынга килегез, — дип, Сәҗидә яшьләрне чәйгә өндәде.

— Апа, мин сезне Сәҗидә апа дип беләм. Дөресме? Димәк, дөрес әйткәннәр, алдамаганнар. Ә мин ышанмаган да идем. Туктагыз әле, мин башта чемоданымны алып килим. Чәйне аннары эчәрбез. Анда күчтәнәчләрем дә бар ич.

Идмас йөгереп диярлек чыгып китте. Ул авыр чемоданын күтәреп вокзалдан кайтканда, Низам да өйдә иде инде.

— Алайса, син безнең Әнисәне эзләп килдең инде. Мин шулай дип беләм, — диде ул Идмаска, чәй эчкәндә. — Эзләрлек тә шул. Чибәрлеге белән таң калдыра ул. Монда әнә сөлек шикелле төрекмән егетләре дә ул килгәннән бирле безнең урамны үз иттеләр.

Болай туры бәреп сөйләшүдән Идмас бераз каушабрак калды.

— Эзләп дип... Без бит... бер училищеда укыдык...

— Шуның өчен генә дөнья читенә килеп чыкмыйлар, егетем. Бергә укыган кеше күп булыр ул, иеме, Сәҗидә?

— Йә инде, Низам, кунак кешегә бәйләнеп утырма. Менә ул алып килгән кетермәнне кимер. Арыш икмәге сохарие. Без инде аның тәмен дә оныткан идек. Монда бит лаваш та лаваш.

Хуҗаның йөзе яктырып китте:

— Менә анысы өчен рәхмәт, Идмас энем. Рәхмәт. Үпкәли күрмә, мин үз балаларымны да туры юлдан гына йөрергә, дөресен генә сөйләргә өйрәттем, Аллага шөкер. Менә дигән кеше булып үсеп җиттеләр. Улыбыз Мәскәүдә зур бер хәрби институтта эшли. Кызыбыз нефть институтында Казакъстанда укыта. Вәт шулай. — Низам горур иде.

— Сез бик бәхетле ата-ана икәнсез. Ә монда ничек килеп чыктыгыз соң?

— Без кечкенә чакта ук әти-әниләр монда күчеп килгәннәр ие. Сәҗидә апаңның да, минем дә. Кайта гына алмадылар.

— Әйе, әти-әниләр туган як дип өзелеп сөйлиләр иде. — Сәҗидә дә сүзгә кушылды. — Күрә алмый гына вафат булдылар. Бик сагыналар ие шул.

— Ник кайтмаганнар соң?

— Дөнья бит, аның мәшәкатьләре... Колхозлашу, кулакларны сөрү. Туганнарыбызны Себергә сөргәннәр... Анда ничек кайтасың?

— Әйе... Булган шул андый хәлләр, булган.

— Йә, ярар. Бүгенгә җитеп торыр. Син безгә туган яклар турында бәйнә-бәйнә сөйләрсең. Озакка килдеңме соң?

— Белмим әле. Бәлкем, монда торып та калырмын... Әйеме, Әнисә? Әнисә менә нәрсә дияр.

— Әйттем бит, юкка килмәгәнсең дип. Әнисә шикелле багалма йөгертә ул. Тик кара аны, мотри! — Низам, шаярып, Идмаска бармак селкеде.

— Низам абый, син нәрсә инде, — Әнисәнең бит очлары алланып китте. — Каламы, юкмы, аның үз эше. Биштән үткән, бишектән чыккан, диләрме әле. Минем моңа ни катнашым бар... Дөнья иркен.

— Ярар, ярар. Болай гына әйтүем. Яшьләр эшенә борын тыгуым түгел. Ходай язганча булыр.

## 19

Яшьләр көннәр буе сөйләшеп туя алмадылар. Бигрәк тә Әнисә кунактан барын да бәйнә-бәйнә сөйләтте. Татарстанда нәрсәләр бар? Халык һаман шулай авыр яшиме? Классташларының кайсы кайда эшли? Куйбышев сусаклагычы төзелү сәбәпле шәһәрне дә, педучилищены да бүтән урынга күчерү турында карар чыккан иде, ул эшләр ничек бара? Аның классташлары Лилия, Фирдәвес кайда икән?

— Әйе, шәһәр күченә. Училище укучыларын, укытучыларын Арчага күчерделәр дә инде. Классташларың кайсы кая юллама алып, эшкә урнашып бетте, — диде Идмас. — Ник син Әнис турында

сорамыйсың әле? Ул Казанда. Университетка кергән. Укып йөри, ди. Таҗсыз патша булырга. Имеш, өйләнергә дә исәбе бар икән... Илгизәр дусты Сәлимәгә өйләнгән.

Боларны ишеткәч, Әнисә тетрәнеп китте. Дулкынлануын яшерергә тырышып, әле чәйнеккә, әле чәшкегә сузылды. Идмас моны сизде, карашын стенада текелдәгән сәгатькә күчергән булып, Әнисәне күзәтте. Чибәр шул, чибәр. Хәзер тагын да тулыланып, матураеп киткән. Йөзе дә көньяк кешеләренеке кебек каралып тора.

— Әнис тә, уку еллары да артта калды шул инде. Истәлек булып, әрнүле истәлек булып, Идмас, — диде Әнисә. — Ярар, син үзең бит бездән ике-өч яшькә олырак идең. Армиядә түгелмени соң?

— Юк, алмадылар. Күздән гаеп тапкан булдылар. Мин моңа бер дә гарьләнмим лә. Өч-дүрт ел вакыт әрәм иткәнче, берәр вузга керермен дип торам. Син рөхсәт итсәң.

Идмас сүзен уенга санаган булып көлеп куйды, ә үзе Әнисәнең йөзе кинәт җитдиләнүгә игътибар итте.

— Минем синең тормышыңа бер катнашым да юк. Синең үзеңнеке, минем үземнеке, — диде Әнисә.

— Икебез дә ятимнәр, беркемебез дә юк. Бергә укыдык, бергә тәрбияләндек, дип кенә әйтүем. Гел чит кешеләр түгел ләбаса. Киңәш итүем дип аңла.

— Синең Зинаң бар иде ич. Ул кайда хәзер? Сез ник бергә түгел?

— Ул никтер миннән йөз чөерде. Хәзер бер ир бала тәрбияли дип ишеттем. — Идмас теләр-теләмәс кенә җавабын теш арасыннан кысып чыгарды.

— Бик дус йөрдегез ич. Ничек инде?

— Ярар ла. Рус кызының татар малае белән нинди уртаклыгы булсын. Менә син үзең турында берни сөйләмисең. Нишләп училищены ташлап киттең. Бөтен шәһәрне аякка бастырып. Сине кайдан гына эзләмәдек без. Сулыклардан, урман-болыннан. Училище, тулай торак чарлакларын әйтеп тә торасы юк. Милиция дә эзли-эзли аяксыз калды. Ә син монда качкансың икән.

— Качмадым мин... Ни дип әйтим... Шулай килеп чыкты инде. Син менә мине ничек таптың?

— Сәрия апаң синең документларыңны, әйберләреңне сорап хат язган ие. Училищега. Шуннан аның адресын белдек. Синекен сорап кат-кат хат язып, аптыратып бетердек. Җавабы бер булды — юк, белмим. Эзләгез, табыгыз, мин аның бердәнбер туганы, дип тукыды. Онытып торам, Сафа абыйны бик каты шелтәләп гади укытучы итеп башка училищега күчерделәр.

— Кызганыч. Ә син минем монда икәнлегемне каян белдең, дим?

— Сәрия апаңнарга бардым. Ире салгаларга ярата икән. Эчкән кеше ихтыяры слабый була инде ул! Сандыкларыннан синең хатларны эзләп тапты инде. Башкасы инде аның, кем әйтмешли, дело техники. Хи-хи-хи.

Идмас Әнисннең Сәрияләргә берничә хат язуын белсә дә әйтмәде. Әнис тә: «Әнисәнең кайда икәнлеген белмисезме? Белсәгез, зинһар өчен, миңа аның адресын бирегез әле», — дип язган иде. Әнисә үзе беркемгә дә берни әйтмәскә кушкач, Сәрияләр серне ачмадылар. Әнис исемле егет кызыксынса, бигрәк тә, дигән иде ич. Идмас алардан үз хатына башта кыска гына «белмибез» дигән җавап алды. Никтер ышанмады. Һәм теләгенә иреште дә. Сәриянең ире Гыйбадулланы шәплэп сыйлады. Гыйбадулла җаен туры китереп, хатынына тишми генә Әнисәдән килгән хат адресын күрсәтте.

— Дело техники, дисең инде. — Әнисәнең күзләрендә ачулы очкыннар уйнап алды. — Алай икән... Син шуннан соң Әнисне бөтенләй күрмәдеңме?

— Әйттем ич инде. Юк. Укырга кергән, өйләнергә йөри икән, дип.

— Анысын ишеттем. Мин югалгач, ул шулай тыныч кына йөрде дип әйтмәкче буласың инде син, әйеме? Ә?

— Сине көчләгән дип аны кулга алдылар ул чакта.

— Әнекәем! Миленький! — Әнисәнең йөзе ап-ак булды.

— Курыкма, курыкма... Озак тотмадылар. Чыгардылар. Гаепсез булган, имеш. Кем белә инде сезнең хәлләрне... Бик дус булып йөрдегез бит. Син, бәлкем, аны үзең йолып калгансыңдыр әле. Кагылмады, дип. Шулаймы?

— Ул шундый әшәкелеккә бара алыр дип уйлыйсыңмыни син? Аның чыннан да бернинди гаебе юк иде.

— Алайса, син ник безне шундый борчуга салдың? Аны да, мине дә. Барыбызны да.

— Миңа нишләргә кирәк иде, ничек итеп аның йөзенә күренергә кирәк иде соң? Шундый мәсхәрәгә калып... Шундый антлар эчкәннән соң... Әгәр мин аны кулга алырларын белгән булсаммы?

— Нишләр идең?

— Нишләргә белер идем. Анысы аның сиңа кагылмый ла...

Идмасның йөзе үзгәреп китте. Ирен почмакларына иронияле елмаю кунды.

— Ачуланма, сиңа бер сорау бирим әле, — диде ул. — Өйләнергә йөргәнен белә торып, син һаман аның турында уйлыйсыңмы? Шушы хәлеңдә дәме?

— Уйлыйм. Берни өмет итмәсәм дә. Ул минем бердәнберем. Яшьлекнең тәүге хисләрен онытып буламыни?

Идмас көлә башлады:

— Хи-хи-хи... Син китапча сөйлисең түгелме?

— Ә бәлки, китап безнеңчә сөйлидер.

— Акыллы син, Әнисә. Молодец та инде үзең. Тик...

— Нәрсә «тик»? Әйтеп бетер.

Әнисәнең таләпчән карашыннан Идмас читкә борылды:

— Тормыш китаптагыча гына бармый бит, диюем.

## 20

Бер-ике атна узгач, Идмас Әнисәне гаҗәпкә калдырды. Күренми торды-торды да килеп керүенә:

— Мине котлый аласың, Әнисәкәй. Эшкә урнаштым. Унбишенче мәктәпкә. Математика укытачакмын, физкультура дәресләрен дә миңа йөкләделәр. Менә тагын нәрсә белдем әле, — диде. — Монда каракүл арзан икән. Татарстанга алып кайтып сатсаң, шәп файда ясыйсың дигән сүз. Яшәргә була монда, була. Ничек уйлыйсың?

— Һәркем үзе белгәнчә яши. Бернинди киңәш тә бирә алмыйм, — диде Әнисә. — Шулай итеп, син монда төпләнергә уйладыңмыни?

— Шулай килеп чыга инде. Син үзең дә монда качып килгәнсең ич.

Әнисәнең күкрәк читлегенең кайсыдыр почмагында бу кешегә ачу кебек нәрсә кузгалды. Үзенең монда килеп чыгу сәбәбен аңа кат-кат аңлатты бит инде. Тәне мәсхәрәләнгән, рухы җәрәхәтләнгән Әнисә Әниснең пакьлегенә каршы нәрсә куя ала иде соң? Идмас һаман шуны аңламыймыни? Ә үзе монда нишләп йөри ул? Бәлкем, үзе качып йөридер. Әнисә, катгый бер карарга килеп, хисләренә юл куйды.

— Син һаман мине качып килгән дип уйлыйсың, — диде ул. — Ә син үзең качып йөрмисеңме икән әле. Алименттан, дим. Зинаң бер ир бала үстерә, диделәр... Синеке түгелме?

Идмас һич тә моны көтмәгән иде. Ачуташ капкан кебек, йөзе җыерылды. Бер агарды, бер кызарды, ыкы-мыкы килде:

— Син... бигрәк инде! Нишләп качып йөрим?.. Каян килеп минеке булсын... Аны кем исбат иткән?

— Зина артыннан калмый йөрдең ич.

— Аның артыннан кем генә йөрмәде. Беләсең килсә, синең Әнисең дә аның янына баргалаган икән — юмарт икән дип кайткан. Мин соңыннан гына белдем.

Әнисә дулкынлануыннан калтыранып аны бүлдерде:

— Ялган! Ялган бу! Үтерсәң дә ышанмыйм. Зинһар, бар, кит. Күрәсем дә, ишетәсем дә килми. Ничек телең бара, ә?

— Ярар, Әнисә, гафу ит. Үзең дә инде... тиктомалдан кешегә шундый гаеп ташларга... Хуш. — Идмас, ашык-пошык киенеп, Саҗидәләрдән чыгып китте. Үзен-үзе әрләп, юл буена төкеренеп кайтты, квартира хуҗасының, нишләп болай күңелсез, диюенә салкын гына җавап биреп, бүлмәсендәге караватка барып ауды. Артыгын ычкындырды шул, артыгын ычкындырды.

Ә шулай да, нишләп соң мин Әнисәгә тартылам, дип уйлады ул. Ятимнәр йортында мин бит аңа игътибар да итмәдем. Училищеда укыганда да әллә ни өзелеп тормадым. Зинаны ничек якын күрдем, аннан башка яши дә алмам кебек иде. Тик ул бер дә юкка миннән баш тартты, араны кискен өзде дә куйды.

...Зина белән алар якыннар, хәтта бик якыннар иде. Идмас Зинаның зур соры күзләренә караган саен үзен тирән чоңгылга баткан шикелле хис итә иде. Зинаның акыллы күзләре, кыю сөйләшүе, һәрнәрсәгә төпле үз карашы булу Идмасны үзенә тарта да, куркыта да иде. Ул аны киноларга алып барды, училище кичәләрендә гел аны гына биергә чакырды. Моның Зина күңеленә хуш килүен күреп сөенде. Егетнең башкалар арасыннан аерып аңа гына шундый игътибар итүе кайсы кызга гына ошамас икән? Егете дә бит төшеп калганнардан түгел. Дөрес, башкалардан ике-өч яшькә олырак. Вакыт-вакыт бүтән кызларга да күз аткалый. Аның каравы әнә нинди юан беләкле, кояш сыман җирән чәчле. Андый чәч беркемдә юк. Кочакласа! Сөякләреңне чытырдата, эретә дә сала. Тамаклары бертуктаусыз ач, ябык, аксыл чырайлы авыл малайлары түгел инде. Ә чаңгыда, тимераякта ничек йөри. Училище командасында иң күренеклеләрнең берсе. Юкка гына Казанга республика ярышларына йөртәләрме соң? Кыскасы, Идмас белән аларның өметләре күптән инде уртак.

Чыгарылыш кичәсенә бер-ике атна кала берничә кыз Бизнәгә су коеныргa төштеләр. Озакламый егетләр дә килеп җитте. Әнә шунда инде Идмас Зинаның ап-ак тәненнән, зифа буй-сыныннан, матур түгәрәк күкрәкләреннән күзен ала алмый торды да ярып салды:

— Егетләр, кызлар, без тиздән Зина белән эшкә бергә китәбез!

Егетләр дәшмәде. Кызлар да моңа гаҗәпләнмәделәр бугай.

— Шулай буласын беләдер идек!

— Бик тә вакытлы!

— Эшкә аерым-аерым юллама алсагыз, бер-берегезне эзләп йөрер идегез әле, — диештеләр.

Тик һәркайчан уйчан, тыйнак Хәлимә генә моны ишеткәч агарынып китте. Үзе дә сизмәстән Идмаска нидер әйтмәкче булып аңа тартылды, аннары, тиз генә киенеп, беркемгә берни әйтми тулай торакка кайтып китте.

Егетләрнең:

— Аңа ни булды? Әллә авырыймы? — дигәннәренә кызлар:

— Озак коенып, хәле киткәндер, — дип калдылар.

Шул кичне Идмас, балалар йортында бергә үскән үзеннән яшьрәк берничә егетне ияртеп шәһәр паркына һава суларга дип чыккач, бер эскәмиядә ялгыз гына уйланып утырган Хәлимәне күреп алды.

— Егетләр, карагыз әле, теге Хәлимә түгелме соң ул? — диде Хәтмулла.

— Ул шул, ул. Берьялгызы нишләп утыра икән? — Идмасның күзләре очкынланып китте.

— Шәһәр малайлары килеп бәйләнмәсен тагын, — диде кайсыдыр.

— Әйе, училище кызларына бәйләнергә генә тора алар.

— Ярар, егетләр, сез кайта торыгыз, мин аның янына барыйм әле, — дип Идмас күз кысты да Хәлимә янына атлады.

Хәлимә аны күргәч тә берни дәшмәде, карашын бер ноктага төбәгән килеш утыра бирде.

— Хәлимә, ник берьялгызың монда утырасың? Инде караңгы төшкән бит, — диде Идмас.

— Утырса ни... Сиңа барыбер түгелмени?

— Түгел шул. Әнә Кулясков төркеме очраган бер егетне кыйнап йөри, кызларны да куркытып бетергәннәр, диләр.

Хәлимә һаман бер сүзен кабатлады:

— Сиңа барыбер түгелмени?

— Син нәрсә инде — һаман бер сүз.

Хәлимә җавап бирмәде.

Идмас, аны сөйләштерергә теләп:

— Син эшкә юллама кайсы тирәгә алдың? — дип сорады.

— Сиңа нәрсәгә ул?

— Соң бит, ничә ел бергә укыдык лабаса. Сорасам ярамыймыни? Чит кешеләр түгел ич!

— Чит шул менә!

— Ничек инде?

— Әйтсәм әйтим инде алайса... Күз урынында синең боз кисәкләре... Күкрәгеңдә дә йөрәк түгел — таштыр ул. — Хәлимәнең сүзләре бүленеп-бүленеп чыга иде.

— Әллә?

— Син берни күрмисең! Берни сизмисең. Ничә ел буе.

— Менә иске авыздан яңа сүз. Син миңа гашыйк түгелсеңдер бит?

— Әйтәм ич таш дип. Бозлы таш.

— Үлеш! Мин каян белим соң. Үзең дә инде. Кил бер үбим әле, ичмаса... — Идмас Хәлимәне кочакламакчы иде, кыз кинәт ике кулын да аның күкрәгенә терәде.

— Юләрләнмә! Бөтен кызлар да бер кайчы белән кыркылмаган. Кайчан язылышасыз соң? Зина белән, дим.

— Причем монда ул?

— При том! Бар, аны үбәрсең!

— Әлегә минем артыма тубал тагылмаган. Мин свободный кеше.

— Алай икән. Аның белән эшкә бергә китәбез, диден түгелме соң. Ирекле кеше, имеш.

— Ирекле шул. Ә бәлкем, мин тотармын да сиңа өйләнермен!

Хәлимә уф дип башын чайкады да торып басты. Аның күзләрендә ачу да, рәнҗү дә бар иде.

— Тотмый гына тор. Идмас, әгәр мин синең сүзләреңне Зинага әйтсәм, ә?

— Әйтмәгәең. Ул миннән беркая да китми, бик беләсең килсә. — Идмас сүзләрендә үзенә күрә горурлык яңгырады.

— Их, син! Син бушкуык, пошляк, җилбәзәк тә икәнсең әле. Ничә ел яратышып йөргән кызың турында шундый сүзләр сөйләргә оят түгелме сиңа? Мин белмәгәнмен. Зина да белмәде микәнни?

— Усал да инде үзең. — Идмас Хәлимә сүзләрен уенга борып, хихылдап алды.

— Идмас, бар, кит әле. Үземне генә калдыр, икенде күләгәсе булма.

— Ярар инде, мин бит уйнап кына әйттем.

— Уйнап кына?! Зинаң моны ишетсә, нәрсә дияр иде икән, ә?

— Каян ишетсен ул?

— Мин әйтсәм? Кеше язмышы белән шулай уйнарга ярыймыни? Зинһар, кит янымнан!

Идмас үзсүзләләнеп һаман тора бирде. Аның үз нияте бар иде.

— Караңгы бит. Кайтырга куркырсың, дим.

— Юк, мин синнән куркам. Синең өчен куркам.

— Менә күрдеңме... Минем өчен. Син миңа битараф түгел бит. Әйдә озатып куйыйм, әйдә. — Идмас кызны култыкламакчы булды. Хәлимә кулын тартып алды.

— Кагылма! Хисләр сукыр була, диләр иде. Дөрес икән.

Идмас, ниһаять, кайный башлаган хисләренә юл бирде:

— Барсана! Баш-аягың бер казан. Ялындырып торасың тагын, — дип кискен борылып, аллея буйлап караңгылыкка кереп китте.

...Икенче көнне ул кызлар бүлмәсе ишеген шакыгач, Зина сикереп торды да аның каршына килеп басты.

— Моннан соң бирелә эзең дә булмасын! — диде ул. — Оныт бирегә юлны!

— Тукта әле, Зина! Сиңа ни булды? Тиктомалдан! Нинди чебен тешләде? — Идмас аптырап калды.

Зина күзләре чоңгылыннан ярсулы очкыннар чәчри иде.

— Бүгеннән мин сине белмим. Бар, алдыңнан артың матур.

— Тукта инде, аңлатып бир, нәрсәгә шултикле ачуың чыкты, ә? — Идмасны күргән кеше аның хәзер кызганыч хәлдә калганын тиз аңлар иде.

— Син мине беләсең, Идмас. Мин ике сөйләмим. Бетте. Барысы да бетте. Сиңа ачуым гына калды. Бар, чыгып кит. Мин хәзер өстемне алыштырам. Кадалып торма, дим ич.

— Зина, безнең бит инде синең белән... — Бу Идмасның алар үзләре генә белгән нәрсәләргә ишарә ясавы иде, тик Зина каты торды:

— Безнең арада берни булмады дип бел. Ишетәсеңме? Берни дә... — Зина моны бик гади, тыныч кына шундый итеп әйтте, Идмасның тәне эсселе-суыклы булып китте. Күңеле белән ул Зинаны үзенә бәйләгән нәрсәләрнең шартлап өзелгәнен тойды, ә шулай да ышанасы килмәде.

— Әллә сиңа Хәлимә берәр нәрсә сөйләдеме? Сөйләсә, безнең араны бозарга сөйләгәндер. Ул үзе миңа гашыйк булган икән, — дип, гаепне бүтәнгә сылтарга маташты. — Ярар, ачуың басылгач бер сөйләшербез әле. Болай булмый ич инде. — Идмас ишеккә борылды.

— Була икән шул, — диде Зина. — Бу безнең соңгы сөйләшү. Егет бул, ялынма да, килеп тә йөрмә.

Идмас, ни әйтергә дә белми, башын иеп чыгып китте. Ул күрше бүлмәләрнең берсендә кемнеңдер мандолинада Салих Сәйдәшев маршын уйный башлаганын ишетеп, мыгыр-мыгыр килде.

Шулай итеп, аларның аралары өзелде. Зина очрашырга да, сөйләшергә дә теләмәде. Идмас аны ашханә яннарында, китапханә бүлмәсендә, шәһәр урамнарында көтеп алса да, Зинаның сүзе бер булды:

— Киселгән икмәк кире ябышмый! Җитәр, һаман берне тәпәмә!

Инде менә Әнисә... Ул да нәкъ Зина әйткән сүзләрне әйтте бит. Бар, кит, күрәсем дә, ишетәсем дә килми, диде. Зина белән борчагы пешмәгәч, ул, бәлкем, Әнисә белән эш барып чыкмасмы дип өметләнгән иде. Инде менә ул да... Ник килде соң әле ул монда? Ник аны эзләп тапты? Теге чакта Әнис белән бәхәс чыкканда ук Әнисә аңа мөнәсәбәтен ап-ачык белдергән иде ләбаса... Шулай итеп, Әнисәнең карашын үзгәртеп булмас микәнни? Бәлкем, булыр әле. Аның да беркеме юк ич. Кәефен җибәрде инде җибәрүен. Тора-бара, суына төшкәч, бәлкем, ипкә килер, алай артык кыланмас әле. Әнис белән мөнәсәбәтләре бөтенләйгә өзелгәнен үз теле белән әйтте ич.

## 21

Әнисә соңгы көннәрдә суырылып калды. Идмас сүзләре аның җанын телгәләде, болай да әрнегән ярасына тоз салды. Әнис тә Зина янына барып йөргән, имеш. Ярар, шулай да булсын ди. Ә син, аны яратып йөргән егет, моңа ничек карадың, ничек түздең? Нигә күз йомдың? Бөтен училище алдында ачыктан-ачык яратышып йөр-йөр дә дус кызың янына пычрак уй белән барган егетләргә күз йом, имеш. Юк, алай булмый ул. Юләр сату түгелме соң бу?

Ә Әнис? Шул арада Әнисәсен онытып, бүтәннәр белән чуала аламы? Моның беркайчан да булуы мөмкин түгел. Ул мине үлеп-үлеп ярата иде. Тик мәңге ялгыз калмас ич инде. Үзе шундый чибәр, эчкерсез, кешелекле, тырыш егеткә күз ташлаучылар аз булмас. Тора-бара мине онытыр, хисләре дә сүрелер. Бу табигый хәл. Әнисә үзе шулай тели. Тик менә Идмас әйткәнчә була аламы икән? Юктыр, юк. Минем йөрәгем алдамый. Алайса, Идмаска моның нәрсәгә кирәге булды икән соң?

Әнисәнең боегып калуын Идмасның соңгы вакытта күзгә-башка күренми йөрүеннән дип уйлап, Сәҗидә белән Низамның егеткә җен ачулары килде. Тиктомалдан кыз баланың күңелен кузгатсын да юкка чыксын, имеш. Шул да булдымы егетлек.

Сәҗидә белән Низам, юллама алып, ике атнага гына булса да дип Фирүзә дигән бик матур урындагы ял йортына киттеләр. Ялгыз калгач, Әнисәнең эче поша башлады. Уйлары белән ул торган саен үскән, укыган җирләренә кайтты. Дус кызларым хәзер кайларда йөри икән? Тормышларын ничек кордылар, ничек эшлиләр икән? Лилия бик нечкә күңелле иде. Минем югалуымны ничек кичергәндер инде. Аңа берни әйтми юкка чыгу — шушы да буламы дуслык! Ә Әнис, дип уйланды ул.

Егет исенә төшүгә, Әнисәнең йөрәге күкрәк читлегеннән чыгарга җыенгандай ярсып тибә башлый. Менә тагын ул каршыга килеп баса да, гадәтенчә, күзләренә карап елмаеп тора.

— Синең күзләрең гаҗәп матур. Болындагы күкчәчәк төсле, — дия иде ул. Ә пристаньда Казанга китәргә торганда нәрсә диде?

— Мин рәссам булсам, зур итеп синең сурәтеңне ясар идем. Чәчәк баскан болын уртасына бастырып, кояш көнләшерлек итеп ясар идем. Чәчәкләрне кояшка түгел, сиңа каратып. Менә, ичмаса, сурәт булыр иде бу, ә? Кулыңа роза тоттырып.

Әнисә ярый әле сөйгәне биргән розаны саклый алды. Туган якларын, Әнисне үлеп сагынганда ул нәни тартмадан бүләк розаны сак кына ала да исни. Иснәве була, училище бакчасындагы гөлҗимешләр, акацияләр уртасындагы урындыкка очып кайта, колагында дус кызларының шатлыклы тавышлары яңгырый башлый. Тавыш-тынсыз гына каяндыр Әнис килеп чыга, кып-кызыл зур роза чәчәге суза, карап басып тора-тора да башын иеп китеп бара. Нинди каһәрле көн аерды соң аларны... Шәфкатьсез, рәхимсез көн... Ә көннең монда ни гаебе бар? Кояшлы матур җәйге көн иде ләбаса. Кара болыт килеп кенә бозылды ул. Әнисәнең уйлары әле тегендә, әле монда сикерә, ул торып йөреп китә, тагын барып утыра. Гомер буе шулай мәсхәрәләнгән, узасы узган, тузаны тузган кыз булып калачакмыни соң инде ул? Ә алда нинди матур хыяллар, планнар бар иде. Нинди явыз бәндә аны шушы хәлгә төшерде соң?..

Уйларына бирелеп, Әнисә капка шакыганны ишетми калды. Инде тәрәзә шакый башладылар.

Кем булыр бу, дип, Әнисә тәрәзә янына килде.

Анда Идмас басып тора, капканы ач, дип кул изи иде. Әнисә чыгып капканы ачты.

— Куркытып җибәрдең, син икәнсең әле, — диде ул. — Мин берьялгызым гына. Сәҗидә апалар ялга китте бит.

— Шулаймыни? Үзем дә шулайрактыр дип уйлаган идем. Күпме килми тордым, сагынып та беткәнсеңдер, иеме? — диде Идмас, шаяру тонында. Әнисәнең дәшмәвен үзенчә юрады булса кирәк, теле белән төлке тотарга ниятләде: — Сиңа каракүл жакет тектерергә дип, районнарга чыгып кердем әле. Тиреләр сатып алдым. Сине куандырырга исәп. Туган көнеңә.

— Миңа берни дә кирәкми, Идмас. Син бар, кайт. Ялгыз хатын-кыз янына ир-ат килүне беркем хупламый монда.

— Йә инде, Әнисә. Син дә, мин дә тиле яшьләр түгел бит. Килсә, аның ни ояты бар? — Идмас кулларын сузып, Әнисәгә якын ук килде. — Без бит инде синең белән дистә еллар бергә.

Әнисә борынына тәмсез хәмер исе килеп киткәндәй булды:

— Әллә син... эчкән димме?!

— Чүт кенә... Уңышлы сәфәрне юып кына. Әнисә, Әнисә, кил әле яныма. Шундый сагындым үзеңне. Мин ялгыз бит монда. Икебез дә ялгыз.

— Юкны сөйләмә, Идмас. Бар, кайт. Эчкән кешене җенем сөйми. Кит, дим.

— Җә инде, матуркаем. Кума инде... Кыз түгел ләбаса инде. — Идмас Әнисәне биленнән кочып, үзенә тартып китерде дә үбәргә сузылды. Әнисәнең борынына хәмер исенә кушылган ачы тир исе килеп бәрелде. Ул укшый ук башлады. Бу сасы ис аңа таныш иде. Мондый тәмсез ис теге бәхетсез кичтән соң аны бик озак эзәрлекләгән иде бит. Монда да шул ис! Әллә! Әнисәнең күзләре зур булып ачылды, таштай каткан сыны калтырый башлады. Билдән түбән бар әгъзалары сулкылдап әрнергә кереште.

— Син!

Идмас, кыршаудай кулларын ычкындырып, берни аңламый кызга текәлде.

— Син!

Әнисә кинәт очынып Идмасны уңлап-суллап яңаклый башлады. Ул үзен-үзе белештерми иде.

— Син икәнсең, кабахәт! Син булгансың!

Идмас Әнисәнең кулларын тотарга маташты, иелде-бөгелде, тик соңгы чиккә җитеп ярсыган Әнисәне туктата алмады.

— Минем мәхәббәтемне, тормышымны җимерүче син булгансың, пычрак җан! Син, син, ублюдок! Югал, югал күз алдымнан! Мә сиңа, мә!

— Әнисә, Әнисә, дим, тынычлан, җә, тынычлан инде. Узган эшкә салават, диләр бит.

— Узган эш?! Оятсыз, җирбит! Ничек монда килергә иттең! Нәрсә кирәк сиңа, ә?

— Минем ниятем чын иде бит, җә инде. Бәлки, торып китәрбез дигән идем. — Идмас челт-челт итеп күзләрен йомгалады.

Әнисә, читлектәге капландай, арлы-бирле сугылды, аннары кәнәфигә сыгылып төшеп, яшь баладай сулкылдап, үксеп-үксеп елый башлады.

— Әнисә, ярар инде, тынычлан, зинһар, тынычлан... Бер утырып барын да сөйләшербез, икебез дә ятимнәр ләбаса... — Идмас Әнисә елап тынычланыр да аннан соң аны үз ягыма аударырмын дип уйлый иде.

— «Сөйләшербез!» «Торып китәрбез!» Синең белән торганчы, гүргә керүең хәерлерәк. Кит, чыгып китәсеңме, юкмы? Югыйсә мин хәзер күршеләрне чакырам.

Әнисә чыннан да сикереп торып ишеккә юнәлде. Идмас моны көтмәгән иде, Әнисәне узып, ишек тоткасына ябышты.

— Ярар, ярар, киттем. — Ул кабалана-кабалана ишекне ачты да яшеннән качкан шайтан кебек йөгерә-атлый капкага ташланды.

Шул мәлне бу якларда җәен шактый сирәк була торган хәл — калай түбәләрне яңгыратып күктән эре тамчылар коела башлады. Яңгыр көчәйгәннән-көчәйде. Ишегалдындагы бердәнбер алмагач яфраклары, калын тузан япмасыннан арынып, ямь-яшел төскә керде. Әнисә коеп яуган яңгыр астына чыгып, озак басып торды. Чәчләре, киеме, бөтен тәне чыланганын ул сизми иде. Аның күз яшьләрен яңгыр юып ташлады. Ничек кинәт башланса, яңгыр кинәт туктады да. Әнисә өйгә кереп ут кабызды да караватка барып ятты. Ул бик-бик арыган иде.

**22**

Картлар йорты матур гына бакча эченә урнашкан. Янында гына яшелчә бакчасы да бар. Теләгән кеше шунда чыгып казына, төрле-төрле чәчәкләр, укроп, суган утырта. Дәрте-дәрманы беткәннәр җылы, кояшлы көннәрдә йорт янындагы урындыкларга тезелешеп салмак кына гәп коралар, черем итәләр. Шылт иткән тавышка да уянып, капканы күзәтәләр. Картларның берсе көн саен бакчаның аргы, аулак почмагындагы урындыкка ялгыз гына сеңә дә уйларына бирелә. Шәлперәйгән иске эшләпәсен агарган кашларына тикле батырып кия, инде тонган, төсен югалткан, һәрвакыт яшьле күзләрен бер ноктага төбәп карлы-бозлы яңгырлар җилләткән таш балбал шикелле сәгатьләр буе тын гына утыра бирә. Янынннан узган кешеләр аның вакыт-вакыт кулларын болгап үзалдына ниләрдер сөйләгәненә сәерсенеп карап китәләр. Карт үпкәләрен гыжылдатып авыр сулый, көрсенә, тик беркемгә берни әйтми утыра да утыра. Арыгач, кузгала, бер аягын сөйрәп диярлек бинага юнәлә, керә. Коридорда бүлмә ишеге янында туктап тыңлап тора. Аннан бүлмәдәше Гаяз тавышы яңгырый:

— Эх, син! Адәм мәсхәрәсе! Шундый козырең була торып, нәрсә карап утырдың, тизәк тутырмасы! Йә әйләндереп җибәрермен!

Картлар йортына караучысыз, терәксез калган колмак сабагыдай карт-коры гына түгел, гомеренең күп өлешен төрмәләрдә уздырып, башын кая куярга белмәгән пенсия яшендәге сукбайлар да эләгә. Гаяз шундыйларның берсе. Андыйлар пенсия алган көннәрдә үзләренә күрә бәйрәм ясыйлар. Елгырраклары кибеткә барып килә. Хәзер анда утлы суга кытлык юк, акчаң гына булсын. Интернатка түләгәннән калган акча шул «ябалак сөте»нә тотыла. Дөрес, монда балаларым йә оныкларым килеп чыкса, күчтәнәчкә, бүләккә дип акчаларын тиенләп җыючы карт-коры да бар. Аларга мондый көннәрдә бигрәк тә авыр. Хәмер яратучыларның авызларына «шайтан төкерегe» кердеме, тавыш-гауга чыгуын көт тә тор. Монда инде алдынгылар рәтендә шул ук тәүбә капкалары ябылган Гаязлар йә кайчандыр дөнья кендеге булып йөреп, җил-давыл китереп ташлаган зур бавырлы «акыл иясләре».

Тагын «төшереп» алганнар да һаман карта сугалар икән. Күпме мөмкин инде... Ахмаклар. Эт сугарып көннәр буе йөриләр дә бер уен табалар. Карт, рәнҗеп, башын чайкап ала, борылып кире китәргә исәпли, ләкин сул аягы карыша. Бүлмәдән яңгыраган тавышлардан аның бөкрәйгән гәүдәсе тагын да сыгыла төшә. Ул кыяр-кыймас кына ишекне ача. Балта элеп куярлык тәмәке төтененә кушылган хәмер, балык, суган исе борынны ярып керә.

Карт чыдый алмый:

— Тагын бүлмәне сасыткансыз, — дип мыгырдый-мыгырдый ятагына юнәлә. Анда ачы тир исе сеңгән, кыршылып беткән күн күртка, полиэтилен пакет, ипи валчыклары, газета ертыклары аунап ята. Ул аларны Гаяз караватына илтеп ташлый.

— Бүлмәдә тартырга, эчәргә ярамый, дип күпме тәкрарлыйлар... Ә сез колагыгызга да элмисез... Бүлмәдән дуңгыз абзары ясыйсыз...

Гаяз кызгылт күзләрен акайтып, йодрыкларын йомарлый. Теле күгәненнән ычкына. Хәмер исе аңкыткан авыр сулышын картның йөзенә бәрә:

— Үлә дә белмәдең, корчаңгы! Имгә яраксыз нәстә! Мыгырдаган була тагын! Синең яшьтәшләрең теге дөньяда әллә кайчан инде миллионынчы төшен күреп ята. Анаң төчкергәндә төшеп калган мәхлук.

Карта уйнаучылар бүлмәне генә түгел, бөтен коридорны яңгыратып кешниләр:

— Миллионынчы төш, ә? Ха-ха-ха!

— Ну, әйтәсең үзең! Төчкергәндә төшеп калган. Ха-ха!

— Суң, һаман мыгырдана! Мин бит аның төне буе бүлмәне пыскытып, сөрсеп ятканына зарланмыйм. Ә ул, паршивый, һаман — «сасыткансыз»! Әле тәрәзәне ач, әле яп!

Карт бүтән эндәшми, ни генә әйтсә дә, файдасы тимәсен белә. Эшләпәсен тумбочка өстенә ыргытып, стенага борылып ята. Бу карт — Идмас Фәсхетдинов. Сиксәнгә якынлашып килгән бәхетсез карт туган якларга Төрекмәнстаннан берничә ел элек кайтып егылды. СССР таркалгач, анда Рәсәйдән килгәннәргә көн бетте. Алар берәм-берәм дә, гаиләләре белән дә квартираларын, мал-мөлкәтен әрәм-шәрәм итеп, туган илләренә кайтырга мәҗбүр булдылар. Төрекмән телен белмәгән кешеләр эштән азат ителде, төрле кыенлыклар алдында калды. Идмас, гомеренең күп өлешен шунда уздырса да, ул телне өйрәнә алмады. Гомумән, аның гуманитар фәннәрдә яшьтән үк рәте булмады. Училищеда укыганда нишләп «феодал» сүзендә «е» язылы, «фиолетовый» дигәндә «и» язылы дип, рус теле укытучысы белән чатыр-чотыр бәхәсләшә иде. Фәсхетдинов күптән инде пенсиядә, эшләми иде. Эшләгәндә әле коллективта, кешеләр арасында ялгызлык ул хәтле үзәккә үтмәде. Тик менә ялга чыккач... Янына кереп хәлен белүче дә, кибеттән ризык-мазар алып кайтып бирүче дә калмады. Яман холкы, көнчелеге, хөсетлеге аркасында гаилә кора алмады, тирә-юньдәгеләрнең дә гайрәтен кайтарып бетерде.

Көннәрдән бер көнне ул туган илдә чыпчык та үлми дигән уйга килде дә булган әйберләрен, бер бүлмәле квартирасын арзанга гына сатып, бик авырлык белән Татарстанга кайтып китте. Баштарак елларда хат алышкан, каракүл тиреләре, җиләк-җимеш сатарга булышкан әшнәләре инде картайган, аңа ярдәм итәрлекләре калмаган иде. Шулай да аз-маз акчасына, алып кайткан каракүл тиреләренә кызыгучы берәү табылды, төрле юллар белән аны картлар йортына урнаштырды. Аңа да Идмас Фәсхетдинов, бөтен акчамны алдап-йолдап алып бетерде, дип рәнҗеп йөрде.

Моннан берничә ел элек аның янына карт кына бер рус хатыны килеп киткән дип сөйлиләр. Зур, матур күзләре инде төсен җуйса да, ул хатын шактый чибәр булган, имеш. Аны алып килгән илле яшьләрендәге ир читтән генә картларның сөйләшеп бетергәнен көтеп торган, якын бармаган. Аннары теге хатынны сак кына җитәкләп, машинасына утыртып алып та киткән. Шул көннән соң Идмас берничә ай авырып яткан, сул аягы начар йөри башлаган.

Еш кына Идмас Фәсхетдинов үз язмышының кайчан, ничек, ник кителгәне турында чигәләре чыңлаганчы уйланып ята. Әтисе яңа төзелгән колхоз милкен әрәм-шәрәм итүдә бер дә юкка гаепләнеп Себердә югалу вакытыннан ук башланганмы аның кара бәхете? Әллә әнисенең Идмасны карт әбисе кулына калдырып кайгыдан бик яшьли вафатыннан соңмы? Әллә бик ашыйсы килгән бермәлне кеше базын басып тотылгачмы? Шуннан сүтелде дә сүтелде инде. «Бакыр комган базга чумган», олылардан ишетеп «ата шайтан» дип үртәгән малайларны тотып яра башлагачмы?.. Үзе дә кимен куймады. Үз тиңнәренә көче җитмәсә, аларның эне-сеңелләрен кыерсытты. Кемгә кышын тимер ялатты, кемнең изүенә бака тотып салды, мәк дип тилебәрән орлыгы ашатты. Бигрәк тә ачуын чыгаралар, гарьләндерәләр иде шул.

Яшьтән үк эшкә кулы ятып тора иде бит аның. Кешедән ким җире юк иде. Дөрес, башка малайлардан гел өстен чыгарга теләде. Шуңа сугышырга, тарткалашырга гел әзер иде. Үзеннән әйбәтрәк укыганнарны, инде соңрак яхшырак эшләгәннәрне ул бер дә яратмады. Берәрсенең уңышын күрсә, нишләп аның урынында мин түгел, мин кемнән ким дигән сорау аны гомере буе әзәрлекләде, тормышының ямен алды, җанын кыйнады, ялгышларга этәрде. Үзенә каршылардан ул астыртын гына үч алырга да өйрәнде. Ярылырга җиткән чаклары да аз булмады. Хәмер капкаларга иялəшеп китүе тагын. Әйе, аның, кем әйтмешли, балта сабы кыска иде. Ялгышларын төзәтергә теләгән чаклары да булмады түгел, булды. Әмма еш кына терсәк якын да, тешләп кенә булмый икән шул.

Ник дип ул Әнисәгә барып бәйләнде инде, йә? Үзе кебек үк ятимә Әнисәгә? Аны түгел, Әнисне сөйгәнгәме? Сөйсә соң, анда синең ни эшең бар? Ярый әле теге чакта гөнаһысын белмәделәр. Белсәләр, төрмәдән башы чыкмый иде ләбаса. Ә Әнисә күпме вакытлар үткәч аның гаебен каян, ничек белә алды икән соң? Шөкер, эш күптән узган инде... Әнистән көнләшүдән генә туган бу эш фаҗигагә әйләнә язды бит...

Аның якын, дус итеп, яратышып йөргән Зинасы бар иде. Тик ул артык горур булып чыкты. Өзде дә куйды. Хәлимә гаепле инде моңа, тагын кем булсын дип уйлады ул. Казанга сәүдә эшләре белән кайткан вакытларда Идмас сораштыргалады, балалы килеш кияүгә чыгып, матур тормыш корганын, Пенза тирәсендә бәхетле генә яшәвен ишетте. Зинасы үстергән баланың үзенеке икәнен дә белә иде, ләкин аның күңелендә ул баланы барып күрү теләге ялгыш кына да тумады. Ә Хәлимә? Ул үзенчә, тыйнак кына аны яратып йөргән икән. Сиздермәгән дә. И-и дөнья, ул хәзер кайда икән?..

Яңагыннан чакма кабызып куып чыгарганына карамастан, Идмас Әнисә янына тагын бер барып карады. Бу юлы аны Әнисә генә түгел, Низам белән Саҗидә дә якын җибәрмәде. Шайтан белсен, әллә инде Әнисә аларга барын да сөйләп биргән микән?

Шулай уйланып ята-ята, күңелсез хәлләр кылт итеп исенә төшкән саен карт сискәнеп китә. Менә тагын... Әнисә белән аралары бөтенләйгә өзелгәч, ул сәүдә эшләре белән Казанга бер кайтуында һич көтмәгәндә базарда Әнисне очратты. Аз-маз хәл-әхвәл сорашып китеп кенә барырга иде дә кана. Юк, ул Әнискә, синең Әнисәң бер төрекмәнгә кияүгә чыккан икән, дип ычкындырды. Бу ялган аңа нәрсәгә кирәк булды, Идмас моны үзе дә белми, аңламый калды. Алар да минем шикелле үк каңгырап йөрсеннәр, дип уйлагандыр инде. Их! Үз ялганы белән ул аларның бер-берсен табарга ярдәм итмәдеме икән әле...

## 23

Ул көнне Әнис базарга аяк киеме эзләп чыккан иде. Ларекларга кергәләп, сатучылар кулындагы ботинкаларны караштырып йөргәч, ул олы яшьтәге бер хатын янында тукталды. Тегенең кулында микропор аслы, матур гына сары ботинкалар күргәч, аларны әйләндереп-әйләндереп карады. Шул арада шау-гөр килгән халык арасында бакыр баш чалынып китте. Тукта, бу Идмас түгелме соң?

— Апа, мин хәзер әйләнеп киләм, яме, — дип, Әнис теге кеше артыннан китеп барды.

Әйе, бу Идмас иде. Әнисне күргәч, ул күрмәмешкә салышмакчы иде дә, карашлары очрашты. Нишләмәк кирәк, чит кеше сыман узып китеп булмый бит инде.

— Нихәл, Әнис, — диде ул, кулын сузып. — Нишләп йөреш?

Әнис артык ачылып китмәде:

— Вак-төяк мәшәкать белән йөрим шунда. Син каралып киткәнсең. Кояшта күп буласың, ахрысы.

— Туры килә шул, йә, укып буламы? Все же университетка кердең бугай...

— Укыйм. Классташларны очратканың бармы? Кемнәр кайда икән?

Идмас ихахайлап көлде:

— Тел төбеңдә Әнисә турында берәр нәрсә белмисеңме дигән сорау инде бу. Юк, белмим мин аны. Кая китеп югалгандыр. Дөрес булса, бер төрекмән егетенә кияүгә чыккан дип ишеткән идем. — Идмас үзгәреш көтеп Әнис йөзенә кадалды. Әнә чыннан да ул агарып китте.

— Төрекмән егетенә?

Идмас көтмәгәндә артыграк ычкындырганын шәйләде:

— Тәгаен каян беләсең? Каян чыккан сүздер. Әлегә хәтле яратасыңмыни соң? Йөзеңнән кан качты.

— Яратам. Таба гына алмыйм.

— Шул хәлендәдәме? Каймагы алынган килеш тәме?

— Их син... Шуны да аңламыйсыңмы? Ниндидер бер явызы аны шул хәлгә төшергәч, ул, бәлкем, Әнис минем белән булырга теләмәс дип, рухи газапланып эзен югалтырга теләгәндер. Мин шулай уйлыйм. Аның кебек чиста күңелле кешене табарга кирәк әле.

— Чиста хатын диген инде?

— Чиста кыз. Яраткан кызым.

— Төрекмән белән яшәсә дәме?

— Каян алдың соң син: төрекмән дә төрекмән? — Әнис ачуы кабарганын басарга тырышты.

— Әйттем ич инде. Шундый сүз чыккан, дип. Утсыз төтен булмый, диләрме әле.

— Синең фәлсәфә, Идмас, бер дә үзгәрми, ахрысы. Теге чакта да шулай дип мине гаепләргә йөргән идең. Тик хаклык җиңде.

Идмасның күзләре гадәтенчә ярык кына булып калды:

— Яратып йөргән кызыңнан колак кагу да җиңү буламы?

— Син сүзне борма. Минем гаепсезлегем ачыкланды. Ә менә синең Зина белән мөнәсәбәтләрең ничек?

Мондый сорауны көтмәгән Идмас читкә борылды:

— Ничек, ничек... Берничек тә түгел. Борчак пешмәде. Кемнәндер бала тапкан, диләр.

— Кемнәндер? Бала? Синнән түгелме икән?

Идмасның ачуы йөзенә чыкты. Бу сүзне аңа кемнәр генә әйтмәде инде. Ярый әле аның бәхетенә Зина, нык торып, баланы Идмаска такмады. Шуның өчен генә булса да рәхмәт үзенә. Ә бу неудачникка нәрсә дияргә, ничек авызын томаларга? Мин син түгел дияргәме әллә? Алай дисәң, ул бит минем Зина белән ничек йөргәнне белә. Араның ничек өзелгәнен генә белми. Белмәсен дә.

— Үзем ятим үскәч, ятимлек миңа яхшы таныш. Баласы минеке булса, ике дә уйлап тормый Зинага өйләнер идем.

— Соң?

— Нәрсәгәдер кәҗәләнде... Күптән инде аның үз тормышы, минем үземнеке. Ялгыз башым, тыныч колагым.

— Ә Хәлимә?

— Нинди Хәлимә? Сары пошлакмы? Аның монда ни катнашы бар?

— Сиңа мәхәббәтен күпме генә яшерергә тырышса да күрә идек бит. Сары пошлак, имеш. Хәер, син...

— Нәрсә мин? Әйтеп бетер!

— Мәхәббәт белән уйнамыйлар. Ахыргы этәч булуың ихтимал.

— Бабайлар сүзе. Сафсата...

— Бабайларны юкка гына аксакал, ягъни акыл иясе димиләрдер. Ярар, ни эш бетереп йөрисең соң әле? — Әнис Идмас кулындагы төеннән күренеп торган каракүл тиресенә игътибар итте. — Әллә тире сатасыңмы?

— Нишләп сатыйм? Сатып алам!

— Шулай күп итепме?

Идмас сатып алам дигәндә мондый сорау булыр дип уйламаган иде. Аның куллары кыбырсый башлады.

— Күп дип... Күп түгел лә... Ни... Бүрек тектерергә исәп.

Әнис аның аптырабрак җавап бирүеннән дөресен әйтмәгәнен аңлады. Идмас авыр хәлдән чыгарга теләп, үзе дә көтмәстән тәкъдим ясады:

— Әллә чәйханәгә кереп берәр йөз грамм төшереп алыйкмы? Синең кайгыны юып... Элеккеге дуслык хакына, ә?

— Без дус идекмени? Кем соң, алайса, мине төрмәгә утыртырга атлыгып йөрде?

— Мин бит ялгышып, син гаепле дип уйлаган идем. Узган эшкә салават, диләр ләбаса.

Әниснең йөрәге кысылып куйды:

— Салават! Минем урында үзең булсаң, нишләр идең икән?

— Ярар, әйдә, берәр йөз грамм кабыйк та үпкәләрне онытыйк инде. Бу дөньяда дүрт аяклы ат та абына.

— Мин эчмим. Ат абына, дисең. Син үзеңне ат рәтенә куясыңмыни?

— Усал син, Әнис. Усал.

Шул арада болар янына халык арасыннан каратутлы бер хатын килеп басты да ярым татарча:

— Булмады, Идмас, алмыйлар. Фарт килми. Карыйлар да кыйммәт дип китәләр, — дип, кулындагы тиреләргә ымлады. — Әйдәле, Чарджуйдан тагын килгәннәр анда.

Идмасның йөзе чалшаеп китте. Ул аннан-моннан саубуллашып таю ягын карады:

— Ярар, хуш... Арытты, кайтып ятыйм әле. Бергә укыганнарны очратсаң, сәлам диген. Араларында Сөләйман йөзеген табучылар бармы икән, ай-һай...

Әниснең җавабын да көтми, Идмас халык арасына кереп китте. Каратутлы хатын да аңа иярде. Әнис алар артыннан карап, уйланып калды. Димәк, болар каракүл сатып йөриләр. Тик каян алалар икән соң аны? Каракүл сарыгын бездә асрамыйлар. Урта Азия тирәсеннән микәнни? Кызык. Теге хатынның сөйләме дә сәер. Сүзләре татарча сыман, тик безнеңчә үк түгел... Кайда яши, кайда эшли икән соң бу Идмас? Үзеннән сорарга кирәк булган икән. Хәер, нәрсәгә инде ул аңарга?

## 24

Көтмәгәндә бу очрашудан соң Әнис җанын авыр хисләр янә бәләкли башлады. Азмы-күпме басыла төшкән йөрәге янә урыныннан купты. Әнисә аны ниндидер төрекмәнгә алыштырсын инде, ә? Ничек инде? Ышаныргамы, ышанмаскамы? Алар бит үлгәнче бергә булырга сүз куештылар. Беткән баш беткән дип

әллә чыннан да шундый адым ясап аттымы икән? Кайда соң ул? Кемнәр арасында йөри? Күреп сөйләшәсе иде үзен! Бер генә дә сагынмый микәнни соң ул! Әниснең Казанда, университетта укыганын белә ләбаса...

Уйлана Әнис, уйлана. Һәм һаман шул Идмасның төрекмән дигән сүзенә барып төртелә. Төрекмән... Тукта әле, теге чакта Идмас янына килеп чыккан хатын да төрекмән хатыны булмадымы икән? Теле бик сәер иде, ни татарча, ни урысча. Чарджуй дигәне нәрсә икән тагын. Бергәләп китеп тә бардылар. Хәер, ул хатын нишләп үзбәк йә казакъ, йә каракалпак булмаска тиеш? Һәрхәлдә, нәрсәдер бар монда...

Лекциядә булсынмы, университетка барышлый-кайтышлый юлдамы уйлана торгач, Әнис бер карарга килде. Менә дүртенче курсның соңгы имтиханнарын биреп бетерсен дә Әнисәне тагын да ныклап эзләргә керешәчәк ул. Аның дәүләт органнарына мөрәҗәгате барып чыкмады. Эзләтергә дип гариза язып милициягә баргач:

— Әнисә Әхмәдуллина сиңа кем була соң ул? — дип сорадылар. Ул нәрсә дисен инде, сөйгән кызым, диде.

Биек фуражкалы капитан көлемсерәп кенә:

— Тапкансың эш. Һәркем йөргән кызын эзләтә башласа, үләргә кирәк монда, — диде. — Фронтовиклар, сугыш вакытында таркалган гаиләләр эшләре дә муеннан... Так что, егетем, без бу эшкә тотына алмыйбыз. Бик яратышсагыз, табышырсыз.

Әнис бергә укыган егетләр, кызларның кайберләрен эзләп табып, алардан кат-кат сорашып карады. Нәтиҗәсе генә булмады. Аның каравы үз вакытында училищеда рус теле укыткан укытучы Нинель Чепурнова Әнискә бер киңәш бирде.

— Мин барын да беләм, Әнис, — диде ул. — Синең бер гаепсез икәнеңә дә ышанам. Сезнең шундый матур дуслыгыгызга соклана идем. Әллә күз тидеме шунда. Әнисә югалгач, аның бер туганы училищеда калган документларын, әйберләрен соратып алган иде бит. Тап син ул апаны. Ул белми калмас, диюем.

— Нинель Ивановна, таптым ла мин аны. Хат артыннан хат яздым. Белсәгез, Әнисәнең адресын миңа әйтегез әле дип...

— Шуннан?

— Җавап килмәде. — Әнис авыр көрсенеп куйды.

— Их син, егет. Җавап килмәде, имеш. Шуннан тынычланып калдыңмыни? — Укытучы тавышында шелтә төсмерләре яңгырады. — Ә ник ул апаның үзен эзләп тапмадың? Янына барып сорашырга иде.

Укытучының бу сүзләре егетнең күңелен айкады. Чыннан да! Имтиханнары бетүгә ул, җәйге айлар өчен стипендия алып, Кырынгыга, Әнисәнең Сәрия апасы янына барырга ниятләде.

## 25

Сәрияләр аны күтәреп алмадылар. «Сезгә нәрсәгә ул? Сез кем соң? Ник безне бимазалап йөрисез, киләсез, хат язып теңкәгә тиясез. Без аның кайда икәнен белмибез... аптыратмагыз» кебек сүзләр Әниснең бар өметен кисеп ташлады. Сәриянең ире Гыйбадулла исә утка керосин сипкәндәй итте.

Кызарынып-бүртенеп тыңлап торды-торды да:

— Йөрисез шунда! Җан көекләре! Әле берсе, әле берсе килә дә: «Әнисә кайда? Әнисә кайда?» — дип сорый. Тү-тү Әнисә, тү-тү! — диде. — Таба алмыйсың син аны, тәти егет. Берегезне дә күрәсе килмәгәч, эзләвегезнең нәмәгә хаҗәте бар? Ә?

— Гыйбадулла абзый, сез, әле берсе, әле берсе килә, дидегез. Тагын кем сорап йөрде соң аны?

— Һәй! — Гыйбадулла кулын селкеп өйдән үк чыгып китте.

Булмады. Бер кире килсә, гел шулай була бит. Монда да барып чыкмады. Әнис бирегә нинди өметләр баглап килгән иде. Биштәрен аркасына асып капкадан чыккач, өй каршындагы кайрылары әллә кайчан кубып, шомарып беткән юан бүрәнә өстенә барып утырды. Озак утырды. Тәрәзәдән үзенә текәлгән карашларны да күрде.

Шулай шактый бөгелеп төшеп утырганнан соң капкадан Сәрия чыкты да:

— Энем, исемеңне Әнис дидеңме әле? Әнис... Әнис... Һем. Туры килеп тора икән. Күреп торам, бик кайгырып утырасың. Буш кеше түгел, күрәмсең. Ул бит кая киткәнен беркемгә дә әйтмәскә кушты, — диде.

Әнис күңелендә тагын өмет чаткысы уянды:

— Сәрия апа, алайса, сез аның кайда яшәгәнен беләсез?

— Ай Алла, нәрсә генә дим соң инде. — Хатын тавышында икеләнү сизелде.

— Бая ирегез, әле берегез, әле берегез килә, диде. Үзегез дә аптыратып килеп йөрисез, дигән идегез. Аны сорап тагын берәр кеше килгән идемени?

— Җирән чәчле, аксыл керфекле юан гына берәү килгән ие шул. Идмас дидеме шунда, Ильяс дидеме.

Әнис тетрәнеп китте. Идмас! Очрашканда ул бит бу хакта ләм-мим берни әйтмәде. Ничек була соң инде бу? Ул да килеп йөргән икән. Менә тагын ребус. Димәк, аның да уенда нәрсәдер бар.

— Алай икән... Сез Әнисә адресын аңа әйттегезме соң?

— Юк-юк.

— Алайса, ул Әнисәнең бер төрекмәнгә кияүгә чыкканын каян белә икән?

Инде Сәрия аптырап калды:

— Син ул Идмасны каян беләсең соң?

— Бергә укыдык. Мин университетка кердем. Ул юллама алып эшкә китте. Берәр ай чамасы элек аның белән базарда очраштык.

— Нәрсә, Әнисә төрекмәнгә кияүгә чыккан дип ул әйттеме?

— Ул.

— Ул каян белгән? — Үз соравына үзе аптырап, Сәрия уйга талды. «Әнисәнең Төрекмәнстанга киткәнен каян белде икән соң ул Идмас? Әллә... Гыйбадулла ычкындырдымы икән...» — Әнис, синең Әнисә белән бергә укыганыңны белдем инде. Ник эзлисең соң син аны? Ник шулай өзгәләнәсең? Бергә укыганнар азмыни?

— Мин бик яратам аны. Ул да мине ярата иде. Кинәт кенә тотты да юк булды... Эх! Бәлкем, ул, көчләнгән булгач, минем Әнискә кирәгем калмады, дип уйлагандыр. Шуңа күзгә күренмәс булгандыр...

— ?! — Сәриянең тыны кысылды. Битләренә тимгел-тимгел таплар бәреп чыкты. — Көч... Көчләнгән... дидеңме?

— Әйе. Мине Казанга пристаньга озатканнан соң, кайтып барганда көчләгәннәр бит аны. Мине гаепләп кулга алганнар иде. Гаебем булмагач чыгардылар. Күрә дә алмый калдым, юкка чыкты.

— Әстәгъфирулла! Син, энем, ни сөйлисең, ә?

— Сез белмәдегезмени? Үзе әйтмәдемени?

— Алай... Аңлый башладым бугай. Ах бичара, бичара... Кара әле, башларым ук әйләнеп китте. Әйтәм җирле, минем кайда икәнемне беркемгә белдерә күрмә, диде. Бигрәк тә Әнис исемле егет эзләсә, диде. Син буласың икән инде, алайса... Бик яратасыңмыни соң?

Сәриянең тавышы йомшап, икеләнеп калуын чамалап, Әнис дулкынлануыннан торып ук басты.

— Бик! Без бит вәгъдәләр дә бирешкән идек. Планнар кордык. Ә чынында менә нәрсә килеп чыкты.

Әнис сүзләрендә хатын-кыз йөрәге ихласлык сизде бугай, Сәрия үзе дә көтмәстән аның җилкәсенә кулын куйды да өйгә чакырды.

— Әйдә, энем, өйгә керик әле, әйдә әле.

Әнис Сәриягә ияреп кабат капкага юнәлде. Бая гына чылбырына буылып-буылып өргән эт бу юлы тыныч кына карап калды. Кергәч, Сәрия самоварын яңартып җибәрде, башын чайкый-чайкый уйланып ипи турады, эремчек, сөт чыгарып куйды. Бакчада бәрәңге төбенә өеп йөргән Гыйбадулланы чакырып кертте. Шау-гөр килеп уйнап йөргән балаларын урамга чыгарып җибәргәч, иренә:

— Гыйбадулла, монда без белмәгән зур хикмәт бар икән. Тыңла әле, — диде. — Ә син, Әнис энем, менә Гыйбадулла абыеңа барын да сөйләп бир. Ул ир кеше, ул ничек әйтсә, шулай булыр. Йә!

Әнис Сәриягә сөйләгәннәрен кабатлады. Гыйбадулла бүлдермәде, сикереп торып йөргәләп алса да, тыңлап бетерде. Аннары хатынына:

— Әйттем бит мин сиңа! Тикмәгә түгел бу, дип. Әйттемме? Әйттем. Ә син — юк, юк! Ярамый! Бир адресын! Бир! — дип ярсый ук башлады. — Тикмәгә шулай эзләмиләрдер. Берсенә биргәч, икенчесенә ник бирмәскә!

Гыйбадулла сулыш юлына су эләккәндәй, кинәт «ык» итеп туктап, йөткерә башлады. Үзе дә сизмәстән теге чакта кызмача баштан Идмаска адрес бирүен ычкындырды. Күзләре түм-түгәрәк булды.

— Син ни сөйлисең? Мин беркемгә берни бирмәдем. Әллә... үзең?

Гыйбадулла, борылып-сарылып тормады, беткән баш беткән диган сыман, кулын селтәде:

— Ярарсана... Булды инде андый гөнаһ. Теге Идмас дигәне коньяк чыгарып күңелне йомшатты бит, каналья.

Бу кадәр яңалыкны башка сыйдырырга кирәк иде. Әнис бер шатланды, бер кайгырды. Менә, ниһаять, аның кулында Әнисә адресы. Әйе, ул Төрекмәнстанда икән шул. Болай булгач, аның кияүгә чыгуы дөрес икән. Янына барсаң йә хат салсаң, гаиләләрен бозып куюың мөмкин. Нишләргә соң? Тагын бер башваткыч. Сәрия апасы да аның кияүдәме, юкмы икәнен әйтә алмады. Үзе бу хакта берни язмагач, белмим шул, дип кенә җавап бирде. Ә шулай да Әнис күңелендә нәни генә өмет чаткысы һаман сүнмәде. Шул чаткы аны Сәриягә рәхмәтләр укый-укый Казанга йөгертте. Уйлана-уйлана, үз-үзе белән көрәшә торгач, Әнис хәл итте: ул Чарджоуга барачак. Әнисәсен... Әнисәнең үзен күреп, барын да ачыклаячак.

Ай-яй бу Казакъстан далалары! Кая карама соры киңлек. Иртәдән кичкә хәтле горизонтта рәшә уйный. Кояш үләннәрне көйдереп бетергән дә, бу бәндәләрнең тагын нәрсәсен корытыйм икән дигәндәй, күк гөмбәзендә эленеп тора. Вагонда чыдап булмаслык эссе. Почта-пассажир поезды көчкә-көчкә сөйрәлә. Һәрхәлдә, Әнискә шулай тоела. Аның башында уйлар өермәсе. Тизрәк, тизрәк Ташкентка барып җитеп, Чарджоу поездына утырырга кирәк. Чарджоу шул Чарджуй икән инде ул. Төрекмәнчә. Менә тиздән Әнис Чарджуйга барып җитәчәк тә югалган Әнисәне күрәчәк. Башта читтән генә. Ире белән булса, ялгыз гына чыккан чагын көтеп алачак. Бер көн, ике, өч көн, бер атна, бер ай көтәчәк ул. Бәлкем әле, кияүдә дә түгелдер. И-и ул чагында... Сәрия, болай булгач, мин Әнисәгә хат салыйм әле, дип калды. Яздымы икән, юкмы икән?

Поезд эсседән әлсерәгән станцияләргә килә дә бик озак тора. Әниснең төшеп йөгерәселәре килә. Помидор-кыяр, кавын-карбыз сатып торучылар рәтләре буйлап узганда да, лаваш сатучыларга акча түләгәндә дә ул җирле халыкның мондый коры җирләрдә тормыш итә алуына гаҗәпләнә. Урмансыз, елгасыз ничек яшәргә мөмкин дип уйлый.

Юлда яшеллек шактый мул үскән зур станцияләр дә очрап куя. Тиздән шундыйларның берсе Кызыл Орда була, анда поезд озак торачак. Каршыга килә торган поездны көтәчәк, диделәр. Поезд килеп туктады, пассажирлар төшеп, кирәк-ярак ала башладылар. Казакъ егетләре, кызлары аларга балык, җиләк-җимеш, кипкән кавын кебек әйберләр тәкъдим итеп шау-гөр килделәр. Менә станциягә әкрен генә Ташкент поезды да килеп керде. Юл өстеннән салган күпер аша бу якка аның пассажирлары да төшә башлады.

Төрле милләт кешеләренең төрле телләрдә сөйләшә-сөйләшә күләгәдәге урындыкларга һава суларга утырганын шактый карап торгач, туеп, Әнис үз вагоны янына китәргә дип торганда күпер аша төшеп килгән ике кызның берсе таныш кебек күренде. Мондый эсседә күзеңә әллә нәрсәләр күренер дип уйлап, ул карашын читкә ташлады. Ләкин шул секундта ук янә борылды. Теге таныш гәүдәле кыз килә-килә... Әнисәгә әйләнде. Ул кысык кына күзле үзбәк кызы белән елмаеп сөйләшә-сөйләшә якын ук килеп җитте дә һични аңламый аптырап торган Әнискә карады. Аның төпсез күкчәчәктәй күзләрендә соң дәрәҗәдә гаҗәпләнү чагылып узды. Ул да туктап калды.

— Әнис?!

— Әнисә?!

Яшьләр бер-берсе кочагына ташландылар:

— Синме бу, сөеклем!

— Мин, мин, бәгърем!

— Ә бу синме, кояшым!

— Әйе, мин! Мин! Күкчәчәгем!

Шуны гына көткәндәй якындагы куаклар арасында кошлар чутылдады, вагоннарның берсеннән тирә-якны тутырып «Сагыну» җыры яңгырый башлады. Яшьләр бер-берсен кысып кочаклаган хәлдә әле һаман басып торалар иде. Аларны хәзер ике поезд ике якка тартса да аера алмас иде.

Беренче булып Әнисә аңга килде:

— Син кая барасың, энис алмам?

— Синең янга, бәгърем. Кабул итсәң. Ә син?

— Ә мин синең янга, гүзәлем! Әнисем!

— Әнисәм!

Төрле милләт кешеләре — ирләр, хатыннар, кызлар, егетләр — кочаклашып торган егет белән кыз яныннан елмаеп уздылар.

Ярты юлдан борылып Әнис Казанга билет алды. Тимер юл станцияләре бер-бер артлы бии-бии артка шуды. Кайтыр юл булгангамы, әллә бүтән сәбәптәнме поезд ямь-яшел урманнар, сусыл үләнле болыннар аша туган якка тиз элдертте. Алда аларны — сөйләшеп, куанып, сөешеп туя алмаячак энис алмаларын — киң кочагын җәеп гүзәл Казан, мәхәббәтле, бәхетле-сәгадәтле тормыш көтә иде. Ә алларында, өстәл өстендә, әллә кайчан Әнис Әнисәгә бүләк иткән, әле дә хуш исе аңкып торган роза чәчәге ята иде.

*2005–2007*

## Якын йолдызлар

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Минем геройларым әле бик яшь. Әнвәргә июньдә, Гүзәлиягә июльдә унбиш кенә яшь тулды. Алар быел тулы булмаган урта мәктәпне, икенче төрле әйткәндә, җидееллык мәктәпне тәмамладылар. Алар укырга кергәндә әле Бөек Ватан сугышы бара иде. Сугыш дәвамында да, ул беткәч тә тормыш чиксез авыр иде. Ачлы-туклы булсалар да, Әнвәр дә, Гүзәлия дә чиста, пөхтә йөрделәр, тырышып укыдылар.

Алар замана балалары иде. Укытучылар, өлкәннәр укуның кирәклегенә туктаусыз өндәп торганга, Әнвәр дә, Гүзәлия дә, яшьтәшләре кебек үк, ничек тә белем алырга хыялланалар иде. Җидееллык мәктәпне бетергәндә Әнвәр инде кара чәчле, кара кашлы, түгәрәк ачык, көләч йөзле, ә Гүзәлия кара күзле, чем-кара чәчле, кара кашлы, ап-ак йөзле яшүсмерләр булып җитештеләр. Буйга тиз үстеләр, кыскасы, аларның алма кебек чаклары иде.

Гомерләрендә беренче мәртәбә беренче класска дәрескә килгәч, Әнвәр белән Гүзәлияне иң алдагы партага утырттылар. Һәм алар биш ел буена янәшә утырып укыдылар. Төрткәләшкән дә, бер телем ипине бүлгәләп ашаган, чәчләрен тарткан чаклары да булмады түгел. Яшел чирәм өстендә тәгәрәп-тәгәрәп уйнадылар, күрше урамнарда гына яшәгәнгә, алар башак, юа, чикләвек, җиләк җыярга да, балык тотарга да, сыер сакларга да үз эшләре белән бергә йөрделәр.

Әнвәр дә, Гүзәлия дә китап укырга бик хирыс иде. Берәрсе кулында үзләре укымаган китап күреп алдылармы — каян алдың, кайчан укып бетерәсең, миңа да биреп торасыңмы? Алар шулай үсте. Ул елларда радио-телевидение дигән нәрсәләр авылда юк иде. Мәктәпкә, клуб китапханәсенә дә яңа китаплар бик сирәк, аз кайта иде.

Алтынчы класста аларны аерым утырттылар. Бу чакта ике яшүсмер инде бер-берсенә вакыт-вакыт беренче генә күргәндәй карый башлаганнар иде.

Бермәлне укытучы Наҗия апалары биек булып үскән тамчы гөлне тәрәзә төбеннән идәнгә күчереп куярга кушкач, Әнвәрнең кулы Гүзәлия кулына тиеп китте. Тиеп китте дә... Әйтерсең лә аларны корт чакты! Тетрәндереп, калтыратып җибәрде. Көтелмәгән бу хәлдән икесе дә оялды, аптырады, тик бер-берсенә сиздермәскә тырыштылар.

* * *

Ул көннән соң шактый вакыт узды. Ләкин теге хәл исләреннән чыкмады. Яшүсмерләр генә булсалар да, алар дөнья хәлләре белән таныш иделәр. Мәхәббәт, ярату турында китаптан укып та, тормыштан күреп тә аз-маз беләләр иде. Тик менә аларның үзләренә килгәндә, Әнвәрнең тора-бара гел генә Гүзәлиянең кара кашларына, чиядәй иреннәренә карап торасы килүен ничек аңлатырга соң? Ә Гүзәлиянең Әнвәр баш түбәсендәге тыңлаусыз чәчләрен сыйпарга теләвен? Физкультура дәресләрендә, кышын чаңгы шуганда аларның һаман ничектер бергә туры килүен? Чаңгы сайлаганда Әнвәрнең яхшырагын, аслары кыршылмаганын Гүзәлиягә алып бирүен?

Алар үзләре моны яшерергә, сиздермәскә тырыштылар. Яңа хистән аларга оят иде, уңайсыз иде. Бер-берсенә күз төшкәндә һич көтмәгәндә кызарып китүләр, карамаска дип үз-үзеңне тыярга карар итеп тә, карыйсы килүләр... Салкын кыш көне иреннәр күгәреп чыкканчы туңсаң да сер бирмәскә тырышулар... Укуыңда гел алдынгы булырга омтылыш.

Шушы хисләр чаңгы ярышларында Әнвәргә беренчелекне алырга, җәмәгать эшләрендә Гүзәлиягә көч-куәт бирде. Минем геройларым ялгызак әби-бабайларга су китерергә, бакча казырга, бәрәңге төбен өяргә, бәрәңге алырга, утын кисәргә булыштылар.

Алтынчы класста укыганда Әнвәр авыл малайларын шаккатырды. Ул дуслары белән кырга башак җыярга чыккан иде. Җыю дип әйтү, бәлкем, дөрескә дә туры килми торгандыр, чөнки урганнан соң анда-санда калган башак эзләп кырны кат-кат таптап бетергәч, анда нәрсә генә кала иде соң? Өстәвенә әле Полевой кушаматын йөртүче гаять усал, кешелексез Сәмит балаларны атка атланып куып йөри, тотса, җыйган бер-ике уч башак салынган капчыгыңны алып китә иде. Аннары инде баланың әти-әнисен колхоз идарәсенә чакыртып тетмәсен тетәләр, хәтта штраф салалар иде.

Пычрак телле Сәмит кайдадыр аяк бармакларын өшетеп, фронттан котылып калган иде. Халыкның терлеген, казларын, басудан тоттым дип, куып алып кайтып, үз абзарына ябып куя да штраф салдырта. Ачтан интегүче терлек, кош-корт тавышы аның колагында музыка булып яңгырый диярсең. Халык штраф түләп, аңа рәте булганы — үз авызыннан өзеп йомыркадырмы, каймактырмы, булмаганы елый-елый сәгатьләр буе ялынып терлек-туарын алып кайта иде.

Менә шул Сәмит сүгенә-сүгенә кырда башак эзләп йөргән малайлар өстенә килеп чыкты. Малайлар төрле якка сибелделәр, Мансур гына нишләптер өлгерә алмый калды. Сәмит атын аның өстенә үк куалады

да, чыбыркы белән берничә мәртәбә тамызып та алды. Мансур үрсәләнеп елый башлады. Аннары Сәмит Әнвәрне куып җитте.

Менә шунда инде малайларны шаккатырган хәл булды. Полевой аты Әнвәр өстенә менәм дигәндә генә, ул җирдә яткан таякны алды да атка кизәнде. Ат читкә тайпылды. Моны һич тә көтмәгән Полевой әллә нинди оятсыз сүзләр әйтеп, ияреннән сикереп төшеп, Әнвәргә кизәнде.

— Ах син, эттән туган нәрсә! Син кем малае?! Мин синең хәзер тешләреңне коям, бетле маңка...

— Сугып кына кара! Малайлар, килегез монда! Ник кыйный ул безне? — дип кычкырды Әнвәр.

Читкә тайпылган малайлар, җирдән кантарлар алып, болар янына килеп бастылар.

— Мансурның беләген, аркасын карагыз әле. Күлмәге ертылган, тәне кара янып бүртеп чыккан бит. Ник кыйныйсың син безне? Безнең нинди гаебебез бар, ә?

— Рөхсәт юк дип күпме әйтергә була сезгә! Әтиләрегезне төрмәдә черетәсегез киләме?! Болай булгач, рәхимлек көтмәгез б...к кибәннәре! — Сәмит һаман ярсый иде.

— Безнең әтиләр сугышта үлеп калды. Ә син безне кыйнап йөрисең! Батыр, имеш. Хакың юк! — Малайлар Әнвәрнең явызга шулай кинәт каршылык күрсәтүеннән батыраеп киттеләр.

— Бирермен мин сезгә хак! Социальтик милеккә кул сузасызмы әле?..

— Социальтик түгел, социалистик... Ә монда кайда ул милек?

— Башак колхозныкы! Көлтәдәме ул, җирдәме! Кара син боларны! Даваегыз капчыкларыгызны!

— Әйдәгез, малайлар, бирик капчыкларны, — диде Әнвәр.— Башаклар да аларның төбендә генә.

Малайлар аптырап калдылар.

— Бирик, бирик. Алып китсен. Ә без директор Җәлил абый янына барыйк. Сөйләп бирик... Моның ияр астына кыстырган капчыгына һәрвакыт ашлык салып кайтканын да әйтербез. Мансур да барсын. Әйдәгез.

— Телеңә салынып торма. Куркыттыгыз... бик... Җәлил абый, имеш. Тагын бер күрсәм, карагыз аны. — Сәмит йомшый төште. — Алыгыз капчыкларыгызны. Матрите!

Сәмит сүгенә-сүгенә атына атланып китеп барды. Моннан соң малайлар гына түгел, өлкәннәр дә Әнвәрне ихтирам итә башладылар.

Җиденче класска күчкәч авыл картларының бер бик җаваплы үтенечен үтәп тә, Әнвәр рәхмәтле булды. Көз иде. Картлар ураза гаетенә әзерләнеп йөргәндә, районнан уздырмаска дигән әмер килде. Иртәгә бәйрәм дигән кичне Әнвәрне дини эшләрдә башлап йөрүче Гарифулла бабай урамга чакырды.

— Улым, син ышанычлы бала. Сиңа йомыш бар. Үтәрсеңме икән? — диде карт.

— Үтим, Гарифулла бабай. — Олыларның үзенә шулай ышаныч белдерүеннән горурланып, Әнвәр теләсә нинди йомышны үтәргә әзер иде.

— Иртәгә ураза бәйрәме. Безгә бәйрәм намазын берәр йортта укуны тыйдылар. Без аны зират янындагы тыкрыкта укырга ниятләдек. Мәрхүмнәргә дога кылырга тыймыйлар бит әле. Картларга, ир-атка шул тыкрыктагы чирәмлеккә җыелырга әйтеп чыгасы иде. Улым, эшләрсеңме шуны?

— Хәзер үкме?

— Хәзер үк.

— Кемнәргә әйтергә?

Гарифулла бабай намаз картларының исемнәрен атады. Аннары теләгән һәр кеше килә ала, тик шау-шусыз гына йөрсеннәр, диде.

Бәйрәм иртәсендә зират янындагы аулак тыкрыкта читән ышыгына җыелган ир-ат намаз укыды, мәрхүмнәр рухына дога кылды. Гарифулла бабай җыелган халыкка, колхоз эшенә соңга кала күрмәгез, дип тә өстәп куйды. Намаздан таралганда ул Әнвәргә зур рәхмәт әйтеп, бәхет-сәгадәт теләде. Әнисе аны, энеләрен бик сирәк эләгә торган нигъмәт — майлап пешерелгән коймак белән сыйлады.

* * *

Чулман җәелеп, болыннарны баскан су кире китеп, аяк асты лычкылдап торган көннәрдә малайлар, кызлар бергәләшеп болынга юа җыярга йөрделәр. Көне-төне күзгә күренеп үсә торган юа күп, инде шактый күтәрелгән, тәмле, сусыл иде. Әнвәр үз капчыгын шактый тиз тутырды. Аның күзе һаман Гүзәлия ягында булды. Әнә ул иптәшләреннән аерылып тәбәнәк таллар ышыгындагы кечкенә аланга кереп бара, иелә-иелә юа учмаларын капчыгына тутыра. Капчыгы зур, әле буш урыны да шактый иде. Булышыйм әле үзенә, дип уйлады Әнвәр. Ул зур гына юа учмасы җыйды да Гүзәлия янына атлады.

— Гүзәлия, мин менә сиңа юа алып килдем.

Гүзәлия сискәнеп китте, болай да алсуланган битләренә куе кызыллык йөгерде. Озын, кирегә кайтарылып торган керфекләрен җемелдәтеп, Әнвәргә күтәрелеп карады. Йа Хода, бу сөйкемле караш нәрсә генә аңлатмый иде!

— Рәхмәт, — диде ул. — Үз капчыгың тулган да икән инде. Бик авыр түгелме соң?

Бу урынсыз соравыннан үзе дә уңайсызланып, тагын да кызара төште.

— Һи-и, бумы? Мин икебезнекен дә күтәреп кайтырмын, яме. Мә, бу учманы ал әле.

Әнвәр учмасын Гүзәлиягә сузды. Сузды да, аны капчыгына салгач, кызның кулларын үз кулына алды.

Бу таллыкта сандугачларның көне-төне чутылдап, армый-талмый сайраган чагы иде. Ямь-яшел сусыл үләннәр арасында барча җан иясе яз килгәнгә шатланган гүзәл вакыт иде бу. Яз үзе дә барча вак-төяк борчуларны оныттырып, җан ияләренә сирәк кенә килә торган ләззәт бирим, яшәргә омтылыш тудырыйм, шатландырыйм дип килгән иде.

Әнвәр бик күп вакытлар кыюлык җыеп йөргәч, Гүзәлиянең кулларын тотарга тәүге мәртәбә батырчылык иткән көн иде бу. Ярабби! Алты ел буена бергә укып, ничә ел бер парта артында утырып, ул бу кулларны күпме генә тотмады, кысмады, бәреп җибәрмәде, хәтта каермады. Әйе, анысы да булды. Кем бала булмаган да, кем тарткалашмый үскән! Бу бит шул син мең мәртәбә тоткан куллар иде. Юк, түгел шул! Бу синең йөрәгеңә ниндидер илаһи көч агымы бирә торган, сине җир, күк, бөтен галәм белән берекterә торган яңа сихри куллар иде! Ике җанны, ике йөрәкне бергә сихри тасмалар белән бәйли торган, тетрәндерә торган, бер шашынып көләсе, һичнинди сәбәпсез кинәт елыйсыны китерә торган, шагыйрьләр теле белән дә аңлатып бетерә алмаслык бөек ләззәт чишмәсе иде.

Әнвәр Гүзәлиянең кулларын үз кулына алды да... дер-дер килә башлады. Һич көтмәгәндә үзенең шушы хәленнән оялып, коелып төште, кызның кулларын җибәрергә теләде. Тик көченнән килмәде. Калтыраган кулларны әкиятләрдәге кебек сихри көч беректергән һәм аларны аеру мөмкин түгел иде. Бармаклардан бармакларга утлы агым үтүен алар икесе дә сизде, ул агым чәч төпләрен, аяк табаннарын чымырдатып, әйтеп бетерә алмаслык рәхәт дулкынга күмде. Аларга бик-бик рәхәт тә, бик-бик оят та иде. Әнвәр, ниһаять, телен әйләндерерлек хәл җыйды. Чиксез дулкынланудан өзек-өзек итеп:

— Гүзә-ли-я... — дип пышылдады.

Якында гына тирә-якны яңгыратып тургай сайрый башлады.

Гүзәлия, кинәт талпынып, Әнвәрнең күкрәгенә капланды, йөзен яшерде дә, кайнар сулышын бүлә-бүлә:

— Әнвәр... Әнвәр... Их, менә хәзер минем канатларым булса иде. Тургай шикелле мин дә күккә очар идем, — диде.

— Мин дә, бердәнберем. Минем дә күңел гел генә югарыга талпына.

Их, Әнвәр, Әнвәр! Бу мизгелдә сиңа бүтән сүзләр дә табасы иде. Тәүге саф мәхәббәт ләззәтеннән сайрар кошка әверелгән яшь җанны кочып, назларга, гүзәленең колак йомшагын авызына кабып:

— Мин сине яратам! Бик яратам! Бәгърем, матурым, җаным! — дияргә иде... Юк шул, әйтмәде.

Ходай бүләк иткән илаһи көчтән, нәкъ үзе шикелле үк илаһи гүзәл хистән изрәгән үсмер сөйгән кызына андый сүзләр таба алмады.

Бу саф, тәүге мәхәббәтле ике яшь җанның бер-берсенә үрелгән дөньяда иң ләззәтле, әйтеп бетерә алмаслык бәхетле гомер таңының гүзәл мизгеле иде.

* * *

Кешеләрнең ачлы-туклы яшәвенә, өс-башы ахыр чиккә җитеп тетелеп төшүенә карамастан, тормыш дәвам итте. Сугыштан гарипләнеп, сәламәтлеген югалтып кайткан ир-ат, сөеклеләрен сагынып көтеп ала алмаган хатын-кыз, билен бишкә бөгеп, колхоз кырларында, урман-болыннарда ат урынына хезмәт итте. Мәчетләрнең манарасын кисеп ясалган салкын клубларда кызыл бәйрәмнәргә җыелды. Кулларына өрә-өрә бөек юлбашчы Сталин җитәкчелегендә политбюро әгъзаларын җыелышның почетлы президиумына сайлады. Алар арасында ирләре сугыш кырында ятып калган Миңлебанат һәм Зәйнәп апалар — Гүзәлия белән Әнвәрнең әниләре дә бар иде.

* * *

Җиденче класста укыганда укытучы Сөембикә апалары «Мин кем булырга телим» дигән инша язарга кушты. Әнвәр берни дә язмый озак уйланып утырды. Инде дәрес бетәргә дә күп калмады. Сөембикә апасы карап-карап торды да, гаҗәпләнеп, Әнвәргә:

— Әнвәр, син ник язмыйсың? Тиздән звонок була бит, — диде.

— Ә мин кем буласымны ачык кына белмим бит әле, — диде Әнвәр. — Минем колхоз рәисе дә, зоотехник та, Нури абзый кебек страхование агенты да буласым килми.

— Укытучы, инженер һөнәре дә кызыксындырмыймыни?

— Малайларның, кызларның күбесе, укытучы булырга телим, дип язадыр инде. Бөтенебез укытучы булса, нәрсә була инде ул. Ә инженер һөнәрен без белмибез ич. Кем ул? Нәрсә эшли?

— Башка һөнәрләр дә бетмәгән. Әйтик, диңгезче, табиб?

— Мин әле генә «Фән юлында газапланган геройлар» дигән китап укып бетердем. Анда галимнәр Джордано Бруно, Галилео Галилей, Коперник, Визалий турында язылган. Менә алар кебек галим булсаң иде, яңа ачышлар ясарга... Яисә «Батырлар китабы»нда язылган Советлар Союзы Геройлары Әгъзам Вәлиев, Ибраһим Газизуллин шикелле очучы!

— Моның өчен укырга кирәк, Әнвәр. Күп укырга.

— Җидене тәмамлагач, авылда кайда укыйсың инде. Әнә бит бездән алда бетергәннәр колхоз эшендә көне-төне эшләп...

— Ярар, ярар, бик тирәнгә төшмә әле син... Дәресләр беткәч, укытучылар бүлмәсенә кер әле. Сүзне шунда дәвам итәрбез, яме, — диде укытучы апасы.

Әнвәр керде. Бүлмәдә Сөембикә апасыннан кала башка укытучылар да, мәктәп директоры Җәлил абыйсы да бар иде. Әнвәр килеп кергәч, алар тынып калдылар.

Җәлил абыйсы:

— Утыр әле, утыр, егет, — дип, аңа озынча өстәл янында урын күрсәтте. Үзе, протезлы аягын җайлап сузып, аның каршына килеп утырды.

— Менә Сөембикә апаң миңа синең инша язмавың сәбәбен сөйләде. Димәк, сиңа авыл тормышы ошамый инде? — диде ул.

— Ошамый шул, Җәлил абый. Аның нәрсәсе ошасын инде. Безнең күрше Мәсгут абый Билаловны гына карагыз. Мәктәпне гел бишлегә бетерде. Ә хәзер кем? Сукачы. Чуаш аты. Кап-кара тузанда... Өс-башы ямалып беткән. Көне-төне хезмәттә. Үзе һаман ач. Андыйлар әзме?

— Вакыты шундый бит аның, энем. Дөньяны утсыз төтен баскан чак.

— Күп кеше шулай яши бит. — Сөембикә дә сүзгә кушылды.

— Яши шул. Ә менә шәһәрдә тормыш икенче, яхшырак, диләр.

— Кунакка кайткан авылдашлар тормышны анда да баллы күлдә йөзү түгел, диләр ич.

— Ул гел шулай калыр микәнни? Аны үзгәртәсе иде. Тик ничек итеп? Мин белмим.

Директор соргылт чәчләрен сыпырып куйды:

— Мин беләм. Син укырга, югары белем алырга тиеш, Әнвәр. Институтмы, университетмы бетерергә. Ә аныңчы урта белем алу кирәк. Казанда училищелар, техникумнар күп. Ә моның өчен син җидееллык мәктәпне бишлегә генә тәмамларга бөтен көчеңне бирергә тиеш. Синнән була ул. Менә укытучы абыйларың, апаларыңның уе шундый. Дөрес, әниең риза булса. — Аннары Җәлил абыйсы шактый озак сүзсез торганнан соң: — Ә колхоз турындагы сүзләреңне син моннан соң беркемгә дә сөйләмә, яме, Әнвәр, — диде. — Үзеңә дә, әниеңә дә тынычрак булыр, район вәкиле Әлимова колагына керә күрмәсен. Килештекме? Бер аңларсың әле. Хәзергә оныт. Мин дә ишетмәдем. Укытучы абый-апаларың да. Укуыңны бел.

— Ярар, Җәлил абый.

— Ә сез, Сөембикә, инша язмады дип, аңа икеле куя күрмәгез. Язар ул, язар.

— Ярар, Җәлил абый. Сөембикә апа, мин иртәгә үк аны китереп бирермен. Язам мин аны.

— Кем буласыңны әйтепме?

— Әйе. Кеше буласым килә дип. Хушыгыз, мин кайтыйм әле. Утын ярасым да, абзар чистартасым да бар.

Әнвәр сүзендә торды, икенче көнне үк Сөембикә апасына төнлә сукыр лампа яктысында язган иншасын китереп бирде.

Ул иншасын «Очучы буласым килә» дип атаган, ә анда болайрак язылган иде: *«Кечкенә чакта мин таган атынырга ярата идем. Бөтен дөньяны онытып, чөелеп-чөелеп, чумып-чумып озак-озак атына идем. Таганнан төшкәч, чират көткән миннән зуррак малайлар кайчак «әйләндереп» тә җибәрәләр иде. Алар суккан урынны кул белән ышкып, яңадан чиратка баса идем. Аның каравы чаңгы шуганда чират юк иде. Текә тауның башына ук менеп баскач, аска карыйсың да куркыныч булып китә. Тик ул башта гына шулай. Менә син аяк астыннан шуып төшеп китәргә генә торган чаңгы каешларын аягыңа киясең дә иелебрәк аска томырыласың. Төшкән саен тизлек арта, колакларда җил сызгыра. Очып барасыңмыни, шундый рәхәт! Күңел белән менә шулай йолдызларга тикле очып менәсе иде!*

*Анда менсәң, Җир йөзендә мең төрле эш белән дөнья куып йөргән кешеләргә: «Әй, кешеләр! Тормыш мәшәкатьләреннән котылсагыз иде! Кеше бит бер генә мәртәбә яши. Мин сезгә матур тормыш телим!» — дип кычкырыр идем. Әллә миңа очучы булырга микән? Тик ничек итеп? Авыл малаена кая инде ул.*

*Төнлә мин уйланып ятам-ятам да торып тәрәзә янына киләм. Яртылаш бозланган тәрәзәдән күзем меңләгән йолдызларга төшә. Күңел җилкенә, минә тагын теге хис уяна — йолдызларга менәсем килә. Аларда әллә сихри көч бармы икән? Ул кадәр үзләренә тартмаслар иде. Йолдызларда кешеләр яшәсә, алар безнең турыда нәрсә уйлый икән? Хыялымнан энеләремнең йокы аралаш нидер әйтеп куюлары йә әнинең:*

*— Ят инде, улым, ят. Йокламыйча тагын уйланып торасың, — дигән сүзләре айнытып җибәрә. Әллә ул да уйланып ятамы икән? — Мәктәпкә энеләреңне ашатып китәрсең, — ди ул. — Мине тагын болынга печәнгә җибәрәләр.*

*...Төн. Бозлы тәрәзәгә саран гына ай нуры төшә».*

Аннары Әнвәр, фикер сөрешен борып, халыкны сугыш китергән афәтләрдән азат итәргә теләвен, бөтен кешенең йолдызлар кебек җемелдәп торуын күрергә теләвен язган иде. Сөембикә апасы аның иншасын укыгач, бик озак уйланып утырды.

* * *

Шул елны җәен яшьләрне тагын да якынайткан бер вакыйга булды. Һич көтмәгәндә төньяктан кечкенә генә кара болыт килеп чыкты да тау өстеннән уйсулыкта урнашкан авыл өстенә үрмәләде. Урамнарда пәри туе котырынды. Беренче тамчылар тузанлы юлларга сибәләргә керешкәндә, тау ягыннан шомлы тавыш ишетелә башлады. Күп тә үтмәде, калкулыкны яргалап бетергән ерганаклардан шаулап авыл өстенә пычрак су агымы ыргылды. Көтмәгән бәла иде бу.

Вакыт-вакыт бик көчле яңгыр озак яуганда яисә көннәр буена күк йөзе еламсырап торганда мондый хәлләр элек тә булгалап тора иде. Андый чакта авыл халкы тиз генә кызыл балчыкка туенган яңгыр суын әллә кайчан казылган зур гына күлгә юнәлтә иде. Инде күл дә тулып ташыган чакта суны Актай елгасына агызырга тирән канау да казып куелган иде. Тик менә хәзер үз вакытында карап, күзәтеп, төзәтеп торучы ир-ат булмаганга, аның ярлары ишелеп, бик саеккан, урыны белән бөтенләй күмелеп беткән иде. Шуңа күрә күл тулып ташыганда су белән актарылып, агып килгән кызыл балчык бәрәңге бакчаларын басып китә, ә аннары кояш астында ул балчык таш булып ката иде. Моннан соң анда нинди бәрәңге үссен инде? Ә бәрәңге бит авыл халкының төп ризыгы иде. Шуңа күрә көчле яңгыр килсә, авыл халкы, ышыкланып тормыйча, тизрәк көрәк-сәнәк алып урамга ашыга, шаулап агып төшкән суны күлгә, бакчалардан читкә борырга тырыша иде.

Бу юлы яңгыр көтмәгәндә килде. Ерганаклар ярларын ашап, балчыкка туенып, су авылга ыргылды. Күл күзгә күренеп тула башлады. Ул ташыса, су инде бакчаларга үтеп, аларны балчык басасы көн кебек ачык иде. Хәвефтән курыккан хатын-кыз урамга йөгерде, коеп яуган яңгырга да карамыйча, иске канау янына ташланды.

Яңгыр ява башлаганда Әнвәр яшьтәш дуслары Фәрит, Газизҗан, Әмир, Фирдүсләр белән Актайның комлы яры буенда балык каптырып утыра иде. Хәлнең мөшкеллеген алар бик тиз аңлады.

— Малайлар, пычрак су бакчаларга тулганчы, әйдәгез, тизрәк иске канауны чистартыйк, суны елгага борыйк! Югыйсә бакчалар бетә, — диде Әнвәр.

— Ай-яй, ишелеп беткән канауны ничек алай тиз генә казып өлгерәсең, — диде кайсыдыр.

— Әйдәгез, йөгерик, кем өйдә, шуларга әйтегез, ярдәмгә чыксыннар. Ә без көрәкләр алып килик.

Әнвәргә ияреп малайлар урамга ташландылар.

Малайлар килеп җиткәндә, колхоз эшеннән бушап торган хатын-кыз, карт-коры кабалана-кабалана канауны чистартырга керешкән иде. Яңгыр чиләкләп орса да, беркем дә ышыкка качарга теләмәде. Кешеләрнең өс-башы лычма су булды. Су аркаларга үтеп керде, аяк киемнәренә кереп тулды. Хатын-кызлар, малайлар сулу алырга да туктамады, күл тулып ташый башласа, эш харап иде.

— Сай була түгелме соң бу, файдасы тияр микән? — диде бер хатын.

— Ага гына башласын, су үз юлын таба ул, — диде Әнвәрләр күршесе Галимҗан бабай.

Ул арада ярдәмгә елга аръягыннан да кешеләр килеп җитте. Эш тагын да көчәеп китте.

— Әнекәем, карагыз әле, ерганактан нинди дулкын килеп чыкты! — дип кычкырып җибәрде Рәисә исемле кыз. — Гүзәлия, дим, кит читкәрәк, кит!

Гүзәлия исемен ишеткәч, Әнвәр аның да монда икәнлеген аңлады, тик күтәрелеп карарга да вакыты юк иде. Авыш кыр өстенә койган яңгыр суы, ерганаклар буйлап тагын да көчәйгән дулкын булып, кысан ярларга сыймыйча түбәнгә ташый иде.

Көрәкләр чыкы-чыкы бер-берсенә бәрелде, сулыш алу авырайды, үпкәләрдән чыккан кайнар һава тамакларны пешерде. Күл тулды, пычрак су ташый башлады, аның бакчаларны басасы инде ап-ачык иде.

— Малайлар, әйдәгез, күл суын да канауга ерып җибәреп карыйк әле, — диде Фирдүс.

Берничә малай күлнең сөзәк ярын казырга керештеләр. Аларга олылар да йөгереп ярдәмгә килде. Менә, ниһаять, су күлдән дә канауга үрмәли башлады. Малайлар, кызлар канауның ишелгән урыннарын актара бардылар. Күлдән шаулап агып чыккан су, канау кырыйларын ашап, елгага таба ага башлады. Ташкын суы елгага бәреп чыккач, барысы да иркен сулап куйдылар.

Кызгылт су агымы көчәйгәннән-көчәйде, тик ул хәзер инде куркыныч түгел иде. Су кырыйдагы бәрәңге бакчаларына үтеп керде, буразна араларында ялтырады, ләкин аның зарары күп булмаячак, чөнки төп агым күлгә, аннан инде канаудан елгага юл тотты.

Яңгыр ничек кинәт башланса, шулай кинәт туктап та калды. Күк йөзе болыттан арынып, кояш та килеп чыкты. Уйсу урыннардагы кызгылт күлдәвекләрдә кояш нурлары ялтырый башлады.

— Бу яңгыр безне чистый җен кыяфәтенә кертте, — диде Газизҗан.

Кешеләр бер-берсенә карашып көлешә башладылар. Барысының да өс-башлары, бит-куллары балчыкка буялып, пычранып беткән иде. Шунда Әмир Әнвәргә читкә карарга ымлады. Әнвәр борылып карагач, алар янына Гүзәлиянең әнисе килүен күрде.

— Әнвәр, рәхмәт, улым. Сиңа да, барыгызга да рәхмәт яусын, — диде ул.

Гүзәлияләрнең бәрәңге бакчасы нәкъ күл кырыенда иде. Шунда җор телле Галимҗан бабай кыстырып куйды:

— Кияү диген инде син аңа, Миңлебанат сеңел. Кияү диген.

Ана сүзен кыска тотты:

— Син аларга никах укымагансыңдыр ич, Галимҗан абзый? Язмышларында язылган булса, кияү дә булыр, Аллаһы боерса. Пәри кияүләмәбез. Ходайдан тәүфыйк сорыйк. Бәхетләренә кырау гына тимәсен.

И Хода, изге күңелле ананың теләге кабул гына булса!

* * *

Әнвәр белән Гүзәлия кичләрен боргаланып аккан Актайның сөзәк ярында яфраклары суга ук тиеп үскән юан, биек өянке янына килеп утыра башладылар. Актайның сап-сары комы өстеннән тыныч кына аккан сай суны чуарлап җылы җил исеп куя. Тирәнрәк урыннарда маймычлар мыж килә, нәни култыкларда су бөтерелә-бөтерелә ага. Каяндыр агып килеп эләккән яфраклар, үләннәр тын гына, туган якларыннан аерылырга теләмәгәндәй, һаман бөтереләләр. Җил агым суга алып чыкса гына алар каядыр билгесез еракка сәяхәтләрен дәвам итәргә китеп баралар.

Әнвәрдән алданрак килгән чакларында Гүзәлия суга, күккә карап уйларга бирелә. Менә безгә чаклы да шушы мәңгелек җирдә, мәңгелек күк астында миллионнарча кешеләр яшәгән дип уйлый ул. Һәркайсы каядыр омтылган, бәхетле булырга хыялланган. Ә кыз баланың бәхете нәрсә икән соң ул? Мул тормышмы? Бәлки. Аны ничек мул итәсе соң? Әнә бит авыл халкы ничек интегә. Колхозда көне-төне ат шикелле эшли, ә тамак туйдырудан ары уза алмый. Фронттан яраланып, эштән чыгып кайткан ир-ат та көннекен-көнгә ялгый алмый азаплана. Салымнар баса. Ач-ялангач кеше бәхетле була аламы?

Бәхет, бәлкем, мәхәббәттер. Ни өчен Әнвәр янында чакта аңа рәхәт була? Әгәр Әнвәр булмаса? Бу уен Гүзәлия читкә куа. Әле дә Әнвәре бар аның.

Кешегә мәхәббәт этәргеч буладыр. Шулайдыр. Әнә бит кешеләр иккән кырлар, алар салган калалар, алар язган китаплар. Барысы да безгә кадәр яшәгән кешеләр мирасы. Мәхәббәт булмаса, кешеләр боларны эшли алырлар идеме? Менә мин Әнвәрне өзелеп яратам. Ул да мине ярата. Ә без кешеләргә нәрсә калдыра алабыз? Мәхәббәт тарихымы? Игелекле эшләр калдыра алырбызмы?

Гүзәлия үзен биләгән бу уйларны Әнвәргә дә сөйли. Әнвәр бераз тын гына уйлап утыра. Аннары:

— Калдырырбыз, кара күзем. Калдырырбыз! — ди. — Чын мәхәббәт беркайчан да югалмый дип уйлыйм мин. Мәхәббәт дөньяны матурлый торган бердәнбер нәрсә.

— Без укыган Нәвои поэмасында Фәрһад белән Ширин мәхәббәте фаҗигале беткән. Без дә шулай булмабызмы икән, ә?

— Һәй, шушы юкка шикләнүләрең... Безгә кем аркылы төшсен. Ханнар, солтаннар заманы түгел ич. Тик... — Әнвәр әйтергәме-юкмы дип туктап кала.

— Нәрсә «тик»? Әйт, әйт.

— Тик... Рәшитнең күзе синдә генә... Маймыл!

— И җүләр! Аның күзен томалап куя алмыйм ич инде мин. Карамагае.

— Карамасын. Әйт үзенә.

— Үзең әйт.

— Гүзәлия!

— Әү дим ич инде.

— Беләсеңме... ни...
— Белмим әле.
— Тагын көләсең... Беләсеңме, минем сине кытыклыйсым килә.
— Уф, көлдереп үтерәсең бит. Юк инде, кытыкламый гына тор. Бигрәк тагын...
— Мин бит кабыргаңа бер генә кат менә шулай орынып кына алырмын дигән идем.
— Менә орындың ич инде. Булды. — Гүзәлия читкәрәк шуыша.
— Һәй, куркак куян. Карале, Гүзәлия, бер-берсен яратышып өйләнешкән кешеләр гел кытыклашып кына торалардыр, әйеме?
— Хыялый. Алайса, парлы кешеләр гел көлеп кенә йөрер идеме?
— Йөрсеннәр шул. Барысы да. Тормыш нинди җиңел булыр иде.
— И-и, тормышны аны көлеп кенә җиңеләйтеп булса!
— Әйдә, без сүз бирешик, Гүзәлия. Кайда гына яшәсәк тә, кем генә булсак та, гел кешеләргә ярдәмчел булыйк. Менә шушы матур көнебез хакына. — Әнвәрнең тавышы калтырап чыкты.
— Син, Әнвәр, хыялый гына түгел. Син изге...
— Ризамы?
— Риза, җаным. Әнвәр, никтер минем күңелем ташыйм дип тора. — Гүзәлия башын Әнвәрнең иңбашына куя.
— Һәй, әле генә барча кеше дә көлеп йөрсә иде дип теләп тордың лабаса. Юк, син елама. Беркайчан да. Көл генә. Көлгәндә синең бит уртасындагы чокырлар тагын да матурлана.
— Сиңа шигырь язарга кирәк.
— Язармын әле. Язганым да бар.
— Китсәнә! Сөйләп күрсәт әле, ә?
— Көлмәссеңме?
— Үзең бер көл, бер көлмә дисең... Юк инде, көлмим.

Сандугач ник талда сайрый?
Башка агач беткәнме?
Гел күрәсем килеп тора
Йөрәк якын иткәнне.
Сандугач ник талда сайрый?
Талда ул таймый микән?
Талдан моңлы җыр таратып,
Сөйгәнен сайлый микән?

— Әнвәр, Әнвәр, дим. — Гүзәлия серле күзләре белән Әнвәргә текәлде. — Сөйгәнеңне сайлап алалармыни?
— Кеше үзе сайламыйдыр аны. Йөрәк сайлыйдыр.
— Шулай дисәң генә. Мине йөрәгең сайладымы?
— Йөрәгем.
— Минем дә шулайдыр инде ул, әйеме? Минем кояш баешын мең мәртәбә күргәнем бар, ә менә быел ул бигрәк тә матур. Нишләп алай икән ул, Әнвәр, ә?
— Без үскәнгә шулай күренәдер ул. Элегрәк күрә белмәгәнбездер... Ә мин ак болытларны яратам. Зәңгәр күктә алар каз бәбкәләре кебек йомшактыр кебек тоела. Әй шулар арасында очып йөрсәң иде! Әллә миңа очучылыкка укырга микән? Шәп һөнәр бит, ә?
— Аңа кайда укыталар икән соң? Кемнәрне алалар икән, авылдан да алалар микән?
— Белмим шул. Җәлил абыйдан сорап карыйм әле. Ул белми калмас.

Уку-укыту эшләре белән Казанга бер киңәшмәгә баргач, Җәлил Хөсәенов шәһәрдә 9 нчы махсус мәктәп барлыгын белеп кайтты. Анда җидееллык мәктәп бетергәннәрне дә алалар икән, диде ул. Өч ел укып, аны тәмамлагач, егетләрне очучылар әзерли торган училищега җибәрәләр икән, ди. Тик ул махсус мәктәпкә керер өчен комиссия узасы бар, ә ул бик читен эш, берничә фәннән имтихан да бирергә кирәк, ди. Имтиханнар урысча икән. Менә, Әнвәр, бик теләсәң, син булдыра аласың, сиңа шунда юл тотарга кирәк. Моның өчен тагын да яхшырак укырга кирәк. Рус телен шәп итеп өйрән. Җидееллык мәктәпне сиңа гел бишлегә генә тәмамларлык булсын. Ә мин сиңа булышырмын, ди.

Боларны ишеткәч, Әнвәрнең түбәсе күккә тиде. Үзен ялтырап торган йолдызлы погоннар таккан хәрби формадан күз алдына китергән саен аның йөрәге дөп-дөп тибә башлый иде.

Очучы! Самолетта ак болытлар арасында очып йөрүче бәхетле җан! Аның хыялы тормышка аша түгелме соң? Менә ул хәрби очучы киеменнән авылга Гүзәлияне алырга кайта. Авыл халкы шакката.

Безнең авылдан да шундый лачын чыгар икән, дип. Малай-шалайның күзләрендә көнләшү, юк, кызыгудан ут яна! Их!

Беркөнне алар арасында мондыйрак сүз булды.

— Нишләп син бүген шулай күңелсез? Бер-бер хәл булмагандыр ич? — дип сүз башлады Әнвәр.

— Юк ла.

— Соң?

— Галия апага мунча ягарга су китергән идем. Аның кәҗәсе авырый икән. Гата бабай кибән куйганда, егылып төшеп, аягын каймыктырган, ди. Ә без менә синең белән шундый бәхетле, — диде Гүзәлия, гаепле кеше сыман.

— Һәй, син бигрәк инде. Кәҗә авырганга кайгырып утырыйкмы инде.

— Карт кешенең карап торган бер кәҗәсе бит ул. Галия апаны мин бик жәллим. Тернәксез, япа-ялгыз. Иренең, улының үлем хәбәрен алганнан бирле бөтенләй кара көйде, диләр. Ничек түзәдер.

— Кемгә генә җиңел икән соң хәзер?! Әтиләр сугышта үлеп калды. Әниләр нужа иләгеп или. Үзебез дә җигелеп, бөтен өй эшен тартабыз. Урманнан коры чыбык-чабык җыйган өчен генә дә урманчы Василий Маратның балтасын алып калган. Штраф салган.

— Шулаен шулай да...

— Ник тагын тын калдың? Әйт әле.

— Ишетмисеңмени? Һаман синең белән сөйләшеп утырам ич. Ялгыз калуымны күз алдына да китерә алмыйм, дидем. Галия апа сыман калмасам иде, дидем.

— Мин үзем дә ялгыз чакта эчтән генә гел синең белән сөйләшеп йөрим. Чыннан да, без икебез дә хыялый бугай, әйеме?

— Булса ни. Әйт әле, андый чакта син миңа ниләр сөйлисең?

— Һәй! Әллә нинди планнар корам. Дөньяны матурлыйм.

— Ул нинди планнар соң, Әнвәр?

— Күп инде алар, күп. Әйтеп бетерерлек түгел. Тормыш гел шулай бармас дип, балаларыбызны укытырга юллар эзлим.

— Балаларыбызны?

— Ник читкә борылдың, бердәнберем минем?

— Оялам ла.

— Мин үзем дә оялам анысы. Тик бөтен кешенең балалары була ич. Менә мин училищены бетереп, сине кайтып алырмын, аннары гел бергә булырбыз. Син шәһәрдә укытучы. Мондагы кебек караңгыдан караңгыга тикле бушлай эшләү юк ди анда.

— Син киткәч, мин ничек түзәрмен соң? Мин? — Гүзәлия Әнвәр йөзенә текәлә.

— Белмим. Үзем дә белмим. Түзәргә кирәк, шуны гына беләм. Тормыш куа кешене, бердәнберем. Минем ике энекәш барын беләсең. Аларга да, әнигә дә ярдәм итәргә кирәк бит. Мин аларның терәге. Чыдарбыз инде.

— Әнвәр, син китсәң, мин яши алмам сыман. Шуны белеп тор.

— Гүзәлия, бәгърем, син ни сөйлисең инде! Кил, кочаклыйм әле бер.

— Һе, оста. Өйләнгәч кочакларсың.

— Һи, аныңчы әле... Без гел шулай күзгә-күз карашып кына йөрербезме?

— Кулымны әнә ничек тотасың. Җиткән! Синең кулың нинди кайнар.

— Синеке дә. Ник икән ул?

— Кем белә инде... Бәлкем, шушыдыр инде ул бәхет.

Гүзәлия Әнвәрнең иңенә башын салды. Әнвәр бик шикләнеп кенә, бер кулы белән аны кочып алды.

— Әнвәр, минем башка бүген бер күңелсез уй килде.

— Нинди уй, сөйлә әле.

— Сөйлисем дә килми.

— Йә инде.

— Исеңдәме, без, малайлар, кызлар, урманга җиләккә барганыек. Шау-гөр килеп авылга кайтып җиткәндә генә, синең кулыңдагы тырыс тузанга төшеп капланды. Җиләкләрең юлга чәчелде. Син җыя башладың, мин дә булыштым. Тик өлгерә алмадык. Сыер көтүе килеп чыкты да... бөтен җиләгеңне таптап узып китте. Ә тояклары! Һаман күз алдымда... Тегермән ташлары тикле. Лап-лап итеп изеп бетерделәр.

— Андый гына хәлләр була инде ул.

— Була да бит... Берәр күңелсезлек килү галәмәте була күрмәсен. Көне буе шул хәл искә килә дә төшә, килә дә төшә.

— Әйтәм аны бүген синең күзләр юешләнгән. Галия апаның кәҗәсе дә авырып киткән, җитмәсә.

— Көлмә әле.

— Көлмим ич. Оныт син ул уеңны, яме. Юк-бар өчен дә борчылма. Исән булыйк. Авырмыйк. Дөнья киң, яшибез әле, бердәнберем. Яле, елмай әле. Менә шулай.

Гүзәлия Әнвәргә сыена. Аның күңелендәге шикләр эреп юкка чыга. Дөнья тагын түгәрәкләнә.

* * *

Кара кышның бер көнендә Әнвәрне дәрестән укытучылар бүлмәсенә чакырдылар. Әнвәр шикләнеп кенә бүлмә ишеген шакыды да эчкә атлады. Анда Сталин портреты астында директор Җәлил абыйлары утыра иде.

— Син нинди олы бәйрәм килгәнен беләсеңме, егетем? — диде директор, ә үзе нигәдер серле елмая иде.

— Яңа елдыр инде, Җәлил абый, — диде Әнвәр.

— Аңа хәтле тагын бик зур бәйрәм бар әле. Бөек Сталинның җитмеш еллык юбилее. Ул декабрьдә. — Директор һаман елмая иде. — Менә сине бер йомыш үтәргә чакырдым. Бәйрәм кичәсендә авыл халкы алдында син чыгыш ясарсың. Бөтен укытучылар, укучылар исеменнән. Бөтен шәһәрләрдә, авылларда хәзер, Сталинны котлап, яңа хатлар кабул итәләр. 21 декабрьдә Көектә дә хат кабул итәрбез. Аңлыйсыңмы?

— Әй, абый, мин нәрсә генә сөйләрмен икән. Белмим дә. Булмас ул миннән...

— Син мәктәбебезнең иң яхшы укучысы. Колхозчылар көнкүреше хакында син тагын нindидер сүз ычкындыргансың. Сүзләрең югарыдагыларга ишетелгән бит, энем. Шуңа күрә дә син чыгыш ясарга тиеш.

Менә кайчан гына бөтен халык надан иде. Ә хәзер аңа укырга, белем алырга мөмкинлек туды. Балаларга кая да юл ачык, диярсең. Менә синң да. Шуның өчен рәхмәт әйтерсең. Чыгышың кыска гына булсын.

— Булдыра алырмын микән соң, абый?

— Син дә булдырмасаң! Дружина советы председателе. Аннары укучылар, укытучылар концерты була. Анысын да син алып барырсың. Килештекме?

— Ярар соң инде. Тик минем адәм рәтле киемем юк бит, Җәлил абый!

— Ул ягы бар инде барын. Ярар, рәтләрбез анысын.

Күп тә үтми кием юнәттеләр тагын. Мәктәпне алданрак бетергән бер колхозчы егетнең чалбары Әнвәргә ярап куйды. Ак күлмәк тә таптылар. Сталин туган көнне клубка халыкны укытучылар җыйды. Мичкә яккан булсалар да, клубта салкын иде. Концерт бирергә җыенган балалар туңып калтырадылар, өс-башлары бик юка иде шул.

Башта бөек Сталинга котлау хатын мәктәпнең уку-укыту эшләре мөдире укыды. Аннары бер-ике колхозчы чыгыш ясады. Менә Әнвәргә сүз бирделәр. Ул сәхнәгә чыгып басты да сүзсез генә залга карап тора башлады. Кемдер тыелып кына көлеп куйды. Әнвәр шул якка карап алды да яңгыравык тавыш белән сөйләргә кереште.

— Хөрмәтле авылдашлар! Менә әле генә без бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга котлау хаты тыңладык. Анда барысы да әйбәт язылган. Шуңа кушылып, мин бер генә нәрсә әйтәм. Без, Көек тулы булмаган урта мәктәбе укытучылары, укучылары, бөек Сталинга рәхмәтләребезне, сәламнәребезне юллыйбыз. Аңа исәнлек телибез. Ул исән-сау булса, безнең тормыш тагын да яхшырыр әле.

Яшәсен иптәш Сталин!

Залның кинәт гөрләтеп кул чабуыннан Әнвәр аптырап калды. Ул үзен шулхәтле күтәреп алырлар дип уйламаган иде. Сәхнә артына кереп, Җәлил абыйлары аны күкрәгенә кысты. Аннары концерт булды. Әнвәр концертны матур итеп алып барды. Гүзәлия дә концертта катнашты. Тавышы матур булганга аны еш җырлаталар иде. Ул Сталин турында русча җыр башкарды. Аның:

Сталин — наше знамя боевое,
Сталин — нашей юности полет.
С песнями борясь и побеждая,
Наш народ за Сталиным идет! —

дигән куплеты кул чабуларга күмелде. Концерттан алар бергә кайттылар.

— Син яхшы сөйләдең, — диде Гүзәлия.

— Син дә бик яхшы җырладың. Ничек кул чаптылар!

Бу көнне алар эшкә ярап куйганга шат иделәр. Тик итегенең тишек олтаны аша кергән яңа яуган кар гына Әнвәрнең теңкәсенә тиде.

* * *

Беркөнне Әнвәр Гүзәлиядән:

— Карале, бердәнберем, синең төш күргәнең бармы? — дип сорады.

— Ник сорыйсың?

— Мин бүген гаҗәеп бер төш күрдем әле. Югарыда кулларымны канат шикелле җилпи-җилпи очып йөрим икән. Аннары кайдадыр бер матур урман аланына, хәтфә үлән өстенә килеп төштем. Тирә-юньдәге куакларда меңләгән кошлар сайрый. Алан төрле-төрле чәчәкләр белән капланган. Алардан хуш ис аңкый. Гөлләр арасында бөҗәкләр гөжләп тора. Чәчәктән чәчәккә кунып, бал кортлары, күбәләкләр оча. Шундый рәхәт икән. Мин үзем ашыгам да кебек, китәсем дә килми икән.

Бераз яткач каядыр барырга кузгалдым. Ә юлны белмим икән. Йөгерәм, эзләнәм, таба алмыйм. Аптырагач агачтагы кошларга эндәштем:

— Әй, гүзәл җан ияләре! Миңа юлны табып бирегез әле! — дим.

Менә аларның берсе минем уң җилкәмә килеп кунды да, колагыма нидер чутылдап, агач ботагына күчте. Аннары тагын еракка очты. Мин аның мине үзе артыннан ияртергә теләгәнен аңладым. Ияреп киттем шулай. Ул сайрый-сайрый алга оча, мин артыннан барам. Бара торгач бик якты, бик матур, әллә нинди нурлы тагын бер аланга килеп чыктым. Андагы алма, чия, кура җиләге дисеңме! Юан-юан каеннар, имәннәр башларын күккә чөйгәннәр. Ә алан уртасында бик биек, матур бер йорт тора. Бизәкле тәрәзәләреннән нурлар сирпелә. Мин курка-курка гына аның болдыры янына килдем дә керергәме, юкмы дип шикләнеп торам икән. Шулай икеләнеп торганда кемнеңдер кеткелдәп көлгәнен ишетеп, борылып карадым. Ә анда!

Ап-ак чәчле, ап-ак түгәрәк сакаллы, ап-ак киемле көләч йөзле бик матур бер карт басып тора. Ә күзләре!.. Күзләреннән шулхәтле нур, шулхәтле якынлык балкый. Мин үземне-үзем тыя алмыйча аның җылы кочагына сыендым. Әйтерсең лә үз бабам. Ул зур куллары белән минем башымнан сыйпый икән. Шулай рәхәтләнеп басып торгач, матур бабай:

— Хуш килдең, бәбкәм, — ди. — Менә рәхмәт. Син, улым, Әнвәр атлы бит әле, әйеме? — ди. — Авылымнан берәрегез килгәнне зарыгып көтә идем.

Мин бабайның нурлы күзенә карыйм да озак кына исемемне әйтә алмый торам икән. Аннары:

— Ә син, бабакай, аны каян беләсең? — дим.

— Беләм инде, улым, беләм, — ди. — Сезнең барчагыз да минем оныкларым бит.

Минем телем ачылып китте.

— Ә син, бабай, үзең кем буласың? — дип сорыйм.

— Авылыгызның исеме Көек бит, — ди ул. — Мин шул Көеккә нигез салган бабаң инде, бәбкәм.

— Көек бабаймыни? Әти-бабайлар безгә авылны Көек бабай салган диләр шул, — мин әйтәм.

— Сөбханалла, хак әйтәләр... Мин инде ул, мин, — ди бабай. — Усал кавем безне туган җиребездән кугач, ят дин тага башлагач, мин кабиләмне менә шушы якларга алып килдем. Монда тоташ урман иде. Без аны кистек, турадык. Йортлар салдык. Бушаган җирләргә иген чәчтек. Шулай итеп, матур гына яшәп киттек, бәбкәм. Безнең елга-күлләрдә балык, урманнарда киек тулып ята ие. Син беләсең ич, әнә хәзер дә әле Мәшкелебездә балык нихәтле. Болыннарда юа, кузгалак, чия, күгән, җиләкнең исәбе-хисабы юк. Тик, улым, әрәм-шәрәм, исраф кына итмәгез. Шулай булса, Ходай биргән ул байлык бик күп буыннарга җитәр. Бу җиргә, илгә хәзер сез хуҗа.

— Әй, бабай, рәхмәт инде сиңа. Ә яңагыңдагы җөй каян килде соң? Авыртадыр инде ул, ә? — дип сорадым.

—Бумы? — Бабай кулы белән яңагына үрелде. — Без шулай ару гына яшәп ятканда каяндыр явызлар килеп, авылга ут салды. Менә шул афәттән йортларыбызны, мал-туарларыбызны саклаганда, киемемә ут капты, сакал-мыегым көйде. Тәнем җәрәхәтләнде. Шуннан калган җөй инде ул, улым. Инде авыртуына килгәндә, әллә ни түгел, балам. Менә авылыбызда бер-бер күңелсез хәл килеп чыкканда гына сызлый башлый.

Бабайның минем белән шулай матур итеп, үз итеп сөйләшүеннән мин батыраеп киттем.

— Син шушы матур йортта яшисеңме, Көек бабай? — дим.

— Әйе, улым. Миһербанлы, шәфкатьле, вөҗданлы, гадел гомер иткән халкым һәммәсе шушында яши. Мондагы кәүсәр чишмәсе бик шифалы. Шул суны эчеп рәхәтләнәләр. Ризыклары — бәйрәм ризыгы.

— Көек бабай, минем моннан китәсем килми, — дим икән. Ә бабай шундый итеп башымнан сыйпый, минем бөтен тәнемәниндидер рәхәтлек йөгерә.

— Беләм, беләм, — ди бабай. — Син монда ашыкма әле. Синең, улым, халкыбыз мәнфәгатенә эшлисе эшләрең күп әле. Җир йөзендә гаделлек аз, кешеләрнең бер-берсенә ихтирамы җитми. Менә шуларны

сизеп торам мин, шуңа йөрәгем әрни. Син игелекле бала, кулыңнан әле бик күп мәрхәмәтле эшләр килер. Эшләрсеңме, улым?

— Эшләрмен, Күек бабай, — дим.

— Рәхмәт, улым. Кара әле, син бу аландагы хуш исле үләннәрне күрәсеңме?

— Күрәм, бабай.

— Шуларның берсен сиңа бирим әле, бәбкәм. Менә мәтрүшкә, дәва үләне. Син кайткач аның орлыгын авыл тирәсендәге таулыкларга, урман аланнарына сип. Үрчесен. Ул сиңа гына түгел, бөтен халкыма файдалы, шифалы булыр. Сырхаулаганда шуның белән дәваланыгыз. Онытма, Әнвәр улым.

— Онытмам, Күек бабай. Рәхмәт. Ант итәм.

—Кирәкмәс, улым. Ант итмә, мин сиңа болай да ышанам. Антыңны онута калсаң йә үти алмасаң, рухи газап кичерерсең. Җә, улым, сиңа кайтырга вакыт. Бар инде. Хәерле юл сиңа. Ходай үзеңә дә, барча Күек халкына да бәрәкәтле мул тормыш бирсен. Амин.

Бабай шулай дип җылы кулы белән кабат башымнан сыйпый-сыйпый мине алан читенә хәтле озата килде. Аннары тагын:

— Хуш, бәбкәм! — дип аркама кагылды. Мин борылып караганда ул юк иде инде.

Шул чакта мин:

— Күек бабай, хуш! — дип кычкырганыма уянып киттем. Уянсам, өйгә тәмле мәтрүшкә исе таралган иде.

— Бик хикмәтле төш күргәнсең син, Әнвәр. Мәтрүшкә авырганда, салкын тигәндә бигрәк тә шифалы бит. Дөрестән дә, аны күбрәк үрчетергә кирәк, әйеме?

— Әйе.

— Карале, син моны шундый матур итеп сөйләдең, ул бабай бик матур, мөлаем булып минем дә күз алдыма килеп басты бит.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Менә аларның аерылышу көне килеп җитте. Иртәгә Әнвәр авылдан олы юлга чыгып китә. Хәл кылынган, ул Казанның 9 нчы хәрби һава көчләренең махсус мәктәбенә укырга керергә китә. Җәлил абыйлары белешеп кайткач, ул ныклап шул теләк белән янып йөрде. Җидееллыкны тәмамлаган өлгергәнлек кәгазендә бары бишле билгеләре генә тезелеп тора. Гүзәлиянең дә шулай.

Җәлил абыйлары Әнвәргә геометрия, алгебра буенча рус дәреслекләре алып кайтып бирде. Махсус мәктәпкә керү имтиханнары рус телендә икән ич. Әнвәр теоремаларны, кагыйдәләрне русча да өйрәнде, ә рус теле белән әдәбияттан ул болай да гел бишлегә генә укыды.

Ул көнне иртән үк Актай өстенә соры болытлар күләгәсе ятты. Әле көзгә шактый ерак булса да, елга көзге төскә керде. Гүзәлиянең көне буе эче пошты, кулы эшкә бармады.

Алар бүген кичен үзләре яраткан урында, зур ябалдашлы өянке янында очрашачаклар. Алда бер Ходай гына белгән олы юл. Ничек керерләр алар ул юлга, ничек үтәрләр?.. Кайчан кабат очрашырлар? Алда аларны ниләр көтә?

Әнвәр, каралып киткән суга карап, уйларының очына чыга алмыйча шактый утырды. Гүзәлиясе һаман күренмәде. Нәрсә булды икән дип борчылып бетте. Менә, ниһаять, Гүзәлия, йөгереп килеп, аның муенына сарылды. Алар кочаклашкан килеш озак басып тордылар. Әйтәсе сүзләр инде әйтелгән, ә әйтелмәгәннәре... Алар бик күп, тик киләчәкнең билгесезлеге икесенең дә йөрәген телгәли, ташып торган күңелләрен сулкылдап әрнетә, нишдидер шомлы уйларга батыра иде.

— Эшләрне җайга салуга мин сиңа хат язармын, яме, Гүзәлия! — Әнвәр алда торган вакыйгаларның котылгысызлыгын җиңеләйтер өчен кара күзле гүзәленә елмаерга тырышып карый. Кыз нидер әйтергә тели, тик әйтә алмый, кысылган тыны аны калтырата, ул баш кына селки.

— Син дә педучилищега кер, имтихан бирәсең юк. Отличница. Ә мин комиссия узып, имтиханнарны бирүгә кайтып җитәрмен. Кышкы каникулда гел бергә булырбыз. Ризадыр бит?

— Ри-за-а... — Кызның сүзе бүленеп чыга. Гүзәлия чыдарга тырыша, тамагына килеп тыгылган төер белән көрәшә. Тик менә күзләренә килеп тулган яшьләре буйсынмыйча ага башлый.

— Йә инде, җаным, сабыр булыйк. Йә инде. — Әнвәр Гүзәлиясенең яшьле күзләрен сөртә, кызның күңелен күтәрәсе килеп: — Син инде мин ерак дип, берсенә дә күз саласы булма, яме? — дип, Гүзәлиянең яшьле күзләренә карый. Ә анда бу сүзләргә рәнҗүле дә, сөюле дә, әрнүле дә хисләр ташкынын күреп, урынсыз шаяртуын аңлый. — Әйдә... кайда гына, кемнәр белән генә... яшәсәк тә... бер-беребезгә тугры булырга... ант итик, Гүзәлия... Антмы, Гүзәлия?

— Ант, Әнвәр җаным, сөеклем. Хуш, бәгърем. Менә сиңа истәлегем итеп кулъяулык чиктем. Исеңә төшкәндә алып карарсың.

— Ай, нинди матур. Рәхмәт.

— Йә, мине соңгы кат озатып куй инде. Кайтыйм. Иртәгә сине кыр капкасы янына озата чыгармын. Ярыймы?

— Ярый гынамы соң, җаным. Көтәрмен. Тик «соңгы кат» диюең генә әллә ничек шунда.

— Соң, китәсең ич. Әле тагын кайчан очрашырбыз, тагын кайчан озатып куярсың...

Әнвәр бердәнберенең кайнар кулларын тотып, капка төпләренә хәтле озата барды. Гүзәлия кереп киткәч тә озак кына шунда басып торды. Аның күкрәк читлегеннән нәрсәдер өзелеп төшкән кебек булды.

* * *

Урынына кереп яткач, Гүзәлияне тагын авыр уйлар биләп алды, үзен кая куярга белми озак газапланды. Үзе генә калгач, көннәрен ничек уздырыр ул? Кичләрен дус кызлары, егетләр клубка чыкканда ул нишләр? Әнвәр булмагач анда ник барсын, барса, кем белән нәрсә турында сөйләшсен?

Кызның күзләреннән ихтыярсыз яшь акты. Ул әнисе ишетмәсен дип мендәрен тешли-тешли елады. Инде күптән өченче әтәчләр кычкырды. Елый торгач, башына якты бер уй килде. Бу уй төнге күкне яктыртып узган аҗаган кебек булды. Әгәр дә хәзер берәр кеше кызның бу мизгелдә кинәт ачылып киткән йөзен күрсә, аның нindидер карарга килүен чамалар иде.

Дөрестән дә җаен тапты бит ул. Иртән Әнвәрне озатырга баргач, янында әнисе булса да, кулына ябышам да җибәрмим, дип уйлады. Китмә, калдырма мине, китсәң, алып кит, дияр. Югыйсә мин үләм, дияр. Шулай итсә, китмәс, аны да алып китәр. Ул үзе дә уйларыннан интегеп ятадыр, риза булыр, дип фикер йөртте кыз.

Инде хәзер йокламаска, иртән басу капкасы янына соңга калмаска, күрүгә кулына ябышырга... Үзе генә калса... шаша бит ул.

Газаплы уйлар тулы төн үзенекен итте. Инде торырга вакыт җиткәндә Гүзәлиянең күзләре үзләреннән-үзләре азга гына йомылып китте. Их, Гүзәлия, Гүзәлия! Соң гына кайтып, авыр сулап, лышкылдап елаганын ишетүеннән битәр йөрәге белән тоеп яткан әнисе изрәп йокыга талган кызын уятырга кызганды. Янына килеп, сулып калган йөзенә карап башыннан сыйпады да йорт эшләренә чумды. Уятмады, сорашмады. Кыз чагында кем еламый да, кемнең йөрәге кем өчендер сулыгып типми инде ул...

* * *

Яшь йөрәкләрнең татлы газабына битараф кояш бераз күтәрелүгә, Әнвәр изрәп йоклап яткан энеләренең өстендәге юрганнарын әйбәтләп япты, әнисен кочаклап үпте дә төенчеген алып юлга чыкты. Капканы ачкач, баганага сөялеп уйга калды. Аның багананы сыйпаганын күргән әнисе:

— Улым, әллә китмисеңме, ә? — дип, тагын бер кат йөрәген телгәләгән уйларын әйтеп карады. — Авыл баласы бит син. Таз толымы тотып кына калмассыңмы, дим.

Әнвәр, айнып киткәндәй, әнисенә борылды:

— Әни-и... Сөйләштек ич инде.

— Озатырга гына барыйм инде алайса?

— Анысын да сөйләштек. Ярар, хуш, әни, хуш.

Үсмер егет нык-нык атлап урам буйлап басу капкасы янына китеп барды.

Гүзәлия киләм дигәч, Әнвәр әнисенең озата чыгарга теләвен кире какты. Егетнең бер күзе әле олы юлда, әле авыл урамында иде. Авыл халкы Өчкүлдән Алексеевскига сөт ташучы машина килгәнне көтеп аптырап бетә. Шул машинага өлгерсәң, Казанга көне белән барып җитә аласың. Өлгермәсәң, очраклы берәр машина көтеп, көн буе утырган чаклар була. Машина күренгәнче Гүзәлия килеп өлгерерме икән? Киләм, озатам, диде бит. Машина озаграк килми торса ярар иде, дип уйлады ул.

Кояш инде әнә каравыл йорты түбәсенә менеп җитте. Чирәмдәге чык та кибеп өлгерде. Гүзәлия генә һаман күренмәде. Чү, олы юлда тузан болыты пәйда булды түгелме? Әйе шул, әнә машина тавышы да ап-ачык ишетелә башлады. Ул да түгел, әрҗәсендәге сөт флягаларын шалтыратып килеп тә җитте. Капка төбендә көтеп утыручыларның гадәттә капчык-төргәкләренә ябышканнарын күрергә өйрәнгән шофер авыл урамыннан күзен ала алмаган яшь егеткә икеләнеп карап алды да машинасын туктатты.

— Әйдә, егет, китәргә җыенгансың, күрәм. Кереп утыр кабинага. Синең бәхеткә күрше авылларда юлчы булмады, — диде ул.

— Абый җаным, бераз гына көтә алмыйсыңмы, ә? Әйберемне онытып калдырганмын, әни шуңа йөгерде. Өлгерә алмый, күрәсең, — дип Әнвәр хәйләләп маташты. Елмаеп торган шоферга күз салгач, үзе комач шикелле кызарды.

— Ярар, биш минут эчендә генә сөт әчемәс әле, тик озак тора алмыйм шул, егетем, — диде шофер.

Юк шул, Гүзәлия һаман күренмәде. Килер әле, ярты сәгатьтән, эчке күлмәге өстенә кофта гына эләктереп, сулуы кабып, алсу иреннәре кибеп, атлыгып килеп җитәр. Тик Әнвәр машина әрҗәсендә бәреләсугыла, сөт флягаларына атланып, әрнегән йөрәген басар өчен иреннәрен күгәрткәнче тешли-тешли шактый китеп өлгергән булыр.

— Йә, егет, әйдә, кереп утыр, китсәң... Бүтән көтә алмыйм, — диде шофер, ни өчендер гаепле кеше тавышы белән. Әнвәрнең өзгәләнеп биеп торганын күреп, әллә ул яшь егетнең хәлен аңладымы? Бәлки, шулайдыр, йөрәк кемдә дә бар ич, бәлкем, сизенгәндер.

Тартмады Әнвәрнең аягы, юк, һич тартмады. Ул кабинага кермәде, югарыга, әрҗәгә үрмәләде. Машина авыл кырыеннан узганда аның күзе һаман урамнарны сөзде. Аңа менә-менә кадерле таныш гәүдә күренер дә кул изәр кебек тоелды. Юк шул, Гүзәлиясе күренмәде.

Их, дөнья... Менә авылның тузанлы юл тасмасы артта сузылып калды. Тау өстендәге зират, кырдагы ялгыз җил тегермәне дә инде тоныкланып артка шуды. Үсмер егет шулай олы, катлаулы дөньяга чыгып китте. Юк шул, аның шәүләсе генә китте. Ә җаны, рухы, сулкылдап әрнегән кайнар йөрәге туган авылының яшел чирәмле урамнарына, урман-болыннарына, Актай янындагы өянкеләргә, комлы ярларга, анда үскән әрекмәннәргә уралып калды. Соңгы чиккә кадәр, авыл күздән югалганчыга хәтле, Әнвәр каерылып-каерылып борылып карады, Ходайдан могҗиза көтте, өметләнде, өзгәләнде. Ләкин бу дөньяда могҗиза аз шул, булмады.

Машина такыр юлга чыккач тагын да тизрәк җилдертә башлады. Шул мизгелдә Әнвәрнең күз алдыннан мәһабәт Көек бабайның бик җитди йөзе чагылып узды. Үсмер егет: «Бабай нигәдер борчыламы икән әллә?» — дип уйлап куйды...

Гүзәлия Әнвәр киткән көннән үк хат көтә башлады. Кәгазь капчык ертыгына язылган конвертсыз хат, дөрестән дә, аңа икенче көнне үк килде. Аны Гүзәлиягә биргәндә хат ташучы Нәфига апа, телен шартлатып:

— Их, наный! Менә шундый мәхәббәтне татырга өлгерә алмадым шул. Гәрәем бәгърем «яратам» дип әйтергә дә өлгерә алмыйча фронтка китеп югалды, — диде. — Менә ичмаса егет бу синең Әнвәрең! Ничек дип язган бит: «Синең гүзәл күзләрең төбеннән ургылган сөю нуры миңа Алишер Нәвоиның Фәрһаде сыман тау-таш актарырга көч бирә».

Алтын кош тоткандай басып торган Гүзәлиянең сораулы карашын күргәч, Нәфига аңлатып та бирде.

— Теге сөт машинасында йөрүче татар егете калдырып китте. Әнвәр аның белән барган икән. Ул егетнең машинасына минем дә утырып йөргәнем бар. Ипле егет. Кыр капкасы янында туктады да:

— Сине очратуым әйбәт булды әле, — ди. — Мәле, шушы хатны бер бәхетле кызга илтеп бир әле, — ди. — Гүзәлия икән исеме. Әнвәр дигән яшь кенә бер егет, бүтән кәгазе булмагач, аны менә шушы капчык кәгазенә юлда язып калдырды. Анда аның үзе чыгарган җыры да бар. Бирә күр, яме, — ди. — Бер күрүдә яраттым мин ул егетне. Маршрутымны үзгәртеп, Чулманга хәтле илтеп куйдым үзен. Башта озак кына әрҗәдә барды. Аннары чакырып кабинага утырттым. Шундый уйчан егет икән. Бик сорагач, аңлатып бирде. Авылдан Казанга укырга китеп баруы икән. Өзелеп яраткан кызым никтер озатырга килми калды, ди. Бик кайгырып баргач, мин әйтә куйдым:

— Алай үзеңне бетермә, — дим. — Кызлар табылыр ул, — дигән идем, шундый итеп карады!

— Ничек инде? Нинди кызлар? Миңа Гүзәлиямнән башка бүтән беркем дә кирәкми, — ди.

— Ярар, — мин әйтәм. — Дөрес итәсең. Яраткач, яратырга кирәк. Тик син ул тикле кайгырма. Авыруга сабышуың бар. Андый чакта хатын-кыз елый, ә син җырла, — дим. Берәр җыр беләсеңме?

— Беләм, ник белмәскә, — ди. Менә әле юлда килгәндә генә үзем дә берне чыгардым, — ди.

— Китсәнә! Вәт, молодчина, — дим. — Йә әле, җырлап кара. Җырлады бит. Чулманга җиткәнче, мин аның ул җырын отып та алдым. Шултикле ошады ул миңа.

Яратуым шулкадәрле көчле,
Минутлар гомердәй тоела.
Ләззәтле дә, газаплы да чагым,
Син генә, син генә уемда.
Зәңгәр күкләр, зәңгәр күлләр миңа
Синең күзләр кебек күренә.
Бары син, бары син мәңгегә
Юл салдың күңелем түренә.

Шушы җыры белән өзде үзәкне. Ул егет кәгазь капчык ертыгына язып сөйгән кызына дип менә шушы хатны миңа тоттырып китте.

Гүзәлия кәгазьне утлы күмер тоткандай алды да күкрәгенә кысты. Озын кара, кайтарылып торган керфекләре дерелдәп китте, аның алсу битләре буйлап эре күз яшьләре тәгәрәде. Их, күздән түгел, җанның, бәгырьнең үзеннән ихтыярсыз саркыган шул саф яшьләрне күрмәс-булдырмас өчен мин әллә ниләр бирер идем. Мәхәббәт янында күз яшьләре булмасын иде. Алай дисәң... Әллә булсынмы икән? Саф мәхәббәт татлы газап белән өретелгән түгелме соң ул? Җан белән тән кебек алар бары тик бергә, бербөтен булып кына яши алалар түгелме соң?

Яшьләре кибә төшкәч, Гүзәлиянең күзләре шәмәхә карандаш юллары буйлап йөгерә башлады. *«Гүзәлия, бердәнберем! Күз нурым! Кайнар сәлам сиңа! Аерылганыбызга берничә сәгать кенә булса да, еллар узган шикелле тоела. Озатырга килә алмадың. Юк, бәгърем, үпкәләмим. Өзелеп сагынганга гына язам. Менә китеп барам, ә йөрәгем синең белән, авылым белән калды. Уемда син генә. Өзелеп-өзелеп сине дә, авылны да яратам мин. Шуны белеп тор, бердәнберем. Машинадан сикереп төшеп, кире йөгерергә ничә кат талпындым. Тик кеше көләр дип кенә тыелып калдым. Хуш, бәхетем. Озак тормам, кайтырмын. Кайда гына булсам да, синең матур күзләрең төбеннән ургылган нурлар миңа Алишер Нәвоиның Фәрһаде сыман тау-таш актарырга көч бирә. Ачуланма. Менә әле генә чыгарган җырым. Очрашканчы минем төсем булсын. Әнвәрең».*

Әнвәрнең Гүзәлиягә бу беренче һәм соңгы хаты булды. Йа Ходаем, бу гөнаһсыз кыз балага сабырлык бир. Кәгазь капчыгы ертыгына шәмәхә карандаш белән язылган бу хатны Гүзәлия бик күп тапкыр укыды. Шул кәгазь ертыгы аның өчен дөньяда иң кадерле, иң кыйммәт нәрсәгә әйләнде. Басып та, ятып та, утырып та, караңгы төшкәндә дә, таң атканда да йөрәге, җаны сөюдән, юксынудан талкынганда Гүзәлия шул хатны алып укыды. Укыган саен үрсәләнде, тора-бара карашын каядыр еракка төбәп, күңел түрендә генә йөрткән егет сурәтен күз алдына китереп, инде әллә кайчан хәтергә сеңеп калган хаттагы сүзләрне кабатлап, йөрәгенә ял алды.

* * *

Казан Әнвәрне көтеп алмады. Битараф кына капты да йотты. Аның кебек бәхет эзләп килгән яшүсмер егетләр, кызлар азмыни монда? Киләләр, ФЗӨләргә, һөнәр училищеларына керәләр, укыйлар, эшләргә өйрәнәләр. Чыдаганы чыдый, чыдамаганы... Анысы инде аның үз эше.

Менә Әнвәрне дә олы хыяллары, матур тормышка омтылышы шәһәргә алып килде. Тырышлыгы да, сәләте дә бар аның. Никадәр генә сагынмасын, өзгәләнмәсен, укыр, кеше булыр. Акча да юнәтә башлар, әнисенең кул астына керер, энеләрен аякка бастырырга ярдәм итәр. Гүзәлияне дә шәһәргә алып килер. Юк әле, юк, аңа хәтле ул ялтырап торган погонлы, алтын төймәле кителе йә киң каеш белән буган гимнастерка, формалы чалбар киеп авылга кунакка кайтыр. Хәбәр шунда ук бөтен авылга таралыр, аны Гүзәлиясе дә ишетер. Үрсәләнеп, кич җиткәнне көтәр, эңгер-меңгер төшүгә яраткан өянкеләре янына йөгерер. Ә Әнвәр күптән инде анда булыр, кочагын җәеп каршы алыр. Бер ел буена күңелендә күкрәк читлеген актарып чыгарлык булып җыелган назлы сүзләрен пышылдар. Аларның йөрәкләре тагын бергә кушылып тибәр. Шуңа шатланып Зөһрә йолдыз тагын да матуррак җемелдәр. Гүзәлия тагын, алып кит мине, дияр. Әнвәр аны тынычландырыр, бер ел чыдадың бит инде, калганына да түз, дияр. Үзең дә укый тор, дияр. Аннары мәңгегә бергә булырбыз, бәгърем, дияр. Гүзәлиясен ничек тә күндерер. Ә бүгенгә...

Бүгенгә әле дөнья мәшәкате муеннан. Бу хәрби мәктәпкә керер өчен ай-яй нинди медицина комиссиясе үтәсе бар икән. Әнвәр шикелле унбишләп үсмерне бер командага туплап, кабинеттан кабинетка ничек кенә йөгертмиләр!

Әйләнгеч урындыкка утыртып, күзеңне йомдырып, әйләндереп-тулгандырып карыйлар икән. Караңгы бүлмәгә алып кереп тикшерәләр, таблицалар укыталар, еректан, арка ягыннан торып озын-озын саннар кабатлаталар. Әллә нинди катлаулы диаграммалар, таблицалардан төсле-төсле өчпочмаклар, квадратлар, түгәрәкләр санаталар. Гәүдәңне аркылыга-буйга үлчәп, капшап бетерәләр икән.

Берничә көн шулай изалаганнан соң Әнвәргә, ниһаять, «годен» дигән нәтиҗә чыгардылар. Инде аңа рус теленнән, геометриядән, тарихтан, алгебрадан имтихан гына тапшырасы калды.

Медицина комиссиясе беткән көнне Әнвәрне зәңгәр гимнастерка өстеннән биленә киң каеш салган, зур гына башлы, эре сөякле, зур авызлы, сирәк сары чәчле бер егет туктатты. Әнвәр аны үз юлында моңа чаклы да күргәләп, аның чәченең сирәклегенә гаҗәпләнгән иде.

— Комиссия узып беттеңме? — дип сорады сирәк чәч, әллә кайчан таныш кешесенә мөрәҗәгать иткәндәй.

— Уздым.

— Слушай, минем сиңа бер үтенечем бар. — Зур авызына ирек биреп, сирәк чәч эре сары тешләрен күрсәтеп елмайгандай итте. — Әллә нәрсә түгел инде ул. Аптырап калма. Менә мин күз буенча үтә алмадым. Минем үтенечне үтәрсеңме?

— Белмим шул. Нинди үтенеч икән ул?

— Пустяк. Минем исем-фамилия язылган менә шушы медицина кәгазе белән күз табибына яңадан кереп чык әле.

— Ничек инде? — Әнвәр аңламады. — Алай буламыни? Анда синең фотосурәтең ябыштырылган ич.

— Әй, анысы чепуха аның... Минекен алып, синекен ябыштырып куябыз. Кыскасы, бер ярты сәгатькә генә син мин булып торасың. Шуның белән шито-крыто.

Ниһаять, Әнвәр төшенә башлады. Бу зур авыз аны алдауга өнди ич.

— Юк, мин риза түгел.

— Мин Казаннан. Имтиханнарга бергәләп әзерләнер идек, ә?

— Юк, юк! — Әнвәр борылып китеп үк барды.

Икенче көнне мәктәп ишеге төбендә Әнвәрне теге егет белән бер хатын каршы алды.

— Менә шушы авыл малае инде ул, — диде хатынга сирәк чәч.

— Энем, минем улым карточкасы белән күз табибына кереп чыксаң, акча бирер идек. — Хатын Әнвәрнең шактый таушалган, тез башлары калкып торган чалбарына карап алды. — Имтиханнарга да бездә бергәләп әзерләнер идегез. Тыңла әле, менә бу балбес, бик тә летчик буласым килә, ди. Син дә шулаймы?

— Әйе.

— Менә күрдеңме? Теләгегез дә уртак. Дус булырсыз.

Иреннәрен кып-кызыл итеп буяган бу хатынга Әнвәрнең ачуы килә башлады. Ник шулай малаен кайгыртып йөри икән ул? Ә үзе «балбес» ди. Ә безнең ишене кем кайгыртсын?..

— Апа, мин һич тә риза түгел. Алдау ачылса, кем җаваплы була? Минме?

— Нишләп алдау? Нишләп ачылсын? Алдашу түгел бу. Яшь кешенең очучы булырга дигән теләге генә тормышка аша.

— Юк, мин каршы. Хушыгыз.

Әнвәр борылып китеп барды. Мәктәп Бауман урамына якын гына урнашкан иде. Урамга төшеп җиттем дигәндә генә, Матбугат йорты янында аны теге сирәк чәч куып җитте.

— Соңгы кат әйтүем, Хөснуллин, риза буласыңмы, юкмы? — диде балбес.

— Юк! Әйттем — бетте.

— Ну, алайса, үзеңә үпкәлә! Киребеткән деревенщина!

Балбес ачуыннан таптанып алды да кискен генә борылып халык арасына кереп китте.

Икенче көнне Әнвәр соң гына, апасының сүзен тыңламыйча, шәһәр карарга чыккан иде. Җәяү генә кайтышлый Спартак урамының караңгы почмагында аны куаклар арасыннан чыгып, дүрт-биш яшүсмернең үзе артыннан килүен күрде. Әнвәр, шикләнеп, адымнарын тизләткән иде, тегеләр йөгереп аны куып җиттеләр. Кайсыдыр:

— Шулмы? — дип сорады.

— Шул, үзе.

Үсмерләрнең буйга озынрагы:

— Каяле, авыл егете, син байдыр... Безгә акчаңны чыгар әле, — дип, Әнвәргә якын ук килде.

— Минем бернинди акчам юк. Авыл кешесе булгач, миңа акча каян килсен.

— Ялганлама. Кая, кесәңне карыйк әле!

Үсмер Әнвәрнең кесәсен актара башлады. Аннан ике-өч сум акча килеп чыкты. Әнвәр аның кулын эләктереп алды:

— Нишлисең син! Юлга дигән соңгы акча бит ул!

— Егетләр! Карагыз әле моңа! Алдаша бит бу! — Үсмер Әнвәрнең эченә китереп сукты. Әнвәр авыртудан бөгелеп килсә дә, үзен-үзе тиз кулга алды. Кинәт кенә тураеп, ул сугыш чукмарына ташланмакчы иде, кинәт башына бик каты итеп бәргәннән алга сөрлекте, аның күз аллары караңгыланды.

— Нишләвегез бу, кабахәтләр! — Әнвәр сүзләрен әйтеп бетерә алмады, юл читендәге күлдәвеккә ауды. Шул мәлне әллә каян Көек бабайның кайгылы йөзе пәйда булды. Карт башын чайкый-чайкый еракка, караңгылыкка очты. Сугыш чукмарлары, тынсыз калган Әнвәрне төрле яктан рәхимсез типкәләп, куаклар арасына кереп юкка чыктылар...

Исламия апаларына Әнвәрне һава суларга чыккан күршеләре алып кайтты. Энесенең күгәреп чыккан күз төпләрен, пычрак киемен күргәч, апасы һушын югалта язды.

— Наным, нәрсә булды? Нишләттеләр сине? Кем?! — дип, бер алдына, бер артына чыкты.

Җизнәсе дә аның янында бөтерелде:

— Әйткән идек бит... үзең генә чыгып йөрмә, дип. Менә инде, ә... Менә инде.

Хәле авыр булса да, Әнвәр «ашыгыч ярдәм» машинасы белән китүдән баш тартты.

— Андый гына хәлләр була инде ул, — диде. — Бер-ике көннән терелəм мин, терелəм.

Дөрестән дә, ике-өч көн дигәндә ул аякка басты, аппетиты да ачылды, тик эче бик каты авыртса да, апаларына әйтми йөрде. Кызыша башлаганын да яшерде. Берничә көннән эче урыны-урыны белән кара янып чыкты. Шуннан соң гына хәлен әйтми булдыра алмады. Хастаханәгә илтеп салганда аның эче әрнеп-әрнеп туктаусыз авырта иде.

Табиблар эч ярысы ялкынсынган, үлеге инде эчәкләренә таралган дигән диагноз куйдылар...

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Сөлек кебек нәфис буйлы, дулкын-дулкын кара чәчле, кара кашлы, кара күзле яшь егетнең үлем хәбәре авыл өстенә зират ягыннан зәңгәрсу-кара болыт ишелеп, дөньяны томалап алган мәлне килеп иреште. Ул яктан болыт килгәндә авыл берьюлы тынып кала. Ара-тирә борчылып эт өргән тавышлар гына ишетелгәләп ала. Карт-корының урамда уйнап йөргән оныклары исенә төшә. Яшеннән куркып йөгерә-йөгерә кайткан балалар да әби-бабаларының пошаманлы йөзләрен күреп тып-тын калалар.

Барча кеше, хәвефтән, зыян-зәүрәттән Ходай үзе сакласын дип теләк тели-тели, йөрәкнең әллә кайсы почмагында гасырлар буе саклаган курку хисенә бирелә. Сиздермәскә тырышса да, барыбер табигатьнең илаһи куәте каршында үзенең көчсезлеген, ваклыгын аерата шул чакта күрә.

Хат ташучы Нәфига Әнвәрләр капкасыннан давылның беренче сулышы бакча читәннәрен, коймаларны чөереп аткан минутта ук килеп керде. Капка аның кулыннан ычкынып шапылдап ябылды. Нәфига, ян тәрәзә яныннан йөгереп диярлек үтеп, өйалды ишегенә килеп сыенды да, аны кагып та тормастан, эчкә атлады. Аннары ике кулын алъяпкыч астында кушырып торган Зәйнәп апага сары кәгазь сузып тынып калды.

— Нәфига, сеңлем, шундый мәхшәр вакытында нишләп йөрисең? — диде Зәйнәп апа, ләкин үзе урыныннан кузгалмады, кулын да сузмады.

Нәфига кинәт лып итеп идәнгә утырды, үксеп-үксеп елап җибәрде.

— Менә бит, менә, — дип, сары кәгазьне селкеп-селкеп алды.

— Нәрсә ул... ни булган... ник елыйсың?

Олы кешенең кинәт шулай сыгылып төшүеннән аптырап, ана, ниһаять, Нәфига янына килде, теге кәгазьне алды, күз йөртеп чыкты. *«Мама приезжай скорее Казань. Погиб Анвар. Твоя дочь Исламия».*

Зәйнәп апа моны кабат-кабат укыды, берни аңламады. Аннары тәрәзә янынарак барып та укып карады. «Погиб» сүзе һаман аның аңына барып җитми иде.

— Погиб, дигән бит, Зәйнәп апа. Погиб, дигән Исламия апа. Әнвәргә нидер булган... Сине чакыра бит...

— Соң... чакыргач... барырга кирәк инде...

— И Ходаем, китеп тә өлгермәгән бала... Ни генә булды икән соң?.. Ничек шулай тиктомалдан үлде икән соң ул?..

Нәфиганың шул «үлде» дигән сүзе кинәт Зәйнәп апаның йөрәгенә кадалды. Ана чайкалып китте, егылмас өчен диварга тотынды, ава-түнә сәкегә таба атлады. Уллары Мансур белән Хәйдәр, әниләренең егылырга җитешкәнен күреп, аның итәгенә барып ябыштылар. Аларның елаган тавышы Зәйнәп апаны айнытып җибәргән кебек булды. Ул улларын башларыннан сыйпап, сәкегә барып утырды. Елый алмады ул. Күңеленә нидер булды, ул карашын каядыр еракка төбәде.

— Менә ник... ике-өч көн буена... йөрәгем чәнчегән икән...

Шушы көннән бәхетсез ана саңгырауланып калды. Тышта давыл котырынды, капкаларны, коймаларны чөереп ыргытты, шатыр-шотыр яшен яшьнәде, чиләкләп бозлы яңгыр койды. Ярларын ишеп ташыган ерганаклардан шаулап аккан су бәрәңге бакчаларына кызыл балчык китереп өйде.

Әнвәрне шәһәр зиратына күмделәр. Әнисе Зәйнәп апа аны соңгы юлга озатырга килеп өлгерсә дә, авылга алып китә алмады.

* * *

Әнвәрнең үлем хәбәре хәвеф өстенә хәвеф булып ятты, сәгате-минуты белән авылга таралды. Суынмады-нитмәде, Гүзәлияләр ишеген дә атлап керде. Кичерешләреннән, йөрәген өзлексез имеп торган сагынуыннан җанын кая куярга белми йөргән сәгатьләрнең берсендә Гүзәлия күрше Миңнафа апасы белән әнисе нидер сөйләшеп торганына игътибар итте. Әнә әнисе, Гүзәлиягә ымлап, бармагын иренемә тидерде.

Гүзәлиянең бу ишарәне күреп калганын сизенгәч, әнисе белән Миңнафа апа почмак ягына кереп киттеләр. «Миннән нәрсәдер яшерәләр», — дип уйлап алды Гүзәлия.

...Тирә-юньдәге кешеләр белән очрашкач, аларның никтер карашларын яшерүләреннән шомланып, Гүзәлия ник шулай итәсез, дип сорарга базмады. Әнисенең күзендә әллә ничә тапкыр яшь күреп аптырап йөрде. Аның никтер саргаеп киткән йөзендә, ирен почмакларында нәни йомгаклар ешрак уйный башлавын шәйләде. Көн саен ике-өч кереп чыга торган дус кызы Миңлегөл дә күренмәде. Гүзәлия сорап кергәндә ул авылның әле теге очына, әле кибеткә, әле район үзәгенә авыздан өзеп җыйган май, йомырка сатарга киткән була иде. Ә Әнвәрдән өзелеп көткән хатлар һаман юк иде.

Гүзәлиянең күңелендә туган кайнар хис аның йөрәген биләде, сагынуга кушылып, түземлеген җуярга мәҗбүр итте.

Актайга су алырга төшкәндә басмада ике хатынның:

— Үзе килә, үзе, — дигән сүзләрен ишетеп калгач, Гүзәлиянең тез буыннары бушап китте. Күңеленнән куып йөргән хәвефле уйларын ул инде яшерә алмас булды. Кайтты да, чиләкләрен капка янында ук онытып калдырып, әнисен барып кочаклады. Коточкыч фаҗигане ничек кенә әйтим дип йөргән ана кызының шулай сүзсез генә килеп кочаклаганын үзенчә юрап:

— Сабыр бул, кызым... Ходайдан сабырлык сора... Үлгән артыннан үлеп булмый бит. Әнвәрнең тәкъдире шундый булган, күрәсең, — дип юатырга теләде.

Кинәт җир убылды, кояш күк гөмбәзеннән аска тәгәрәде, упкынга төшеп капланды. Дөньяны дөм караңгылык басты. Гүзәлия, әнисе кочагыннан шуып, җиргә ауды. Аның куллары үзләреннән-үзләре йомарланды. Ул йодрыклары белән Җир-ананы төя башлады:

— Минем мәхәббәтемне син күтәрә алмадыңмыни, җир? Синең салкын кочагыңа Әнвәр нәрсәгә кирәк булды?! Ансыз мин хәзер нишлим инде, ә? Ул юкка гына күккә ыргылмаган икән шул!

— Чү, балам, чү! Зинһар, сабыр бул... Сабырлыкка ни җитә... — Ана баласын түземлеккә өндәде. Гүзәлияне көч-хәл белән өйләренә алып кереп урынга салды.

И Җир-ана! Яшь гүзәлне, гөнаһсыз балаңны, зинһар, гафу ит. Синең бер гаебең юк икәнне каян гына белсен инде ул. Гаделсезлек инде бу, нишлисең бит. Кешеләр үз авырлыкларын еш кына сиңа сылтыйлар, ә син күтәрәсең. Рәнҗеми генә бусын да күтәрсәң иде. Синең сабырлык кешеләргә дә иңсен иде, Җир-ана.

Гүзәлиянең хәлен җиңеләйтер өчен әнисе ни генә кылмады. Нәни баланы көчләп ашаткан кебек кулына кашык тоттырып ашатты, эчертте. Урамга чыкса, артыннан калмады. Гүзәлия кич җитүгә Әнвәре белән очраша торган урынга — Актай ярындагы өянке янына юнәлә, сәгатьләр буена шундаауган агач өстендә тын гына утыра иде. Күзеннән мөлдер-мөлдер яшь ага, ә карашы һаман суда, әйтерсең лә анда Әнвәр йөзен күрә иде. Эндәшсәң, җавап та бирә, эндәшмәсәң, кичләр буе ләм-мим сүзсез утыра. Тыгыз кара чәч толымнарын сүтеп, таратып ташлый, аннары тарый, үрә, үзе тирән уйга чума.

Карт өянке әллә каян килеп бәрелгән җилдән кинәт кенә шаулап ала да тына. Аның суга тияр-тимәс чайкалган сыек ботакларыннан бер-ике сары яфрак тымызык суга төшеп, балдак-балдак түгәрәкләр ясый, аннан әйләнеп йөри-йөри дә агып китә. Аңа көндез энә караклары менеп кунаклый, маймычлар килеп төртелә.

* * *

Тормыш дәвам итә. Тик менә аның, Гүзәлиянең генә, күге караңгы, күңеле китек, тормышы комга терәлгән көймәдәй туктап калды. Ул шулай уйлый, ә тирә-юньдәгеләр башкача фикер йөртә — авырлыкка бирештеңме, ул сине баса, кешелектән чыгара. Шуңа күрә чыдам, түземле булырга, тормышка яраша да белергә кирәк.

...Мәктәп директоры Җәлил Хөсәенов киңәше белән Гүзәлиянең туганнан туган фронтовик Әхәт абыйсы безнең сылуыбызны ияртеп район үзәгенә барды, гариза яздырып, аның документларын педагогия училищесына тапшырып кайтты.

Шулай итеп, Гүзәлия педучилище студенткасы булды. Мәктәпне гел бишлегә генә бетергәнгә, аны имтихансыз кабул иттеләр.

Уку елы башлангач, авылдан, өйләреннән аерылып тору тагын авыр булды. Ул авылын сагынды, Әнвәр белән йөргән сукмакларны сагынды, яшь йөрәгенә урын таба алмый интекте. Ял көннәрен җиткерә алмыйча тилмерде. Үзеннән алдарак укырга кергән егетләр, кызлар, аның ачы кайгысын белеп, хәленә керергә, азга гына булса да авыр кичерешләрен җиңеләйтергә тырыштылар.

Беркөнне өлкән курста укучы Зәкия Гүзәлия янына тулай торакка килде. Ул квартирада яши иде.

— Гүзәлия, без, студентлар, авылыбызга кайтып концерт куярга җыенабыз. Синең матур җырлаганыңны барыбыз да белә. Әйдә, син дә катнаш, — диде. — Нинди җыр җырлыйсың?

— Миңа җырлап йөрергә генә калды шул. — Гүзәлиянең күзләрендә әрнүле очкыннар уйнады.
— Гүзәлия, матурым. Дөньяда гашыйк булмаган кеше юктыр ул. Мин дә гашыйк, тик... Әй, сөйләрмен әле бер. Йә, нинди җыр җырлыйсың?
— Ә үзем чыгарган җырны җырларга ярыймы?
— Син җыр чыгардыңмы? Ну, молодец... Ярый гынамы соң? Бик яхшы булыр.
Үзебезнең авыл студентлары концерт куялар дигәч, халык клубка шыгрым тулды.
Концерт төрле-төрле интермедияләр, скетчлар, җырлар, биюләр белән аралашып барды. Халык рәхәтләнеп ял итеп утырды. Менә концертны алып баручы Кәрим:
— Ә хәзер сезгә Гүзәлия Гайнетдинова үзе чыгарган җырын башкара! — дигәч, халык тып-тын булды. Гүзәлиянең бәхетсез мәхәббәтен кем генә белми дә, кем генә аны кызганмый иде.
Гүзәлия чыгып басты, бераз залга карап торгач, тирән сулап куйды. Зал да, сәхнә артындагы иптәшләре дә карашларын аңа төбәп көтәләр иде. Гүзәлия башын аска иеп, үзәккә үтәрлек моңлы тавышы белән җырлый башлады.

Сөюнең мин ләззәтеннән мәхрүм,
Ә газабы буа буарлык.
Күз яшьләрем кипте, хәсрәт калды,
Көч калмады аны юарлык.

Залда кемдер сулкылдап алды.

Кара язмыш миңа күлмәк текте,
Ул күлмәгем кара бизәкле.
Сагынуга түзеп була икән,
Өметсезлек өзә үзәкне.
Ялгыз башын кая куяр диеп,
Язмыш мине изеп күзәтте.
Ялгызлыкка түзеп була икән,
Өметсезлек өзә үзәкне.

Гүзәлия җырлап бетергәч, залга карады.
Залдагы әбиләр, апалар елый иде. Алар арасында сөекле ирләрен, улларын югалткан, әрнеп-әрнеп, өметләнеп көткәннәр бик күп иде шул. Кемдер «аһ!» дип тынын кысты, кайсыдыр, тулган күңелен кеше алдында бушатудан тарсынып, уңайсызланып, ишекне шап итеп ябып тышка атлыкты. Кемдер кул чабарга тотынган иде, күршесе аңа:
— Тик кенә утырсана! — дип кырт кисте.
— Өздең, җаным, үзәкне өздең, Гүзәлия... Рәхмәт сиңа, күңелләрне айкадың. Ходай Тәгалә сиңа тәүфыйклы, бәхетле озын гомер бирсен.
Гүзәлия сәхнәдән төшеп, студент иптәшләре, сәхнә артына йөгереп кергән авыл кызлары кочагына барып ауды...

* * *

Беренче семестр бетеп, имтиханнар тәмамлангач, Гүзәлия дә, авылның бүтән студентлары да каникулга кайтты. Яшьләр кичләрен клубта биюләр оештырдылар, бер-берсенә кунакка йөрешә башладылар. Гүзәлия беркая чыкмады, өйдә китап укып утырды, әнисенә өй эшләрендә булышты. Вакыт-вакыт, онытылып, бер ноктага карап уйга тала иде...
Беркөнне аларга укытучы Нәҗия апасы килеп керде. Гүзәлиядән ничек укуын, хәл-әхвәлләрен сораштырды. Гүзәлиянең җаваплары кыска булды — яхшы, барысы да әйбәт.
— Сеңлем, күзеңнән күрәм, син һаман сагышланасың бит, — диде Нәҗия. — Әнә әниең дә әйтте, сөйләшеп кара әле, ди. Баланың җанын уятасы иде. Син аны ничә еллар укыттың бит, ди. Мин сине аңлыйм, бик аңлыйм, Гүзәлия. Син Әнвәрне бик ярата идең. Ул да сине. Укытучы күзе үткен була бит ул. Ләкин хәзер нишләмәк кирәк. Дөнья бу. Синең яшисең бар әле. Шушы яшьтән үзеңне-үзең бетерү бер дә кирәкмәс иде.
— Ә мин яшәмиммени? Мин мәхәббәтем белән яшим, Нәҗия апа.
— Аңлыйм, сеңлем. Бик аңлыйм. Тик... Ничек дип әйтим... Үлгән артыннан үлеп булмый, ди бит халык.
— Их, Нәҗия апа. Мәхәббәт үләмени соң ул? Әнвәр юк, беләм. Ә аны яратуым исән. Аны нишләтим?
— Онытырга да кирәк бит... Югыйсә...

— Онытырга?! Әнвәрнеме? Сез ни сөйлисез, Наҗия апа! Онытсам, мин уртак мәхәббәтебезгә хыянәтче булам ич. Аны онытсам, бу дөнья миңа нәрсәгә? Актаебыз, урманнарыбыз, болыннарыбыз, кояш, күк нәрсәгә? Әнә Актай янындагы өянке. Ул минем өчен шундый якын. Ул да Әнвәрне хәтерли. Миңа аның яфраклары шавында Әнвәрнең «җаным, бәгърем» дип пышылдавы ишетелә. Мин Әнвәр яраткан урманнар, кошлар белән яшим. Шуларны ташлап, мин кемгә якын кеше була алам? Вак-төяк мәшәкатьләргә буйсынып, мин кемгәдер җан көеге булыйммы?

— Соң бит... мәшәкатьсез тормыш буламыни? Барчабыз да шулай яши ләбаса.

— Наҗия апа, ачуланмагыз... Бер сорау бирим әле. Сез кайчан булса да өзелеп яраттыгызмы?

Мондый сорауны укучысыннан һич тә көтмәгән укытучы йөзеннән караңгы күләгәләр йөгереп узды. Кинәт бирелгән сораудан аның тыны кысылды. Ни дип әйтсен инде ул? Һәркем үзенчә ярата. Наҗия дә үз вакытында берәүне яратты. Тик үзенең физик кимчелеге аркасында (ул тумыштан аксап йөри иде) мәхәббәтенең янып китүенә киртә куйды. Тора-бара сүнде, сүрелде. Эш белән мавыгып, онытырга тырышты. Ә авыл укытучысының эше тавык та чүпләп бетерерлек түгел. Наҗиянең тормышы зарланырлык булмады, укучылары аны ихтирам итте. Аңа «Республиканың атказанган укытучысы» исемен дә бирделәр. Әмма тормышының бер ягы китек иде шул. Ул гомеренә карт кыз булып калды. Мәхәббәт сүзен ул инде китап, дәфтәр, икмәк, сөт, газета кебек сүзләр белән беррәттән куярга өйрәнгән иде.

Туры бирелгән сорауга туры җавап кирәк. Ә Наҗиянең беркайчан да хакыйкатьтән качканы булмады. Дистәләгән укучыларын да ул гаделлеккә, турылыкка өйрәтте. Тик менә бүген ул ничек дип җавап бирә ала иде соң? Гүзәлия аның йөрәк түренең әллә кайсы күзәнәгенә яшеренеп яткан хисенә кагылды. Әрнетер өчен түгел, үзе әрнүдән. Шуңа күрә укытучы карашын яшермәслек көч тапты.

— Яратуын мин дә яраттым. Мин дә тере кеше ләбаса. Тик синеке кебек көчле булмагандыр ул минем мәхәббәтем. Яралган да сүнгән... Ачуланма, сеңлем. Мин бит син өзгәләнгәнгә ярдәм итим дип килдем. Әниең дә үтенде. Җәлил абыең да нишләргә белми аптырап йөри.

— Наҗия апа... Ни сөйлисез... ни сөйлисез?..

— Әйдә, Гүзәлия, моннан соң «син» дип кенә сөйләшик әле.

— Булдыра алсам...

— Күрәм, син бүген үзең минем өчен укытучы дәрәҗәсенә күтәрелдең. Рәхмәт... Ярый, мин китим инде.

— Сезне... сине озатып куйыйм әле. Бәлки, Әнвәр турында берәр нәрсә сөйләрсең.

— Киттек алайса.

— Ичмаса, бер фоторәсеме дә калмады.

— Тукта әле, Гүзәлия. Бер елны сез район үзәгенә пионер слетына бардыгыз ич. Син дә, ул да. Дүртенчеме, бишенчеме класста укыганда...

— Барган идек шул. Ник сорыйсыз?

— Шунда фотога төштек, дип, Нәкыя апаң сөйләгән иде.

— Әйе, хәтерлим. Төшкән идек. Тик минем дә, Әнвәрнең дә акчасы юк иде. Фотоларны сатып ала алмадык. Менә хәзер исемә төште.

— Авыр еллар иде шул... Ярар, сезнең белән слетка барганнарның берәрсе ул сурәтне сатып ала алгандыр ич. Эзләп карыйк әле. Сез бит унлап кеше барган идегез.

— Һәй, табып булса!

* * *

Эзли торгач, ул рәсем табылды. Заманында бик яхшы укыган, хәзер Казанда яшәүче Наилә исемле кызның альбомында ул фотоның барлыгы билгеле булды. Моны белгәч, Наҗия кош тоткандай шатланып Гүзәлияләргә килеп керде.

— Гүзәлия, таптык бит теге фотоны. Классташың Наиләдә бар икән ул. Казанга барып кайтасың инде, болай булгач. Шунда күчермәсен дә алдырырсың, — диде укытучы.

Әнвәрен кабып йоткан Казанны яратмаган Гүзәлия көне-сәгате белән юлга җыенды.

— Кызым, акыллым, тыңла әле мине. — Ана инде йөзенче кат кызын тынычландырырга, хәсрәтеннән айнытырга теләде. — Ярар, бардың, аның каберен күрдең ди. Мин сине бик аңлыйм, йөрәгем белән аңлыйм. Ә шулай да... Хәсрәтең генә яңарыр бит. Бармыйсыңмы әллә? Тыңла әле сүземне, ә?

— Әни... Туктатма инде мине. Үпкәләмә, сорыйм әле. Син этигә яратып кияүгә чыктыңмы?

— Менәтерә мә! Иске авыздан яңа сүз. Һи-и, синең этиең шикелле бер дигән кешене яратмый буламыни!

— Ул хәзер менә мәрхүм. Син аны хәзер дә яратасыңмы?

— Яратам, кызым, яратам. Ә бәлкем, исәндер дә әле. Ялгыш җибәрелгән кәгазьләр булгалый, диләр бит.

— Менә күрдеңме. Әтинең үлгән хәбәре килсә дә, көтәсең, әле дә яратасың. Әнвәр дә мәрхүм хәзер. Ник мин аны яратмаска, онытырга тиеш соң, ә?

— Йа Хода... Әнә нинди акыллы бит үзең. Минем хет өметем бар. Бар әле, бар. Ә синең... Ярар инде, барып кайт. Үзеңне жәлләп кенә әйтүем иде, кызым. Сиңа карап йөрәгем телгәләнә ләбаса.

— Рәхмәт, әни. Хәтерең калмасын инде, яме. Синнән дә якын кешем юк бит минем.

Ана белән кыз арасында менә шундый сүз булды. Икенче көнне Гүзәлия Казанга чыгып китте.

Фоторәсемдә галстуклы кызлар, малайларның кайсы утырып, кайсы басып төшкән. Арттагы рәттә, уртадарак Әнвәр басып тора. Карашында ниндидер гаҗәпләнү дә, арыганлык та сизелә. Күзләрен тутырып объективка караган. Чәчләре матур итеп таралган. Ак күлмәге чалбарына кыстырылган, муенында пионер галстугы.

Слетка алар җәяү бардылар, җәяү кайттылар. Шәһәр карап йөрделәр, төрле спорт ярышларында катнаштылар, бик арыдылар. Әнвәр дә арыды. Авылга кайтып җиткәндә генә аның көне буена берни ашамаганлыгы беленде. Үзе белән алып бармаган, күрәсең. Әллә алырга берни дә булмадымы икән?

Гүзәлия шул чакта, нишләп моны белми калдым икән соң, дип уйлады. Аның бит ул чакта әнисе пешереп биргән ике йомыркасы да, бәрәңге пәрәмәче дә бар иде. Әллә кайчангы сәхифәләр булса да, Гүзәлиянең йөрәге сулкылдап-сулкылдап әрнергә тотынды. Ә Әнвәр берни белми, сизми, кара кашлары астыннан матур күзләре белән карап тик тора. Сурәтнең әрнергә йөрәге юк шул.

Фотоательеда рәсемнең күчермәсен бик тиз эшләп бирделәр. Менә хәзер Әнвәр белән гел бергә булырга, аның белән сөйләшергә, киңәшергә дә була иде...

Казанда Гүзәлия Әнвәрнең апасын эзләп тапты. Озак кына таптанып торганнан соң ишекләрен какты.

— Кем анда? Керегез, кер, ишек ачык! — Бүлмәдән хатын-кыз тавышы яңгырады.

Гүзәлия керде, туктап калды. Ул Әнвәрнең апасын таныды, ире белән аларның авылга кунакка кайтканда күргәне бар иде.

— Мин Көектән килдем, Исламия апа, — диде Гүзәлия. — Менә әни сезгә күчтәнәч итеп бераз май, мәтрүшкә җибәрде. Гүзәлия булам мин...

— И Хода... Әйдә уз, сеңлем. Уз. Утыр. Менә нинди кунак килгән! Газиз, Газиз, чык әле монда, — дип, хуҗа хатын күрше бүлмәдәге иренә эндәште.

Бүлмәдән чәчләренә ак төшә башлаган 45–50 яшьләрендәге ир күренде. Ул авызы тулы ап-ак тешләрен ялтыратып елмая иде.

— Ишетәм, Көектән икәнсез! Һай ул Көек! Аның урман-болыннарының матурлыклары! Балыклы елга-күлләре! Менә Исламия шикелле, сезнең шикелле чибәрләр шул матур болыннарда гына үсәдер ул! — дип шау-гөр килде. — Әйдә, әнисе, чәеңне яңарт, кунак кызга тәмле чәй эчер. Исемеңне ничек дидең әле?

— Гүзәлия мин... Гүзәлия.

— Аһ, шулаймыни? Әнвәр... Әнвәрнең... — Газиз абзый барын да берьюлы төшенеп, ни әйтергә белми аптырабрак калды. — Гүзәлия диген, ә? Бик күрәсем килгән иде. Бик. Менә күрдем. Тик минем сөйләшеп утырырга вакытым гына юк. Эшкә китәм. Син, сеңлем Гүзәлия, авылга кайтканчы тагын кил әле. Бергәләп Әнвәр янына да барырбыз. Кил, яме, ял көне кил. Әнисе, мин киттем алайса. Хуш, сеңлем, — дип, Газиз эшкә чыгып китте.

Ул киткәч, Гүзәлия:

— Исламия апа, Әнвәрнең соңгы көннәре турында күбрәк итеп сөйләгез әле, — диде.

— Сеңлем, изге күңелең, олы мәхәббәтең өчен нинди генә рәхмәтләр әйтим инде сиңа? — Исламия тирән итеп көрсенеп алды. — Бик нечкә күңелле иде шул ул. Шагыйрь булыр дип уйлый идем. Шигырьләр, хәтта бәет тә язганын хәтерлим. Хәер, үзең дә беләсеңдер инде... Гел синең турында сөйләде. Бик сагынды.

— Аны кыйнаган кешеләрне һаман таба алмадылармы?

— Юк, юк шул. Эзләп бик озак йөрделәр. Берни белә алмадылар. Тикшерүчеләрне әйтәм. Күңелеңә авыр алма, әйтим әле. Һәр кешенең үз язмышы, үз бәхете... Синең бөтен гомерең алда әле. Үзең гаҗәеп чибәр дә.

Гүзәлия Исламиянең тел төбен тиз аңлады, бүлдерергә генә кыенсынды. Аннары... аның тавышында, хәрәкәтләрендә Әнвәр төсмерләре барлыгын тойды. Аңа рәхәт иде.

— Рәхмәт, Исламия апа. Сезне тыңлый-тыңлый уйланып утырам әле, — диде ул.

— Үткән белән яшәп булмыйдыр, шулайдыр. Киләчәккә карарга кирәктер... Тик Әнвәр бит минем тәүге мәхәббәтем. Кайберәүләргә карыйм да... боларны тормыш ыгы-зыгысы басып киткән икән, дип уйлыйм.

Тик андый чакта да чын мәхәббәт югалмый икән. Тормыш ничек кенә катлаулы булмасын, сөешеп кушылган кешеләрнең күз карашында, гади сүзләргә үзләре генә аңлый торган мәгънә салып сөйләшүләрендә мин әнә шул йөрәк түрендәге якынлыкны тоям.

Газиз абыйның кулына әнә ничек йомшак кагылдыгыз. Ә ул сезгә ничек елмая! Мин күрдем бит. И-и, әрнүле йөрәккә кагылгач, күпме сүз табыла. Китим әле мин, рәхмәт чәегезгә.

— Сеңлем, изге җан син. Алла сиңа түземлек, саулык-сәламәтлек бирсен. Минем күңелне дә айкап куйдың бит әле. Еш кына дөньяның тәмен белеп яшәргә онытабыз шул. Ял көне тагын кил. Әнвәр янына барырбыз, Газиз абыең да шулай диде.

— Килермен, Исламия апа. Рәхмәт сезгә.

Әнвәрнең апасы, җизнәсе белән сөйләшкәч, Гүзәлиянең күңеле ничектер бераз тынычланып киткәндәй булды. Әллә аңа шулай тоелды гына микән? Бәлкем, туктаусыз уйланып, сагышланып йөргәннән соң кеше табигатенең үзенә күрә бер бушанып китүе, саклану чарасы гына булгандыр бу. Ләкин тормыш һич көтмәгәндә кешегә нинди генә сынаулар куймый. Гүзәлияне ишек төбендә үк яңа тетрәнү көтә иде. Ул ишек тоткасына орынган гына иде, ишек ачылып китте һәм анда... Әнвәр пәйда булды.

* * *

Палата түшәме ап-ак, чиста. Ә шулай да озак карап ятсаң, анда да әллә нәрсәләр табып була. Әнә андагы акбур төерчеге Әнвәрнең кара кашы өстендәге нәни генә ак эзне хәтерләтә. Гүзәлиягә аны Әнвәр кармак сабы белән сугып Рәхимҗан салды дип сөйләгән иде. Һәрчак ярылып торган шалпык иренле, акай күзле ул малай Әнвәрләрдән, Гүзәлияләрдән ике-өч яшькә олырак иде. Әле мәктәптә үк, кыш булса, кызларның элгечтәге пәлтә-бишмәтләренең төймәләрен яру, кесәләренә, букчаларына оятсыз сүзләр язылган кәгазь кисәкләре салу дисеңме, җәй булса, су коенган малай-кызларның киемнәрен суга манчып бәйләп «каз боты» кимертү дисеңме, зираттагы карга ояларын туздырумы, бала-чага берәр төрле ризык тотып чыкса, аны алдалап-йолдалап алумы — боларның барысына да ул маһир иде. Олылар аны юкка гына потка бер кадак тулмаган нәрсә дип әрләмәгәннәрдер инде. Шул Рәхимҗан сукты инде Әнвәрнең маңгаена.

Бик матур җәйге көннәрнең берсендә кызлар, бәрәңге төбен өеп арыгач, Актайның авыл читендә, ферма янындагы тирәнрәк бер урынына су коенырга барганнар иде. Чишенеп суга керүләре булды, биек әрекмәннәр арасыннан фермада эшләүче шул шалпык ирен үрмәләп килеп чыкты да кызларның киемнәрен җыеп алды. Аннары аларның җиңнәрен, балакларын суга манчып, кысып-кысып, тыгызлап бәйләде дә комга күмде. Кызлар шуннан соң ул китәр дип уйлаганнар иде дә, кая ул! Авызын ерып, кызларның судан чыкканын көтеп утыра бирде. Кызлар ялынып-ялварып та карадылар, тик ул ыржаеп утыруын белде. Судагы кызлар күшектеләр, тешләре тешкә тими, елаша башладылар.

Рәхимҗан тыкрыктан сыерларны су эчәргә алып төшүче көтүче Мияссәр абзыйны күргәч кенә шылды. Кызларның кайсыдыр моны фронттан кайтканнарның берәрсенә әйткәндер, күрәсең, бер-ике көннән күпер өстендә балык каптырып утырган малайлар янына Рәхимҗан килеп басты. Аның күз төбе күгәреп чыккан, ярылып торган иреннәре шактый шешкән иде. Гадәте буенча ул балыкларны куркытырга суга таш ата башлады.

Әнвәр:

— Син ник алай эшлисең инде? Нинди кызык табасың үзеңнән кечерәкләрне кыерсытып? — дип торып басты. — Әле эләккәне җитмәдемени?

Рәхимҗан бер малайның кулыннан кармак таягын тартып алды да Әнвәрнең башына орды. Җәрәхәт зур булмаса да, кан ага башлады. Ачуы чыккан Әнвәр, каян шултикле көч тапкандыр, Рәхимҗанны биленнән эләктереп, уңга-сулга селки башлады. Тегесе моңа башта игътибар бирмәде, уенга сабыштырды, хихылдады, ләкин ул абайлап өлгергәнче Әнвәр аны ярдәмгә килгән дусты Әмир булышлыгы белән күпердән суга бәреп төшерде.

Һич көтмәгәндә шундый каршылыкка очрап, мәсхәрәгә калган Рәхимҗан шыр җибәрде бугай, Әнвәргә бүтән кагылмады, ләкин Әнвәр маңгаендагы җөй мәңгегә калды.

Түшәмдәге ак тап әнә шул Әнвәр маңгаендагы яра эзенә охшаган иде. Бәлкем, түгелдер дә, ләкин Гүзәлиянең күзенә ул нәкъ шуның кебек күренде.

Район хастаханәсенә Гүзәлия бер ай элек эләкте. Казандагы теге хәлләрдән соң аның битләре алсуланып, кызарып, купшаклана башладылар. Табиблар төрле мазьлар, майлар сылап карадылар. Бетмәде. Аннары, сораша торгач, Гүзәлиянең кичерешләрен белгәч, авыруның нервлар какшаудан икәненә төшенделәр. Кызны тынычландыру, авыр уйларыннан арындыру бик читен булды.

Хәзер инде эш савыгуга таба бара. Ә шулай да Гүзәлия Казандагы хәлләрне исенә төшерсә, авыр сулап уйга тала. Ә ул чакта...

* * *

Ишектән һич көтмәгәндә Әнвәр килеп керде. Каратутлы, дулкын-дулкын кара чәчле, кара кашлы. Карашында гаҗәпләнү дә, аптырау да бар сыман. Гүзәлия аңа карады да катты. Әнвәр аптырап кызның кинәт агарып киткән йөзенә, әле Исламиягә карап басып торды.

— Әни, вакытым тар. Чәй эчәм дә тренировкага йөгерәм, — дип кул юарга кереп китте.

Тез буыннары бушаган Гүзәлия егылмас өчен шкафка сөялде. Аның йөрәге дөп-дөп тибә, авызы кипкән, бер генә сүз әйтерлек тә хәле калмаган иде. Гүзәлиянең кинәт төсе китүен күреп, Исламия урындык китереп куйды. Бу бик вакытлы булды, Гүзәлия шунда сыгылып төште.

Егет ваннадан чыгып өстәл янына килеп утырды.

Әнисе:

— Менә, улым, безнең авылдан Гүзәлия килгән. Таныш булыгыз, — дигәч, кунакка елмаеп карап куйды.

Гүзәлия егетнең йөзенә текәлеп, ни әйтергә белми утыра бирде. Егетнең каш өстендәге теге җөе юк иде. Борын яфраклары да бераз киңрәк. Әйе, бу Әнвәр дә, түгел дә иде.

— Әни, дим, чәй эчим дә йөгерим.

— Хәзер, Әхмәт, хәзер.

Ниһаять, Гүзәлия аңына «әни», «улым» сүзләре барып җитте. Бу егет Исламия апаның улы икән ләбаса. Йа Хода, кеше охшаса да шултикле охшар икән! Ул кул хәрәкәтләре, күз карашлары... Ә елмаюы!

— Исламия апа, гафу итә күр. Ничектер буыннарым изрәде. И җаным, улыгыз коеп куйган Әнвәр икән бит.

Исламия дә кызның хәлен тулысынча аңлап җиткерде бугай, аны җилкәсеннән кочаклап алды.

Икенче көнне алар тагын очраштылар. Гүзәлия, Әнвәр кабере янына баргач, нишләрмен, үз-үземне белештерми елап, егылып ятмаммы, дип бик нык хәсрәтләнеп барды. Юк, еламады, егылмады. Аңа әллә нәрсә булды. Ул үзен ничектер читтән, бүтән кеше күзе белән күрә башлады. Әнә ул мөмкин кадәр тыныч калырга тырышып, кульяулыгын тарткалап, чардуганга сөялеп тора. Ап-ак йөзендә тирән уй чагыла. Менә шунда, аның аягы янында, Әнвәр ята. Тыныч кына ята. Элеккечә колагына берни дә пышылдамый, кайнар сулышын да өрми. Ничек була соң инде бу, ә?! Үләргә житешеп, өзгәләнеп йөргән Гүзәлиясен ул берничек тә сизмимени? Күккә, йолдызларга менәм дип йөргән хыялый бөркет Әнвәр шулай тыныч кына җир астына кереп яттымыни? Кайда монда гаделлек? Кая киткән аның мәхәббәте?

Гүзәлия айнып киткәндәй башын күтәрде. Аның каршында Исламия апа белән Газиз абый басып тора. Алар нидер әйтәләр, ә Гүзәлия аларны ишетми. Менә аның күзе тере Әнвәргә — аларның уллары Әхмәткә төшә. Күз алдында Әнвәрне әле Әхмәт, әле Әхмәтне Әнвәр алыштыра. Каш өстендәге җөй бер күренә, бер югала. Әхмәт-Әнвәр елмая. Бу елмаю Гүзәлиянең каткан күңелен эретеп җибәрә. Ниһаять, ул дөньяга әйләнеп кайта, ишетә башлый.

— Әйдә инде, Гүзәлия сеңлем. Кайтыйк. Менә Әнвәр белән дә күрештегез. Тыныч кына йокласын, авыр туфрагы җиңел булсын...

* * *

Хастаханәдә дәваланып ятканда үзе дә көтмәгәндә Гүзәлия башына бер уй килде. Терелеп чыгып, имтиханнарын тапшырып авылга каникулга кайткач, ул уй тагын да ныгый төште. Гүзәлия башта аны куып та карады, тик уе аның саен ныгый гына барды. Һәм, ниһаять, Гүзәлия аны беркөнне әнисенә ачып салды:

— Әни, бәгърем, рәнҗемә, — диде ул. — Мин укырга Казан училищесына күчәм.

— Ничек инде? — Әнисе аптырап калды. — Тиктомалдан... Анда кайда, ничек яшәрсең? Ә мин?

— Укып бетереп эшкә урнашкач, мин сине үз яныма алырмын. Ә үзем... Стипендия алам ич мин. Авырга китсә, кичке бүлеккә күчәрмен, ә көндез берәр эшкә керермен.

— Әй, бала, бала... Бу нәрсә була соң инде? Киңәш тотасы иде бит, Җәлил абыең белән... туган-тумача белән.

— Алла боерса, бары да әйбәт булыр, әнием. Борчылма, риза гына бул.

— Бул, дип. Булмый нишлисең... Кайда торырсың соң син? Карале, башларым әйләнеп китте.

— Берәр квартира йә тулай торак табылыр әле. Исламия апалар да булышыр дип уйлыйм.

— Йа Алла, Ходай шулай язгандыр, күрәмсең. Мин каршы килә алмыйм инде. Син хәзер сабый бала түгел.

...Шулай итеп, Гүзәлиябез Казан кызы булды. Педагогия училищесының кичке бүлегенә укырга күчте, вакытлыча эшкә дә урнашты, тулай торак та тапты. Хәзер аңа Әнвәр-Әхмәтне теләгән саен күрергә мөмкинлек туды. Бер кичне ул Әнвәр төшендә күргән бабайны хәтерләп, озак уйланып ятты. Ходайның рәхмәте, Көек бабай аның да төшенә керде. Хәер, берни дә әйтмәде, елмаеп Гүзәлиягә кулын гына сузды. Аның кулыннан Гүзәлия иңенә тургай очып кунды да матур итеп сайрап җибәрде.

*2004*

*У каждой любви — своя история,*
*своя цена страданий!*

*Ч.Айтматов*

***Несколько слов моему дорогому читателю***

*Если ты не веришь, что на свете живет настоящая любовь, не утруждай себя чтением этой книги. Если ты не веришь в святую, трепетную, радостную и чистую любовь, которая, подобно солнцу, освещает твои дни, вдохновляет, дарит твоей душе крылья, заставляя ее петь... Если ты не веришь, что на белом свете есть любовь — и сладкая, и мучительная одновременно, способная потрясти твою душу и тело, размыть границы между мечтой и реальностью, способная вести тебя к милосердию, доброте и свету, к необозримым высотам, — не читай...*

*Однако если когда-нибудь всего тебя захватывала горячая волна любви, заставляя петь, плакать, грустить, и поднимала от земли к звездам, то — молод ты или стар, девушка ты или юноша — будь любезен, прочитай.*

*Автор*

## Анисовые яблоки

### 1

Теплый ветер чуть шевелит листья на яблонях, и они тихо шелестят — словно шепчутся. В саду разливается аромат спелых яблок. На ветках акации с сухим треском лопаются стручки, и из них обильно сыплются на землю высохшие семена. Птицы, в другое время жадно набрасывающиеся на любой корм, сейчас сыты и спокойны: они уже вывели птенцов, подняли их на крыло, и теперь беззаботно чистят свои перышки, клювы и порхают среди веток по одним только им известным делам.

Анис с Ильгизом пришли в библиотеку училища за учебниками для второго курса. Прежде чем войти в каменное здание, они, не сговариваясь, решили посидеть немного на скамейке в яблоневом саду. Было тепло и удивительно спокойно. В голубом небе медленно плыли белые облака...

— Как думаешь, в деревне уже начали убирать картошку? Погода что надо — ясная, сухая.

— Да вряд ли, Ильгиз. Наверно, еще хлеба не убрали. Эх, поехать бы, помочь...

— Уроки-то пропускать нельзя. Уедешь без спросу — попадешь в кабинет директора... Анис, а ты скучаешь, а?.. По деревне, я имею в виду.

— В этом году уже терпимо. Видимо, все-таки привыкаешь ко всему... Но в прошлом году!..

— А я все так же скучаю. Во рту еще сохранился вкус домашнего молочного супа, а сердце уже рвется, как бабочка, попавшая в паутину...

— А кто у тебя остался в деревне, Ильгиз?

— Мама. Мамочка... Зрение у нее совсем плохое. С тех пор, как получила похоронку на отца, плачет и плачет. Уж сколько лет...

— Да-а... Наверно, она очень любила его.

— Она и сама так говорит.

— Ты только подумай, как это удивительно! Как сильно человек может любить человека, да? Что же это за любовь такая?..

Анис и Ильгиз теперь частенько вспоминают тот давний свой разговор. С тех пор прошел целый год. И какой год! Год, который, подобно внезапно налетевшей буре, порядком растормошил их молодые души. И этот учебный год, ознаменованный приходом первой и чистой любви, и навсегда отпечатавшийся в памяти незабываемыми событиями, как раз и начался в тот самый солнечный, теплый, чудесный, пропахший яблоком сентябрьский день.

## 2

Анис только взялся за ручку двери, но она внезапно распахнулась, и из нее выбежали со смехом несколько девушек. Если бы эту сцену снимал кинооператор, то он непременно показал бы, как Анис, отступив назад, пропустил девушек, а затем камера крупным планом показала бы его широко открытые глаза и выражение восхищения и удивления на его лице. А голос за кадром, вероятно, прокомментировал бы так: «...Это огромное, возвышенное чувство зародилось внезапно в сердце Аниса в чудесный, теплый и солнечный сентябрьский день».

Девушки тем временем забежали в ворота училища. Анис, начисто позабыв, что пришел в библиотеку за учебниками, постоял некоторое время в задумчивости у двери, а затем сел прямо на ступеньки. Мимо него сновали туда-сюда молодые ребята и девушки. Те, что поступили в училище только что, шагали неуверенно, внимательно оглядываясь вокруг. Старшекурсники — напротив, шумно перепрыгивая через две-три ступени. А Анис продолжал сидеть. Перед его глазами все еще стояло нежное лицо девушки с толстыми косами, выпорхнувшей в середине той стайки девчат. Глаза девушки были ярко-голубыми, словно васильки на лесной поляне, и в них плескалась радость от жизни, молодости и здоровья. Взгляд девушки лишь скользнул по лицу Аниса, но успел зажечь огонь в его груди. От этого огня по всему его телу теперь разливалась какая-то сладостная тревога, и почему-то хотелось летать или бежать куда-то... Нахлынувшее состояние Анису было немного знакомо. Точно так же он чувствовал себя, когда в лесу или на лугу неожиданно набредал на поляну, усыпанную красными ягодами. Сейчас были примерно те же ощущения, но... горячее, сильнее и... приятнее. С этого дня Анис потерял аппетит и покой. Он сидел на уроках, но его там не было. Взгляд юноши был устремлен куда-то далеко, на что бы он ни смотрел, перед ним вставало нежное белое лицо девушки, ее голубые глаза, тяжелые косы. Он не слышал недоуменных вопросов учителя: «Анис, что с тобой? Ты не слушаешь. О чем я только что рассказывала?» В таких случаях его приводил в чувство только толчок соседа — Вагиза. И Анис, очнувшись, отвечал:

— Извините, я прослушал.

— Надо быть внимательнее на уроке, — предупреждали его, а Анис, возвращенный к реальности, удивлялся про себя: «Я же на уроке! Опять задумался».

Все в этой жизни имеет свой предел. Так и мысли в смятенной голове Аниса после некоторого времени начали, наконец, приобретать реальные очертания. Он начал потихоньку понимать причину того, что ему все время хочется видеть эту улыбчивую девушку с васильковыми глазами. Ему приходилось читать об этом. Герой романа Габдрахмана Абсалямова «Золотая звезда» Галим Урманов испытывал точно такие же чувства...

На переменках Анис издалека наблюдал за синеглазой незнакомкой. По тому, что она все время была с девушками, поступившими в училище из детского дома, Анис понял, что его избранница — тоже сирота. Такие ребята ходили в одинаковой одежде. «Васильковые глазки» была одета точно так же, видимо, у нее тоже не было родителей. Каждый раз, когда он думал об этом, его сердце болезненно сжималось. Эх, как бы он хотел погладить девушку хоть раз по ее волосам!

Но в один из дней Анису привалило счастье: он узнал имя свой синеглазой красавицы. Как уже было сказано, при училище был разбит очень красивый яблоневый сад и огород. В саду росли яблони разных сортов, и дни сбора урожая становились в училище веселым праздником. Ах, этот пряный яблочный дух! Опьянев от душистого запаха, кружатся в воздухе пчелы и осы. Сад гудит от молодых голосов. В эти дни вместе с учениками работают и учителя, даже директор — рослый мужчина с густыми волнистыми черными волосами — помогает грузить ящики с яблоками на телегу, шутливо переговаривается с молодежью, иногда даже вступает с ними в спор. Эту простоту любят в нем и ученики, и учителя. Впрочем, в городе вряд ли нашелся бы хоть один человек, который не знал и не уважал бы его. Приезжая в райцентр из деревень по своим делам, люди частенько узнавали его на улице и обязательно подходили:

— Здравствуйте, Сафа Гилязетдинович, как ваши дела?..

Все потому, что слава о педагогическом училище разлетелась по всей республике. А руководит им уже многие годы отличник просвещения Сафа Насихов.

Для деревенских парней и девчат, с детства привычных к любой физической работе, сбор яблок разве трудное дело?! А уж когда работа коллективная, да еще на глазах у директора и учителей!.. Нынче год оказался урожайным на яблоки; ребята осторожно, стараясь не помять плоды, срывают их с веток, укладывают в ящики и отвозят на склад. Этих яблок хватит и на то, чтобы поесть, и для столовой — варить зимой компот. Так говорит сам директор.

Недалеко, взобравшись на лестницу, в компании своих одноклассников собирает яблоки и та самая девушка... Анис видит ее не только глазами, но и своим сердцем. Ах, как она смеется! Словно серебряный колокольчик звенит! Этот голос проникает в самые отдаленные уголки души Аниса. Он оглядывается на девушку и забывает о ящике, который собирался закинуть себе на плечо.

— Ящик, похоже, слишком тяжел для Аниса. — Насмешливо замечает однокурсник Аниса Ильгиз. — Давай помогу! — И он берется за края ящика.

Да разве это тяжесть для Аниса? И разве он позволит помогать себе на глазах у всех? Вот сейчас он покажет, чего он стоит... Анис рывком поднял ящик с земли, но, потеряв равновесие, чуть не уронил его на землю. Верхние яблоки посыпались на землю. Кто-то засмеялся. Девушки, сочувственно заохав, украдкой посмотрели на учителей и директора. Анис, не поднимая голову от смущения, начал подбирать яблоки с земли. Его щеки стали такими же красными, как эти яблоки. А в голове крутилась только одна мысль: заметила ли она?.. И что скажут учителя?..

Опытная учительница русского языка поняла состояние Аниса:

— Ничего страшного, ребята, постарайтесь быть поаккуратнее, — сказала она, сразу сняв напряжение. — А с яблоками ничего не случилось, они же на мягкую землю упали.

Анис благодарно улыбнулся ей, тяжелый камень, навалившийся на сердце, растворился и исчез бесследно.

В то же мгновение неподалеку разом вскрикнули несколько девушек. Оказалось, что девушка с васильковыми глазами потянулась за яблоком, лестница под нею упала. Теперь бедняжка висела, ухватившись за ветку, и кричала: «Помогите же!..»

Увидев это, Анис бросился на помощь. Туда же побежали и другие ребята. Но вы только посмотрите на рыжего Идмаса! В мгновение ока он добежал до лестницы, приставил ее к яблоне. Затем, взобравшись по ней, притянул девушку к себе и помог ей спуститься на землю.

Кто-то из подруг заметил:

— Аниса, у тебя рука расцарапана, надо смазать йодом. — И девушку увели в медпункт училища.

Анис тем временем, не веря своим ушам, огляделся по сторонам. Ее назвали Анисой? Ну да... Значит, ее зовут Аниса. Что же это получается? Ведь он сам — Анис. Интересно... Анис то радовался этому, то удивлялся. И правда, удивительно. Какое совпадение! Анис — Аниса. Впрочем, мало ли на этом свете людей, которым родители дали похожие имена? Но вот когда такие люди встречаются — это уже дело божье. Значит, эта девушка — тезка Аниса...

В ту же секунду сердце Аниса кольнула другая мысль — неприятная. Почему до Анисы первым добежал не он, а рыжий Идмас? Если бы он был порезвее, Аниса сказала бы спасибо не Идмасу, а ему, Анису.

Но все же настроение у него было приподнятое. Он узнал имя обладательницы васильковых глаз. Аниса... Надо же!

## 3

Довольно долгое время Анис предпринимал попытки встретить Анису наедине. В то же время он не представлял, как начнет разговор и что скажет, если ему улыбнется такое счастье. Поэтому, встречая девушку в компании ее подруг, он был даже рад этому.

К октябрьским праздникам в училище обычно готовились серьезно. Студенты участвовали в праздничной демонстрации. Проходя перед зданием райкома, где у памятника Ленину обычно стояло районное начальство, ребята дружно махали руками. А из динамиков доносилось радостное:

— Приветствуем студентов педагогического училища!

Молодые люди, услышав слово «студенты», радостно кричали на всю улицу: «Ур-ра-а!»

В самом училище перед праздником обычно устраивают большой концерт. Выступление русского отделения смотрят студенты татарского отделения и наоборот. За кулисами, трясясь от страха, ждут своего выхода на сцену ребята с сольными номерами, в том числе и те, кто играет на музыкальных инструментах. После концерта — танцы. Актовый зал гудит от множества голосов — здесь девушки в белых блузках и

белых фартучках и юноши в галстуках, которые придают им серьезный вид. Ведь что ни говори — праздник, что ни говори — молодость...

А в этом году для Аниса праздник получился двойной. Сыграв в составе оркестра несколько произведений, Анис спустился со сцены и тут же присел на первое попавшееся свободное место. Однако не успел он устроиться, как сидевшая рядом девушка шепнула ему:

— Здесь занято.

Анис повернулся к девушке... Это была Аниса!

— Это место моей подруги. Вон она сама идет, — сказала девушка.

— Молодой человек, освободите, пожалуйста, мое место, — раздалось прямо над ним. Подняв голову, Анис увидел перед собой русскую девушку. От неожиданности он даже встать забыл.

— Ты что, словно в первый раз видишь?! Что ты уставился? — сказала Аниса и рассмеялась.

И тут Анис не к месту шепнул ей:

— Ты ведь Аниса. А я — Анис. — И тут же, встав, быстро ушел.

Несколько дней после этого Анис ходил окрыленный, испытывая какое-то внутреннее удовольствие и ожидая перемен. Ведь он сказал свое имя этой голубоглазой, сказал! Значит, они познакомились. Однако никакой перемены не случилось. Аниса изредка попадалась ему то в библиотеке, то в коридоре, всегда в компании подруг и такая же равнодушная к нему. В такие дни душа Аниса страдала. Ну, как же так?! Она даже не оборачивается при встрече, а ведь они уже познакомились? Похоже, ей совершенно безразлично, есть на свете Анис или нет его. Хотя... она, наверно, права. Кто он такой, чтобы такая красивая девушка стала обращать на него внимание? Одежда на нем — одно название. В училище действует установленный директором жесткий закон: в общежитии ты можешь носить какую угодно, даже латаную одежду, но в училище изволь ходить пусть в самом простеньком, но отглаженном костюме. Рубашка всегда должна быть чистой. На шею — обязательно галстук. Об обуви даже говорить нечего. Она должна быть чистой. Иногда у порога училища, независимо от того, весна на дворе или осень, стоит сам директор и проверяет одежду и обувь. Все это продиктовано одним его желанием — научить будущего учителя одеваться аккуратно и чисто.

Ребят, принятых на учебу из детского дома, в училище кормят и одевают. Это находится под жестким контролем воспитателей. И одежда на них красивая. Одни только шерстяные свитера чего стоят. Некоторые шустрые ребята сами время от времени требуют от воспитателей обновления гардероба. Имеем право — дайте! А что у Аниса? Прошлой весной во время половодья он таскался по коридорам училища в огромных калошах с предательски выглядывающей изнутри красной подкладкой. И умирал от стыда, замечая многозначительные взгляды девушек, которыми они обменивались между собой.

Родители в этом году продали овцу и кое-как наскребли Анису на ботинки, новые брюки и рубашку. Но все равно его одежда намного хуже той, что выдают учащимся-сиротам. И еще эти волосы! Густые и черные, они непокорными вихрами торчат на макушке. Сколько их ни приглаживай, ни смачивай — бесполезно. Отрастить бы их подлиннее, так и забот бы никаких. Но нельзя: увидит директор и все — стригись. Потому что ты будущий учитель!

